PRESSA.RU

ЯҢАШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА

№7 (295) – ИЮЛЬ 2016

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

1920 елдан
нәшер ителә

Татарстан профессионаллар командасын туплый

Җиләкчедән күрмәкче

Ханнар төрбәсе язмышы

КАМА СУДАГЫ ҺӘМ АНЫҢ ТУРИСТИК ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

PRESSA.RU

16+

Редакция:
420066, Казан,
Декабристлар ур., 2,
тел. (843) 222-09-79
tatarstan@tatmedia.com

Баш мөхәррир: Татьяна Николаевна Вафина, vafina@tatmedia.com
Шеф-редактор: Әскәр Сабиров, sabirov@tatmedia.com
Баш мөхәррир урынбасарлары:
Нияз Әхмәдуллин, ahmadullin@tatmedia.com
Рөстәм Шакиров
Чыгарылыш мөхәррире:
Фәридә Әхмәтҗанова
Бүлек мөхәррирләре:
Владимир Матылицкий
Татьяна Колчина
Ольга Туманская
Линар Закиров
Әдәби мөхәррир: Луиза Янсуар
Веб-редактор: Олеся Бондаревская, bond@tatmedia.com
Авторлар: Катерина Котова, Айдар Сәгъдиев, Фаяз Хуҗин, Диләрә Шкурко
Фотографлар: Ната Смирнова, Александр Эшкинин
Дизайн-макет: Леонид Гобәйдуллин
Вёрстка: Игорь Глушков, Леонид Гобәйдуллин
Препресс: Игорь Глушков
Корректор: Айсылу Корманова
Офис-менеджер: Ләйсән Әхмәрова
Тышлыктагы фото: Ната Смирнова

Журнал 1920 елдан нәшер ителә

1979 елда Халыклар дуслыгы ордены белән бүләкләнә

Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәттә теркәлгән. Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС 77 – 66045, 10.06.2016.

Тираж: 3500 данә,
шул исәптән татар телендә – 1000.

Бәясе ирекле

Редакциянең язма рөхсәтеннән башка «Татарстан» журналындагы материалларны күчереп бастыру тыела. Күчереп бастырганда, журналның исемен күрсәтү мәҗбүри. Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Реклама материалларының эчтәлеге өчен редакция җавап бирми. «Промо» һәм «Медиа» рубрикалары материаллары реклама-коммерция нигезендә басыла.

Журнал «Татмедиа» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы типографиясендә **басылды**:

420066, Казан, Декабристлар ур., 2

Заказ № М-1675

Басарга кул куелды: 19.07.2016

Дистрибуция һәм трафик бүлеге җитәкчесе:
Миләүшә Байрашева, milyaushanb@tatmedia.com
Коммерция директоры:
Нина Әхмәтшина, nivlana@tatmedia.com, тел. (843) 222-09-76
Коммерция директоры урынбасары:
Айваз Диндаров, aivazid@tatmedia.com
Махсус проектлар бүлеге җитәкчесе:
Юлия Фәсәхова, тел. (843) 222-06-05
Махсус проектлар бүлеге белгече:
Җәмилә Әхмәтшина, ahleva5@mail.ru
Бухгалтерия:
Ольга Басаркина, тел. (843) 222-09-80

ДӨНЬЯ ТЫНЫЧЛЫККА ОМТЫЛА

Кайчан да булса барысы да тәртипкә килер, һәм дөньяда күптән көтелгән тынычлык урнашыр. Без кычкырышмый, талашмый, атышмый, шартлатышмый башларбыз, сүгенү-орышышу сүзләрен онытырбыз, хәзер нигәдер күзебезгә күренмәгән гап-гади нәрсәләргә шатлана-куана башларбыз. Дөньяда барысы да тынычлыкка таба бара, шундый юнәлеш шәйләнә. Һәм бу тарихны яңадан язарга, һәйкәлләрне юк итәргә тырышуларга, вакыт-вакыт безне тетрәндергән терактлар булуга да карамастан. Дөнья тынычлыкка омтыла: кайдадыр бу ачык шәйләнә, тиз бара кайдадыр урау юллар аша, хаталана-хаталана бара, әмма омтылыш бар, ул күренә. Чөнки кеше акыллы зат, ул сугыш һәм җимерүләр өчен түгел, тынычлык һәм имин тормыш төзү өчен яратылган. Бу турыда хисап һәм докладлар теле белән ТР Президенты каршындагы Милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләр Советы утырышында югары затлар да сөйләделәр. Бу турыда дискуссияләр һәм бәхәсләр теле белән Төбәк һәм милли ММЧ форумы депутатлары да сөйләделәр. Бу турыда догалар телендә Казанда Ифтар ашына җыелган дин әһелләре дә сөйләделәр. Бу турыда Украина халыкларын берләштерү максаты белән хач йөреше оештырган украинлылар да әйтергә омтыла. Һәм хәтта ки сугыш коралларын еракка яшереп, тыныч максатларда Казанга килгән индеецлар да Бауман урамында бу турыда җырлыйлар. Ничек уйлыйсыз: бу җырларның сүзләре нинди икән? Аңламыйсызмы? Ә без аңлыйбыз. Тыныч күк йөзе, дустанә мөнәсәбәтләр хакында ул сүзләр.

– Ни өчен сез монда? – дип сорыйбыз юлбашчыларыннан чиста ишарәләр телендә.

– Чөнки монда тыныч урын, – ди юлбашчы. – Тынычлыкны саклагыз! Хау!*

* Хау! – Мин бөтенесен дә әйттем! – индеецлар теленнән.

СЕЗНЕҢ РЕДАКЦИЯГЕЗ

Редакция советы:
АЛАЕВ Юрий Прокопьевич
АЛЕКСАНДРОВСКАЯ Ирина Алексеевна
ӘХМӘТШИН Равил Кәлимуллович
БЕЛЯКОВ Роман Юрьевич
БИКЧӘНТӘЕВ Фәрит Рәфкатович
БОЛЬШАКОВ Андрей Георгиевич
ВӘЛИЕВА Зилә Рәхимҗановна
ГАЛИЕВ Марат Гадыевич
СӘЛӘХОВ Мәгъзум Кәлимуллович
ФӘЙЗУЛЛИН Равил Габдрахманович
ХӘКИМОВ Рафаэль Сибгатович
ХОМЕНКО Вадим Васильевич

татмедиа

Гамәлгә куючы:
«Татмедиа» АҖ
Нәшер итүче:
«Татмедиа» АҖ

420097, Казан,
Академическая ур., 2

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла

«Татарстан» журналына язылу барлык элемтә бүлекләрендә кабул ителә
Индекс **П2381** – татар телендә
Индекс **П2378** – рус телендә

Ярты елга язылу бәясе:
892 сум 32 тиен

Ната Смирнова фотосы

ЭЧТӘЛЕК

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

4. Дәүләт Думасы.
Булачак парламентарийлар каршындагы бурычлар.

6. Үрнәк чиста, трихинеллёз юк.
Авыл ветеринарлары ничек яшиләр һәм эшлиләр.

26. Кече эшкуарлык.
Җиләкчедән күрмәкче.

34. Татарстандагы климат.
Тропиклар яисә боз чорымы?

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

40. Туристик энергияне саклау законы.
Ни өчен безгә киләләр һәм тагын да күбрәк килсеннәр өчен нәрсә эшләргә.

44. Яшел соус белән бирелә торган фахверк.
Германиягә күбрәк килсеннәр өчен немецлар нәрсә эшлиләр.

48. Кама судагы.
Һәм аның туристик үзенчәлекләре.

54. Татарстан тирәли сәяхәт.
Провинциаль гүзәллек һәм тарихи ядкәрләр турындагы хатирәләр.

58. Кече ватан патриотлары.
Янка Купала янына – җилкәннәрне киереп.

64. Украина татары.
Дөньяда дошманлык һәм үзара аңлаша алмаудан өстенрәк кыйммәтләр турында.

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

74. Тарих сәхифәләре.
Казан Кремле территориясендәге хан төрбәләре.

78. Беренче урында яңгыраш һәм кешелеклелек.
Гастрольләрне санамаганда, Казанда ярты гасыр.

82. Китап киштәсе.
«Җәйге» китаплар турында сөйләшәбез.

96. Татарстан риваятьләре.
Шуран өрәкләре.

PRESSA.RU

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

2.07

Олег Морозов, Татарстаннан Федерация Советы әгъзасы, – Казанда «Бердәм Россия» партиясенең Татарстан региональ бүлегенең XXV конференциясендә:

– Россиядә яшәп килгән федерация күпчелек Татарстан һәм аның лидерларының эзлекле федералистик позицияләре аркасында барлыкка килде. Бүген ул Конституция белән беркетелгән, һәм аны беркем дә юкка чыгара алмый.

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

1.07

Владимир Зорин, РФ Президенты каршындагы милләтара мөнәсәбәтләр буенча Совет президиумы әгъзасы, – төбәк һәм милли ММЧ форумында:

– Безнең үзенчәлек шунда, безнең конфессияара мөнәсәбәтләрдә хокукый көйләү моделебез бар. Дөньяда һәйкәлләрне, диннәрне, бер-берсен юкка чыгаралар, ә бездә исә Екатерина II нигез салган модель үсеш алган. Һәм без Татарстанда җыелдык. Һәм без Татарстанга бөтендөнья хәрәкәткә керткән әлеге өлеше өчен рәхмәтле. Киләчәк нәкъ менә шундый хәрәкәтләрнеке.

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

2.06

Камил хәзрәт Сәмигуллин, Татарстан мөфтие, – Рамазан ае башлану уңаеннан котлауда:

– Әйдәгез олы җанлы булыйк һәм барыбыз бергә ярдәмгә мохтаҗ булган гаиләләргә, ятимнәргә, инвалидларга, өлкәннәргә булышыйк. Бу вакыт – холкыбызны яхшырту, авыр гөнаһлардан арыну һәм үз тормышыбыздан барлык начар гамәлләрне чыгарып ташлау өчен уникаль мөмкинлек.

Фото: Татар-информ; www.islam.ru

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

БУ САНДА ТӘКЪДИМ ИТӘБЕЗ:

«Бердәм Россия» республика бүлекчәсен **КЕМ** җитәкләде

Авыл ветеринарлары **НИЧЕК** яши һәм эшли

Иң тәмле җиләкләр **КАЙДА** үсә

«Акыллылар өчен эшләү» **КЕМ** принцибы

Татарстанлылар **НИ ӨЧЕН** «сары зонада» яшиләр

PRESSA.RU

– ТАТАРСТАННАН ДУМАДА ПРОФЕССИОНАЛЛАР КОМАНДАСЫ БУЛЫРГА ТИЕШ

«Безнең республика мәнфәгатьләрендә эшләргә, кешеләрдә булган ихтыяҗларны, таләпләрне һәм хаҗәтләрне җиткерергә», – ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов сентябрь сайлауларыннан соң Дәүләт Думасына Татарстаннан киләчәк парламентарийлар өчен әнә шундый бурыч билгеләде.

Фото: president.tatarstan.ru

Булачак сайлаулар гамәлдәге хакимият өчен имтихан булачак. Асылда, сайлаучыларның тавышлары узган елларда башкарылган эшләргә иң объектив бәя ул.

Татарстан лидеры бу хакта әйдәп баручы телевидение каналлары җитәкчеләре белән 29 июньдә Кремльдә узган очрашуда әйтте. Шушында ук Рөстәм Миңнеханов төп тезисны да ачыклады: илнең законнар чыгаручы иң мөһим органында Татарстаннан бердәм профессионаллар командасы булырга, һәркем депутат мандатына хокукын республика кешеләре иминияте хакына башкарган конкрет эшләре белән расларга тиеш. Президент игътибарны тагын бер мөһим моментка юнәлтте: профессионаллар командасы үз позициясендә нык торырга һәм «төпле сүзен әйтә белергә» бурычлы. Рөстәм Миңнеханов әйтүенчә, алар «тәҗрибәле, абруйлы, әйбәт мәктәп үткән» кешеләр булырга тиеш.

Булачак сайлаулар гамәлдәге хакимият өчен имтихан булачак. Асылда, сайлаучыларның тавышлары узган елларда башкарылган эшләргә иң объектив бәя ул. Тормышның сыйфаты, демография, медицина хезмәтенең торышы, белем бирү дәрәҗәсе – бу эшнең ни дәрәҗәдә нәтиҗәле булганлыгы турында фикер йөртү өчен төп критерийлар әнә шулар. Һәм Татарстан, бу яктан караганда, бөтен Россия күләмендә лаеклы урынны били.

Бу турыда билгеләп үткәч, Татарстан Президенты, шуңа да карамастан, ирешелгән уңышларның әле тынычланып калыр өчен сәбәп булмавын да искә төшерде. Әйе, бүген Татарстан хакимиятендә торучылар байтак эш башкардылар. Әмма, беренчедән, бүгенге нәтиҗәләргә буш урында ирешелмәде – нигезне, традицияләрне инде безгә кадәрге буыннар салган иде. Икенчедән, дип ассызыклады Рөстәм Миңнеханов, «без һәрвакыт канәгатьсез булырга тиеш», чөнки «безнең критерийлар, безнең индикаторлар ул – бөтендөнья дәрәҗәсе». Әгәр дә катлаулы бурыч куелган икән, аны тиешенчә хәл итәргә дә кирәк. Президент образлы итеп әйткәнчә, «һичьюгы ярты адымга булса да алда торырга кирәк».

Шунысын да искә төшерик, Татарстан лидеры Рөстәм Миңнеханов «Бердәм Россия» партиясенең республика төркеме исемлегендә беренче булып тора. Бу карар бердәм россиялеләрнең 27 июньдә Мәскәүдә узган съездында кабул ителде. Исемлек башына тәбәктә генә түгел, ә бәлки тулаем илдә ышаныч казанган абруйлы сәясәтченең куелу факты, экспертлар фикеренчә, һичшиксез, гроссмейстерларча карар булып тора, һәм аңа сайлаучылар лаеклы бәя бирәчәк. Моны раслау йөзеннән, аналитиклар ике ел элек узган ТР Дәүләт Советына сайлау нәтиҗәләрен китерәләр. Ул чакта исемлек башында Рөстәм Миңнеханов торган «Бердәм Россия» өчен татарстанлыларның 84,26%ы тавыш бирде.

– Без партиянең бу карарын Татарстан Президентының абруен һәм нәтиҗәле эшен тану буларак кабул итәбез. Рөстәм Нургалиевич – федераль масштабтагы сәясәтче, Россия дәрәҗәсендәге шәхес, – диде бердәмроссиялеләр съездыннан соң «Бердәм Россия» партиясенең Татарстан төбәк бүлеге секретаре Фәрит Мөхәммәтшин. – Федераль үзәк янә бер тапкыр Татарстан Республикасын Россиянең алдынгы төбәге буларак күрсәтте, безнең казанышларыбызны югары бәяләде. Һәм без үз тәҗрибәбезне тапшырырга, илнең һәм республикабызның икътисадын Дәүләт Думасының закон чыгару карарлары югарылыгында үстерергә һәм тотрыклылыгын сакларга әзер.

Шунысын да искә төшерик, «Бердәм Россия» федераль исемлегенең Татарстан территориаль төркеменә барлыгы 14 кандидат керде. Президенттан соң исемлектә ТР авыл хуҗалыгы министры Марат Әхмәтов, Татарстаннан хәзерге Дәүләт Думасы депутаты Александр Сидякин һәм республиканың элекке сәламәтлек саклау министры, РФ финанслар министры урынбасары Айрат Фәррахов исемнәре бара. «Бердәм Россия» тагын алты кандидатны бер мандатлы округлардан тәкъдим итте. Болар – Фатыйх Сибагатуллин (Идел буе округы), Илдар Гыйльметдинов (Мәскәү округы), Айрат Хәйруллин (Түбән Кама округы), Әлфия Когогина (Яр Чаллы округы), Ринат Хәйров (Әлмәт округы), Иршат Минкин (Үзәк округ).

«Бердәм Россия»нең Татарстандагы төбәк бүлеге – илдә иң зурысы. Республикада яшәүче 137 мең кеше партия әгъзасы булып тора. Республиканың закон чыгару һәм вәкиллекле органнарында «Бердәм Россия» зур күпчелекне тәшкил итә: гомумән алганда, бердәмроссиялеләрнең парламент командасы – хакимиятнең төрле дәрәҗәләрендәге 6202 депутаттан гыйбарәт. Бүгенге Дәүләт Думасында Татарстаннан бердәмроссияле 13 депутат эшләде.

Сентябрь сайлауларының нәтиҗәләре буенча «Бердәм Россия» парламентның түбәндәге палатасындагы вәкиллекне арттыруга өметләнә. Партиянең төбәк бүлегендә моның республика мәнфәгатьләрен федераль дәрәҗәдә тагын да нәтиҗәлерәк якларга мөмкинлек бирәсенә ышаналар.

PRESSA.RU

... Гомуми белем бирү мәктәпләре белән тәэмин итү Мәктәп һәм балалар бакчаларын капиталь ремонтлау Яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү Балалар бакчалары төзү Яшүсмерләр клубларын капиталь ремонтлау Спорт мәйданчыклары төзү «Уңайлы мохит» программасы Социаль хезмәт күрсәтү стационар оешмаларын капиталь ремонтлау Балалар сәламәтләндерү лагерьларын капиталь төзекләндерү **Участок ветеринария пунктларын төзү һәм капиталь төзекләндерү** Мәдәният объектларын капиталь ремонтлау ФАПлар төзү, сәламәтлек саклау объектларын капиталь ремонтлау Ветеринария хезмәте күрсәтү биналарын төзү Ветеринария берләшмәләрен һәм авыл хуҗалыгы идарәләрен капиталь төзекләндерү Сыер абзарларын капиталь ремонтлау Силос-сенаж траншеяләрен төзү Яшелчә саклагычларын капиталь ремонтлау Тузган торак Социаль ипотека Күп балалы гаиләләрне торак белән тәэмин итү...

ПРЕЗИДЕНТ ПРОГРАММАЛАРЫ. НӘТИҖӘЛӘР

МАЛ-ТУАРНЫ ДӘВАЛАУЧЫ ТАБИБЛАР

2013 елдан Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов күрсәтмәсе буенча участок ветеринария пунктларын төзү һәм капиталь төзекләндерү программасы эшли башлады. Без программаның үтәлешен карау максаты белән Арча районына юл тоттык. Яңа Кенәр авылында яшәүче Габдрахмановлар гаиләсе башкорт токымлы сигез үгез тота. «Алар бик тыныч, нәрсә бирсәң, шуны ашый. Авырган чаклары да була. Кайвакыт юеш печән ашап күбенәләр. Андый вакытта мал табибын чакыртабыз», – дип сөйләде Рәмзия ханым. 2014 елда авылда ветеринария пункты ачылгач, ветеринария хезмәте күрсәтү дәрәҗәсе дә яхшырган.

Автор:
Линар Закиров

«СЫЕР – ИҢ АКЫЛЛЫ ХАЙВАН»

Рәмзия Габдрахманова Арча районының Сәрдәбаш авылында туып-үскән. Бүген ул гаиләсе белән 2500 кешелек Яңа Кенәр авылында гомер кичерә. Заманында салада дүрт сыер көтүе чыккан булса, хәзер берәү генә калган – анысында да мал саны иллегә дә тулмый. Габдрахмановларның биш баласы бар – өчесе кыз, икесе малай. Егетләр кул арасына кереп кенә килә, шуңа күрә бөтен эш кызлар җилкәсенә төшә. Әниләре әйтүенчә, кызлар тиресен дә түгә, печәнен дә чаба.

– Минемчә, хуҗалыктагы иң акыллы хайван – сыер. Катырак әйтсәң, үпкәли. Ун ел элек, дуңгыз үстереп, ит сатудан кергән акчага лапас белән өй салдык. Хәзер 260 каз, 200 бройлер, 20 тавык, үрдәкләр асрыйбыз. Матурлык өчен индоүрдәкләр дә тотам, аларның ишегалдында матур итеп йөргәннәрен күргәч, күңел күтәрелә. Яңа ел алдыннан бөтен казларыбызны алып бетерәләр. Йоннарыннан

Фото: Ната Смирнова



үзебезгә дә, туган-тумачага да бүләккә мендәрләр ясыйм. Кибетнеке белән чагыштырганда, аерма җир белән күк арасы. Кияүгә чыгасы кызлар да, килеп, мендәр сорый.

Терлекләр сау булсын өчен, аларның сәламәтлеген кайгыртып торырга кирәк. Авылдагы ветеринар мал-туарыбызга прививканы даими ясый, – дип сөйләде безгә хуҗабикә.

МАЛ ТАБИБЛАРЫ НӘСЕЛЕ

Рафаэль Хәмзинның ветеринар булып эшләвенә быел 20 ел була. Яңа Кенәр һәм күрше-тирәдәге авылда 16 мең баш мал-туарга инде җиде ел күз-колак булып тора ул.

– Мин кечкенә чакта гаилә дусларыбызның берсе мал табибы булып эшли иде. Бу һөнәргә аңа карап тартылганмындыр. Нәселебездә дә үз тормышын ветеринария хезмәте белән бәйләүчеләр күп, – диде Рафаэль әфәнде.

PRESSA.RU

Элек авыл читендә ветеринария пункты булган. Әмма анда эшләрлек шартлар булмаган, шуңа да мал табибына бөтен нәрсәне өендә хәстәрләргә туры килгән. 2014 елда яңа пунктны дүрт контейнерга төяп алып килгәннәр дә бер атна эчендә җыеп та куйганнар.

– Авылда төзелеп бетмәгән бер йорт бар иде. Яңа пункт ачылганчыга кадәр, безгә шул йортны алып бирәселәр иде. Бу программа килеп чыккач, өр-яңа бинада эшли башладык. Хәзер бөтен кирәк-ярак шушында саклана. Операция, орлыкландыру бүлмәләре, даруханә дә бар, – дип, кечкенә генә бина буенча экскурсия үткәреп алды Рафаэль Хәмзин. – Даруханәдә булмаган әйберләрне сорасалар, район үзәгеннән алып кайтабыз. Кыш көне җылы, тик җәй көне эссерәк, кондиционер юк.

Әңгәмәдәшем сөйләвенчә, пунктта биш кеше эшли: ветеринар, эпизоотолог, ике фельдшер һәм санитар. Эш машинасы да бар – «Нива». Шимбә-якшәмбе рәсми рәвештә ял булып саналса да, мал-туар эш көннәрендә генә авырмый бит. Шуңа күрә, ул-бу килеп чыкса, әйтик, сыер бозаулый алмаса, авыл халкы мал табибын тәүлекнең теләсә кайсы вакытында чакырта.

ЯЛЫ ДА, АКЧАСЫ ДА БУЛСЫН

Ун авылны берләштергән Яңа Кенәр җирлеге башлыгы Рафаэль Фәхретдинов белән дә әңгәмә корабыз. Җирлектә 1500 хуҗалык исәпләнә, барлыгы биш меңгә якын кеше яши икән. Берничә ел элек күршедәге өч авыл җирлеге берләштерелгән, аларның башлыклары Рафаэль Фәхретдиновның урынбасарларына әйләнгән.

Яңа Кенәрнең әллә каян елкылдап торган өр-яңа мәктәбендә 340 бала укый, клуб та, спорт мәйданчыклары да бар. Барысы да ал да гөл кебек. Тик шулай да халыкны бер мәсьәлә борчый:

– Авылларыбызда эш урыннары җитеп бетми. Элек монда яшелчә киптерү, агач эшкәртү, азык-төлек комбинатлары, кирпеч заводы һәм башка төрле җитештерүләр бар иде. Кызганыч, күбесе таралып, юкка чыкты. Бүген бит кешегә ялы һәм түләве яхшы булган эш кирәк, – дип аңлатты әңгәмәдәшем.

«АЧУЛАНСАҢ, СӨТЕН КИМЕТӘ»

Яңа Кенәрдән соң 2015 елда ветеринария пунктына ия булган Урта Курса авылына юл тоттык. Рафил Абдуллин үзләренең шәхси хуҗалыгында ике дистәгә якын мөгезле эре терлек асрый. Биш сыерның берсе буаз, дүртесеннән тәүлегенә 70–75 литр сөт савып алалар. Абдуллиннар, үзләренә ике-өч литр калдырып, калганын һәр литрына 17 сумнан тапшыралар. Рафил әфәнде сөтлебикәләрне соңгы тапкыр кул белән кайчан сауганнарын хәтерләми, бу эшне күптәннән автомат башкара.

Урта Курса авыл җирлеге башлыгы Рәмзия Вафина әйтүенчә, 2015 елдан шәхси ярдәмче хуҗалыкларга терлек биналары төзү өчен субсидия бирелә: биш сыер тотучыларга – 100 мең сум, сигез сыер асраучыларга – 200 мең сум.

Абдуллиннар бу мөмкинлектән файдаланып калырга өлгергән инде. Өч буаз таналары озакламый сыер булып җитешкәч, киләсе елда сөтлебикәләрнең саны, программа таләп иткәнчә, сигезгә җитәчәк. Былтыр Урта Курсада субсидия алу бәхетенә – дүрт, быел ике кеше ирешкән, тагын 13 кеше чиратта тора.

Авылда сөтне УАЗ машинасы белән Абдуллиннарның улы җыя. Егетнең буш вакыты күп булганга, хуҗалыктагы терлекнең көен көйләргә нигездә аңа туры килә. Рафил әфәнде һәм аның хатыны күмәк хуҗалыкта эшлиләр, терлек азыгын шуннан бирәләр.

Гаилә башлыгы бройлерлары белән үрдәкләрен дә күрсәтте.

– Үрдәкләр авырлыкны тиз җыеп, аяклары йөрмәс була. Хәлләрен җиңеләйтү өчен, витаминнар, балык мае бирәбез. Үгезләрне иткә дип үстерсәк, кош-кортны, суйгач, күчтәнәч итеп җибәрәбез. Мал тоту да, бәрәңге үстерү дә табыш китерә. Мәшәкате күп, иренмәскә генә кирәк, – диде ул.

Гаилә башлыгы безне Дочка кушаматлы аклы-каралы сыерлары белән дә таныштырды. Аңа биш яшь, колагында туган көне күрсәтелгән язу да эленеп тора.

– Әзрәк кенә ачулансаң да, хәзер үк сөтен дә киметә, янына да китерми. Нәкъ сабый шикелле. Һәр сыерның үз холкы, – диде гаилә башлыгы.

Дочканың калган өч ахирәте – Иркә, Ландыш һәм Кечкенә. Шунда ук җырчы Иркә белән Ландыш Нигъмәтҗанованың «Якын дус бераү генә» дигән җырлары искә төште. Абдуллиннарның сыерлары да үзара дус-татудыр, дип ышанам.

– Малларыгызның авырганы бармы? – дим.

– Авырыйлар инде. Бозаулагач, сыерда порез булырга, бозауларның эче китәргә мөмкин. Терлек, авырса, ашамый башлый, тизгә сыеклана, мөгезен тотып карасаң, температурасын белеп була. Көн саен шулар янында булгач, малның хәлен кәефеннән дә чамаларга мөмкин. Элек үгезләр бер-берсе белән сөзешеп, мөгезләрен йә яра, йә бөтенләй төшерә иде. Билгеле, яңасы үсеп чыкмый. Хәзер инде үгезләрне һәм башка эре терлекне, бәйдә тотып, сөзешүдән саклыйбыз.

Җирлек башлыгы Рәмзия Вафина сөйләвенчә, Урта Курсада халык хайванны күп асрый, 12 баш сыер тотучы гаиләләр дә бар. Җирлектәге алты авылның һәркайсында көтү чыга.

– Ветеринарлар бик кирәк. Авыруларны булдырмау максатында мал табибы шәхси хуҗалыклардагы терлеккә прививкалар ясый. Бер елны Алан авылында 14 сыерда лейкоз табылып, барысын да бетерделәр. Шуннан соң башка авылларда да, бөтен терлекне тикшереп, анализлары билгеле булмыйча, көтү кумадылар, – дип сөйләде җирлек башлыгы.

ДМИТРИЙ МЕДВЕДЕВ КЕР-ХАЙВАННЫҢ ИСЕМЕН ҮЗГӘРТТЕ

Урта Курса җирлегенә кергән Корайван авылының даны бөтен илгә таралды. 2013 елга кадәр ул Кер-Хайван дип аталды. Исеме килешле түгел, дип, халык канәгатьсезлек белдереп, район советы, Казан, Мәскәү депутатларына хатлар язды. Россия башкаласында халыкның гозерен ишеттеләр. 2013 елның мартында РФ Премьер-министры Дмитрий Медведев Кер-Хайван атамасын Корайванга алыштыру турындагы фәрманга кул куйды.

– Шушы сөенечтән соң авыл халкының тормышы үзгәрдеме? – дип сорыйм җирлек башлыгыннан.

– Корайван – бер урамлы кечкенә генә авыл. Кер-Хайван булып аталганда, авылда дөньяга килгән балаларның туган урыны итеп Арчаны яздыра башладылар. Без бит хәзер грамоталы, культуралы кешеләр, исем мәсьәләсенә сак карыйбыз. Авылның атамасын үзгәртергә дип, 1980–1990нчы елларда күтәрелеп карадык – барып чыкмады. Вакыты җиткәч, ниһаять, мәсьәлә хәл ителде. Авыл халкы паспортларындагы язуны да әкренләп үзгәртә, – дип сөйләде ул.

Участок ветеринария пунктларын төзү һәм капиталь төзекләндерү программасын финанслау күләме:

326,1 миллион сум

Участок ветеринария пунктлары төзелеше

2013 елда — **9**

2014 елда — **44** (һәр районда берешәр, шул исәптән берсе – Казанда)

2015 елда — **42** (терлекчелек зур үсеш алган районнарда)

2016 елда — **40** пункт төзү планлаштырыла (2015 елдагы принцип буенча)

Ветеринария хезмәте корылмаларын капиталь төзекләндерү программасын финанслау:

90 миллион сум

Ветеринария хезмәте биналарын һәм корылмаларын төзекләндерү

2014 елда — **17**

2015 елда — **18**

2016 елда — **23** пунктны төзекләндерү планлаштырыла

АТА МӘЧЕЛӘРНЕ «СӨННӘТКӘ УТЫРТАЛАР»

Урта Курса ветеринария бүлеге мөдире Гадел Газизуллин да мәктәптән соң кая укырга керергә аптырап тормаган, аның нәселендә дә мал табиблары бар. 16 ел эчендә үз эшенең остасына әйләнеп беткән инде ул, бүгенге көндә ун авыл белән ике агрокомплекстагы 1300 баш савым сыерына, бозауга хезмәт күрсәтә.

– Кайчандыр бу авылда ветеринария пункты булган, әмма җимерелеп беткән. Монысында эшлисе генә килеп тора, – диде ул.

Баксаң, пунктта гына түгел, күмәк хуҗалыкта да орлыкландыру буенча хезмәт күрсәтелә. Шуңа күрә бу өлкәдә ике оешма арасында көндәшлек күзәтелә. Авылда ата мәчеләрне «сөннәткә утыртырга» теләүчеләр дә табыла. Хезмәт түләве – ике мең сум. Айга бер көн, әйтик, соңгы җомгада моны бушлай башкаралар.

Даруханәдә атлар өчен файдалы матдәләр белән баетылган «чупа-чупс» та сатыла. Пунктның урам як тәрәзәсенә Гадел әфәнденең кесә телефон номеры күрсәтелгән кәгазь ябыштырылган.

Төнлә дә шалтыраталар, андый чакта барудан баш тартып булмый. Мөгезле эре терлеккә караганда, кош-кортның чирен ачыклау кыенрак. Диагноз кую өчен, кошларны район үзәгендәге лабораториягә җибәрәбез, – диде әңгәмәдәшем.

Курсада заманында циркта эшләгән кеше яши. Чир китә, гадәт китми, дигәндәй, ул кеше экзотик хайваннар да тота. Әмма маймылы, картаеп, быелгы кышта үлеп киткән.

– Быел бер хуҗалыкка төлке кереп, 11 тавыкны буган, өчесен алып киткән, сигезе үлгән. Бәхеткә, быел котырган төлке очрамады. Гадәттә, андыйларны Арчага алып барып, крематорийда яндырабыз, – диде.

Ринат Фәйзрахманов, Арча районы дәүләт ветеринария берләшмәсе җитәкчесе:

– Арча районында иске ветеринария пунктлары калмады диярлек, алар, 1940–1950нче елларда төзелеп, тузып бетте. Республика программасы буенча беренче ветеринария пункты 2014 елда – Яңа Кенәргә, 2015 елда Урта Курсага кайтартылды, быел Түбән Аты белән Шушмабаш авылларында урнаштырыла. Терлек саны кайда күбрәк, пунктларны, беренче чиратта, шунда ачабыз. Әйтик, Урта Курсадагы «Ак барс» агрофирмасында гына да 1200 баш терлек исәпләнә.

Яз көне котыру, түләмәгә (сибирская язва) каршы вакцинацияләү үткәргәндә, шәхси хуҗалыклардагы мал санының, ким дигәндә, ун башка артуына игътибар иттек. Сөт тапшырудан да акча яхшы керә, вакытында биреп баралар, бу мәсьәләне район башлыгы шәхси контрольдә тота.

Быел инкубатордан алынган чебешләргә субсидия бирелә башлады: дәүләт тавык белән бройлерлар өчен – 30 сум, үрдәкләр өчен – 80 сум, казлар өчен 100 сумны кайтара. Республикада терлек саны буенча Арча районы алда бара, бездә 54 мең терлек исәпләнә, икенче урында – Балтач, аларда 53 мең баш.

PRESSA.RU

СЕЗНЕҢ УҢЫШ КЕЙСЫ

Дәрес темасы «ике икең» кебек гади – футболка төрүнең японча ысулы… Лектор көчле тавыш белән ачык итеп сөйли, әмма аның каршында утыручыларның күзләрендә сорау билгесе – көндәлек тормышны җиңеләйтә торган хәйләгә тыңлап кына өйрәнеп булмый икән. Ә менә шушылай итеп сакчыл җитештерү серләренә яки дәүләт сатып алуларына төшенү җиңел, дип уйлыйсызмы?

Автор:
Катерина Котова

ФУТБОЛКА… ДӘЛИЛ БУЛАРАК

Сүз уңаеннан, бу гади генә дәрес түгел. Укучылар урынында педагоглар үзе. Бүген алар үзләренең укыту барышында куллана орган ысулларының ни дәрәҗәдә «үтемле» булуын үз күзләре белән күрә.

– Тикшеренүләр күрсәткәнчә, классик лекция барышында материалның нибары биш проценты гына үзләштерелә, – дип сөйли КФУның Дәүләт һәм муниципаль идарәнең югары мәктәбе директорының беренче урынбасары Галина Маштакова. – Практика һәм тренинглар ярдәмендә материалны үзләштерү күрсәткечен 80 процентка кадәр күтәрергә була!

Шушы сүзләрне раслагандай, тренер катнашучылар белән футболка төрү мисалында өйрәтү алгоритмнарын тикшерә башлый. Нәтиҗәдә японнарның хәйләкәр зирәклеге бергәләп эшләнгән гамәлләр алгоритмнары аша үзләштерелә һәм шушы алгоритм операцияләрне кабатлау аша ныгытып куела.

Мәгълүмат бирүнең әлеге ысулы – аны кулланганда уку төркемендә «бишле»гә укучыларның саны 90 процентка җитәргә мөмкин – күренекле совет психологы Петр Гальперин тарафыннан эшләнгән һәм шушы көнгә кадәр иң алдынгылардан санала. Шуңа охшаш технологияләрне көнбатыш компанияләре хезмәткәрләрен өйрәткәндә куллана, мәсәлән, Toyota җитештергәндә – TWI ысулы белән укыту. Тренингларда өлкәннәрне укыту буенча белгеч Дэвид Колб ысулы кулланыла. Күпчелек бизнес-тренерлар боларны традицион ысуллардан күпкә нәтиҗәлерәк дип таба. КФУның Дәүләт һәм муниципаль идарәнең югары мәктәбе дә калышмаска булган. Ләкин дәүләт хезмәткәрләренең квалификациясен күтәрү программаларында алдынгы коралларны куллану өчен башта педагогларның үзләрен укытырга кирәк.

– Ел дәвамында безнең мәктәптә квалификация күтәрү курсларында 3,5 меңнән артык кеше укып чыга, – дип сөйли КФУның Дәүләт һәм муниципаль идарәнең югары мәктәбе директоры Игорь Привалов. – Әлбәттә, педаголарның үзләренең әзерлек дәрәҗәсе мәсьәләсе көн кадагына баса. Өстәвенә, бездә югары уку йортлары мөгаллимнәре дә, дәүләт хезмәтендәге кешеләр дә дәресләр алып бара. Беренчеләре укыту ысулларын белә, ләкин, кызганычка каршы, дәүләт һәм муниципаль хезмәткәрләрнең эшчәнлегенең үзенчәлеген аңлап җиткерми. Икенчеләре – үз эшенең остасы, әмма аларны укытырга өйрәтәсе бар. Аларны башка уку-укыту учреждениеләренә дә җибәрергә булыр иде, шулай да без әлеге ике төркем өчен мәктәпнең эшчәнлеге үзенчәлекләрен истә тотып, тренинглар программасын үзебез эшләргә булдык.

Фото КФУның Дәүләт һәм муниципаль идарәнең югары мәктәбе архивыннан

БЕЛЕМНӘР САНДЫГЫ

Мәктәптә укыту ысулларын яңадан карау идеясе Президент Аппаратының Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты башлангычы белән туган. Ул дәүләт һәм муниципаль хезмәттәге персонал белән идарә итү өлкәсендә күп кенә башлангычларның авторы булып тора.

Мәктәп өчен яңа булган әлеге ысул берничә тапкыр уңышлы кулланылган инде. Шуның бер мисалы – муниципаль районнарның башкарма комитеты җитәкчеләре өчен программа. Ул вакытта мәктәп хезмәткәрләре кейс ысулын кулланган: бу вакытта катнашучылар территорияләрнең проблемалары турында фикер алышуда турыдан-туры катнаша. Укытучы чынбарлыктагы вазгыятьнең моделен төзергә һәм, укытуның алдынгы ысулларын кулланып, фикер алышуга катнашучыларның һәркайсын җәлеп итәргә тиеш. Катнашучы исә тәгаен проблеманы максималь дәрәҗәдә нәтиҗәле хәл итү юлын табарга бурычлы.

Шушы вакыт эчендә программада катнашучылар уйлап чыгарылган «Максат» дигән республикада яшәгәннәр. «Максат»ның дүрт муниципаль берәмлеге Татарстан республикасының күп кенә районнарына хас булган проблемалар алдына куелган.

Бизнес-симуляция өч көн дәвам иткән. Шушы вакыт эчендә программада катнашучылар уйлап чыгарылган «Максат» дигән республикада яшәгәннәр. «Максат»ның дүрт муниципаль берәмлеге Татарстан республикасының күп кенә районнарына хас булган проблемалар алдына куелган. Җирлектәге экологик вазгыятьне ничек үзгәртергә? Тузган коммуникация челтәрен яңартуга акча каян табарга? Районда сәламәтлек саклау сыйфатын ничек күтәрергә һәм аны ничек итеп халыкка якынрак итәргә? Шушы һәм башка сораулар буенча чынбарлыкта куллану мөмкинлеге булган карарлар кабул итүнең алгоритмнары эшләнгән.

– Әлеге программада катнашучы белән без элемтә булдыра алдык, – дип сөйли Галина Маштакова. – Нәтиҗәләр шул дәрәҗәдә сокландырды ки, без уйлана калдык: кейс ысулын алдынгы программалар белән беррәттән безнең башка программаларда да кулланмаска микән? Һәм әгәр 2016 елда без курслар тематикасына һәм уку-укытуның озынлыгына күп кенә үзгәрешләр керткән булсак, быел исә төп бурыч – барлык модульләр өчен дә кейслар эшләп, күнекмәләрне практикада куллануга зур игътибар бирү. Безнең мөгаллимнәр составы бар, хәзер безгә аларның дәресләрне башка төрле итеп үткәрүе кирәк. Педагоглар укытуның алдынгы ысулларын кулланырга мәҗбүр. Һәм без укытучыларның бу процесста катнашырга теләвен дә күрәбез.

БАРЫСЫ ДА ӨЛКӘННӘРЧӘ

«Тренерлар тренингы»нда катнашучыларга гадидән катлаулыга һәм аерымнан гомумигә түгел, ә катлаулыдан катлаулыга һәм гомумидән аерымга таба барырга тәкъдим ителә. Куркыныч яңгырый, әмма чынлыкта бу курсларны эшләүчеләрнең иң югары отышлы нәтиҗәгә исәп тотуын аңлата. Өстәвенә, укучының башлангыч әзерлек дәрәҗәсенә бәйсез рәвештә.

Биредә бар да «өлкәннәрчә». Катнашучыларны шунда ук тренинглар дөньясына чумдыралар – хәтта әлегә «йөзә белмәгәннәр»не дә. Төркемнәргә бүләләр, биремнәр өләшәләр: билгеле бер темага тренинг яки проблемалы лекция сценариен эшләргә. Аны экспертлар комиссиясенә тәкъдим итеп, якларга кирәк булачак. Шаярып торырга урын калмый биредә.

Менә төркемнәрнең берсе «Кыяр үстерү» темасы белән чыга. Тренерның беренче алымы – аудиториянең игътибарын күз ачып йомганчы үзенә җәлеп итү – менә дигән итеп эшләнгән. Кыярның Россия тарихындагы урыны турында сөйләгәндә, тыныч кына калып буламы соң инде? Алга таба тыңлаучылар кыярларның төрләрен үзләштерә, аларны консервлау серләренә өйрәнә. Темасы шаярулы, әмма кораллары – җитди, ә иң мөһиме – алдынгы. Проблемалы лекция, эшлекле уен, дискуссия, тренинг... һәм нәтиҗә буларак – катнашучыларның барысы да укыту процессына җәлеп ителгән. Нәтиҗә бар, презентация вакытындагы киткән хаталар өстендә эш үткәрелгән. Хәзер инде җитдирәк темаларга да алынырга була, мәсәлән, коррупциягә каршы көрәш, республикага инвестицияләр җәлеп итү яки туристлар агымын көчәйтү.

КФУның Дәүләт һәм муниципаль идарәнең югары мәктәбендә үзләренең педагоглары өчен оештырылган әлеге сессия гадәттәгечә – өйгә эш белән тәмамлана. Аларның һәркайсы укытуның алдынгы ысуллары белән коралланып (экспертлар ярдәм белән, әлбәттә), үзләренең темасы буенча укытуның яңа программасын төзи. Республикадагы көн кадагындагы проблемаларны хәл итүгә юнәлтелгән актуаль кейслар яңа кораллар үзләштерергә һәм яңа белемнәр алырга гына ярдәм итеп калмый, укырга, камилләшергә һәм республикага файда китерергә дә өйрәтә.

PRESSA.RU

ИДЕЛ БУЕНДА БАСУ КӨННӘРЕ: «ХАЛЫКНЫ ҮЗЕБЕЗНЕКЕН САТЫП АЛЫРГА ТӘРБИЯЛӘГЕЗ!»

«Идел буенда Халыкара басу көннәре» Лаеш районының визит карточкасына әйләнде инде. 29 июньнән 2 июльгә кадәр биредә тәҗрибә басуларында инновацияле-технологияләр күргәзмә-форумы узды. Россиянең 27 төбәгеннән һәм 8 чит илдән килгән 160 компания, институт, дәүләт оешмасы һәм ассоциацияләр үсемлекчелектәге, терлекчелектәге һәм авыл хуҗалыгы техникасындагы яңалыклар белән таныштырдылар. Проблемалар турында фикер алыштылар. Андыйларның азрак булуы сөендерә, һәм аларны хәл итү юллары да табыла.

Автор:
Владимир Матылицкий

– Быел, һава торышы комачау итмәсә, Авыл хуҗалыгы министрлыгы бөртеклеләрдән 106 миллион тонна, шикәр чөгендереннән 40 миллион тонна, майлы культуралардан 14-15 миллион тонна уңыш җыеп алырга исәп тота, – дип белдерде Россия Авыл хуҗалыгы министрлыгының Үсемлекчелек, механикалаштыру, химияләштерү һәм үсемлекләрне саклау департаменты директоры Петр Чекмарев «Агросәнәгать комплексы бүген. Проблемалар, бурычлар һәм аларны хәл итү юллары» форумы барышында. – Бәрәңге азрак булачак, аз утырттык, ә менә ачык һавадагы яшелчәләр белән ил үзен тәэмин итә алачак.

КАРАР №1: ИМПОРТ ТҮГЕЛ, Ә ТӘРБИЯ

Теплицада үстерелә торган яшелчә 1 миллион тонна җитешми. Россиягә тагын 2 мең гектар теплица кирәк, төзелеш бара, әмма әкрен. Импортсыз булмый. ТР Фермерлар һәм крестьяннар хуҗалыклары ассоциациясе рәисе Камияр Байтимеровны да борчый бу мәсьәлә. Ул Россиягә янә Төркиядән яшелчәләр агымы керер, дип курка, таможняда киртәләрне көчәйтергә кирәк, ди.

– Безне бернинди киртәләр дә коткармаячак. Халыкны тәрбияләгез, үзебезнекен сатып алсыннар, – дип җавап бирде Чекмарев. – Шуның белән экологик яктан чиста, тәмле азык-төлек җитештерә торган күршегезгә, дустыгызга, туганыгызга ярдәм итәрсез, ә чит илләр эшкуарларының салым акчасына коралланa торган НАТОга түгел.

КАРАР №2: ВАЛЮТАГА ТҮГЕЛ, СУМНАРГА

Урып-җыю барышы техниканың әзерлегенә бәйле, әмма валюта үсеше аркасында агросәнәгать комплексында проблема: 160 мең берәмлек трактор, 20–30 процент урып-җыю комбайны җитми, ә булганнарының 40 проценты ун ел элек сатып алынган. Ләкин сумнарга да яхшы техника сатып алып була: **Питер тракторын, Тамбовның TERRIONын, Белоруссиянең МТЗын. Күргәзмәдә дә Ростов белән Гомельдән килгән тракторлар кызыксыну уятты.**

КАРАР №3: САТЫП АЛУЛАР ТҮГЕЛ, СУБСИДИЯЛӘР

Петр Чекмарев сүзләренә караганда, орлыклар күргәзмәсе иң яхшыларны куйган иде: Идел буе федераль округы һәм Татарстан территориясе өчен районлаштырылган сортлар гектарыннан 10 тоннага кадәр уңыш бирә. РФ Авыл хуҗалыгы министрлыгы алдында бурыч тора: шикәр чөгендере, кукуруз, бәрәңге, көнбагыш орлыклары буенча импортны алыштырырга. **Бәрәңге һәм яшелчә культуралары буенча гектарлата субсидияләр кертелгән. Орлыклар сатып алуга да субсидияләр бирелә. Орлык заводлары төзелешенә дә 20 процент чыгымнарны каплау һәм субсидияләр бирү буенча карарлар кабул ителгән.**

КАРАР №4: КӨНДӘШЛЕК ТҮГЕЛ, Ә ЭШКӘРТҮ

Идел буе сатуга чыгарыла торган алмалары белән көньяк төбәкләргә көндәш була алмый, ләкин монда, Чекмарев сүзләренә караганда, алмаларны эшкәртү белән шөгыльләнеп була: соклар сыгарга, измә һәм башка ризыклар әзерләргә. Ә Татарстанга җиләкләр белән шөгыльләнү яхшырак – алар биредә югары сыйфатлы мул уңыш бирә. **Һәм сөенечле яңалык – 2017 елда бакчаларга дигән субсидияләр ике тапкырга артачак.**

КАРАР №5: ЯҢГЫРЛЫ ТҮГЕЛ, Ә КОРЫЛЫКЛЫ УРЫННАРДА

Россиядә 19 миллион тонна ашлама җитештерелә, ләкин шуның 2,5 миллион тоннасы гына кулланыла. Калганын чит илләр сатып алып, безнең ашламаларда яшелчә үстерә, Россиягә алып килә һәм безнең АСК белән көндәшлек итә. **Сүз уңаеннан, 2017 елда субсидия биргәндә, «геотермик» коэффициент кертеләчәк: ашламаларның нәтиҗәлелеге азрак булган коры төбәкләрдә дымлылык җитәрлек булган төбәкләргә караганда, субсидияләр югарырак булачак.**

КАРАР №6: САТЫП АЛАСЫ ТҮГЕЛ, Ә РЕМОНТЛЫЙСЫ

Яңгыраган планнарга караганда, Россиянең АСК проблемалары Татарстанга кагылмый.

Техника сатып алу ягыннан гына актуаль: хәзерге вакытта йөз гектарга 154 ат көче булган куәтләрне, аз дигәндә, 200гә җиткерергә. Импорттан кергән техниканың 2000нән артыграк детале һәм ремонтлау төеннәре үзләштерелгән, бәяләре оригиналдан 1,5–2 тапкыр арзанрак. Техниканы яңадан эшкә кайтару 5–6 тапкырга арзанракка төшә. **Аерым төеннәрне һәм агрегатларны, электрон системаларны, трактор һәм комбайннарның идарә итү блокларын капиталь ремонтлау эше үзләштерелгән. Авыл инженерлык үзәкләре булдырылган.**

Николай Титов, ТР авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрының беренче урынбасары:

– Татарстанның агросәнәгать комплексы авыл хуҗалыгы продукциясен тулай җитештерү буенча 4нче урында тора. 2015 елда хуҗалыкларның барлык категорияләрендә 214 миллиард сумлык азык-төлек җитештерелгән. Республикада 3,4 миллион гектар чәчүлек җирләре, миллионнан артык мөгезле эре терлек, 357 мең сарык һәм кәҗә, 16 миллионнан артык кош асрала. Азык-төлек сәнәгате буенча меңнән артык предприятие бар, күбесе иң яңа технологияле эшкәртү линияләренә ия.

СЫЙФАТ БИЛГЕСЕ

**«Татарстан» журналы яхшыларның да иң яхшыларын тәкъдим итә:
иң яхшы предприятиеләр, иң яхшы җитәкчеләр, профессионаллар Россиянең горурлыгы.**

Әлеге дәрәҗәле премияләр җиңүчеләре турында тулырак бүгенге санда укыгыз.

«Елның иң яхшы предприятиесе» Халыкара премиясе Россия эшкуарлыкны үстерүгә ярдәм итү фонды тарафыннан булдырыла һәм Россия Федерациясе территориясендә эшли торган, үз юнәлешләрендә югары нәтиҗәләргә һәм социаль-икътисадый күрсәткечләргә ирешкән үз илебездәге һәм чит ил предприятиеләренә бирелә.

Проектның максаты – Россия бизнесының яңа имиджын булдыру. Бүген күп кенә Россия предприятиеләре үзләрендә югары рентабельлекне, базарда тотрыклы урын тотуны һәм интенсив үсешне берләштерә. Нәкъ менә шундый предприятиеләр илдәге икътисадның «геройларына» әйләнә һәм илнең яңа икътисадый элитасын тәшкил итә.

«Ел җитәкчесе» премиясенә номинацияләнүчеләр дәүләт статистикасы органнары тарафыннан тәкъдим ителгән объектив мәгълүматлардан чыгып ачыклана – шулай итеп җиңүчеләрне сайлауда алдан ук ялгыш булу фикере юкка чыгарыла.

Номинацияләнүчеләрне сайлап алуның беренче этабы үз эченә катнашучыларны төбәкләр, эшчәнлек төрләре, хезмәткәрләр саны һәм катнашучының анкетада чагылдырылган башка күрсәткечләре буенча «аралауны» ала. Икенче этапта катнашучы компанияләрнең хисап чоры өчен икътисадый күрсәткечләренә анализ ясала. Шулай итеп, нәкъ менә көндәшләре белән чагыштырганда яхшырак күрсәткечле компанияләр Эшмәкәрлекне үстерүгә ярдәм итү фонды методологлары тарафыннан номинацияләнүчеләр исемлегенә кертелә һәм бүләкләү тантанасына чакырулар ала.

«Профессионаллар – Россиянең горурлыгы» Бөтенроссия милли премиясе. Премия РФ Дәүләт Думасы депутатлары һәм Россия төбәкләренең Сәүдә-сәнәгать палаталары җитәкчеләре ярдәме белән Иҗтимагый танылу халыкара академиясе тарафыннан булдырыла.

Премия үз алдына РФ Президенты һәм Хөкүмәтенең көндәшлеккә сәләтле базар икътисадын тәэмин итү сәясәтенә ярдәм, Россия эшкуарлары традицияләрен саклау һәм үстерү, шулай ук икътисад һәм социаль өлкәләрнең төрле тармакларында эшли торган Россия предприятиеләренең иң яхшыларын бүләкләүне төп максат итеп куя. Бәйсез бәя бирү нигезендә премия илебез бизнесының лидерларын ачыклый, алар тарафыннан тормышка ашырыла торган проектларга потенциаль инвесторларны җәлеп итә һәм, шул рәвешле, Россия базарында аларның статусын һәм конкурентлыкка сәләтлелеген ныгытуга ярдәм итә.

Номинантлар исемлеге иҗтимагый танылу халыкара академиясенең эксперт советы соравы буенча тутырылган төбәк ССПларының тәкъдим хатлары нигезендә төзелә.

PRESSA.RU

ПРОЕКТТАГЫ КИЛӘЧӘК

«Таткабель»нең югары вольтлы сынау станциясе

КВЗ. Агрегат-җыю корпусы. Казан шәһәре


«Лужники» ЗСА реконструкцияләү, Мәскәү шәһәре

Иннополис. Уку һәм спорт корпуслары

«Сколково»да «Татнефть» ФТҮ» ГАҖ

«Капитал булу һәм аның белән идарә итү бик зур социаль җаваплылык белән бәйле, ул Ватанга хезмәт итүнең аерым төре булып тора... һәм дәүләт белән эшмәкәрлекнең үзара уңышлы мөнәсәбәтенең нигезен тәшкил итә», – дип билгеләп үтте үзенең «Милли икътисад элитасы» лауреатларына мөрәҗәгатендә Татарстан Республикасыннан Россия Федерациясе Федераль Җыенының Федерация Советы әгъзасы Олег Морозов. Быел премияләр тапшыру тантанасында шуңа да игътибар юнәлттеләр: җиңүче предприятиеләр катлаулы яңача икътисадый чынбарлык шартларында да әлеге принципка тугры калалар.

«Милли икътисад элитасы» премиясенең «Ел предприятиесе» номинациясендәге лауреат булган «Казан Гипронииавиапром» АҖен заказчылар, көндәш предприятиеләр, төбәк җитәкчелеге, үз хезмәткәрләре алдына куелган югары дәрәҗәдәге җаваплылык кына түгел, ә сәнәгать һәм оборона комплексы предприятиеләре өчен алдынгы технологик карарларны проектлауны өйрәнү һәм аннан соң аларны гамәлгә кертү башкалардан аерып тора. Бүген институтның өстенлекле юнәлешләре – сәнәгать объектларын, шул исәптән җитештерү линияләрен, транспорт һәм инженерлык инфраструктурасы объектларын, торак йортлар һәм җәмәгать биналарын, шәһәр төзелешен проектлаштыру, авиация сәнәгате һәм инфраструктурасы өлкәсендә проектлаштыру.

«Казан Гипронииавиапром» компанияләр төркеме инженерлык проектлаштыруы, технологик апробацияләү, технологик һәм махсус җиһазлар белән тәэмин итү һәм хезмәт күрсәтү белән бәйле булган комплекслы карарлар эшләү буенча хезмәтләр күрсәтә.

Үзенең казанышлары өчен институт күбесенчә данлы үткәненә рәхмәтле. XX гасырның 40 нчы елларында «Гипроавиапром» Мәскәү авиация сәнәгате проект институтының Казанга эвакуацияләнгән белгечләренең төп бурычы булып эвакуацияләнгән авиация предприятиеләрен реконструкцияләү өчен проект документациясе эшләү була. Әлеге эш институтның алга таба үсеше өчен ныклы нигез булып тора. 2015 елда «Казан Гипронииавиапром» эшчәнлегенең төп юнәлешләренең берсе яңа әйләнеш ясады: институт проектчылары очкычлар, авиация двигательләре һәм Россия авиация һәм мотор заводлары өчен башка авиация техникасы чыгару буенча проект һәм эш документациясен булдыру буенча эшләрнең шактый зур күләмен башкардылар.

Институт җитештерүне реконструкцияләү һәм техник яктан яңадан коралландыру проектларын эшләгән заказчылар исәбендә Казан вертолёт заводы (Ми-17, Ми-38, «Ансат», «Актай» вертолётларын чыгаруны тәэмин итү), С.П. Горбунов исемендәге КАҖБ – КАЗ («Туполев» ГАҖ филиалы), «Авиастар-СП» АҖнең Ульяновск авиация заводы, Воронеж самолёт төзелеше акционерлык җәмгыяте, Смоленск авиация заводы, Уфа агрегат җитештерү берләшмәсе, Уфа моторлар төзелеше җитештерү берләшмәсе, Пермь моторлар заводы, «Салют» газ турбиналары төзелеше ФҖҮ» АҖ (Мәскәү шәһәре), «Салют» ГАҖ (Самара шәһәре) кебек стратегик предприятиеләр бар.

2015 елда институт территориаль проектлаштыру буенча берничә проект эшләде. Әлеге юнәлешне үстерү 2006 елда «Алабуга» МИЗ проекты буенча эштән башланып китте. Узган елда «Казан Гипронииавиапромы» белгечләре МИЗнда техник-гамәлгә кертү тибындагы «Иннополис» объектлары (Татарстанның Югары Ослан муниципаль районы), «Алабуга» МИЗ (Ford автомобильләре җитештерү буенча

Реклама

Газ-турбина двигательләре җитештерү. «Климов» АҖ. Санкт-Петербург шәһәре

МДФ заводы. «Алабуга» МИЗ

Ford автомобильләрен җитештерү заводы. «Алабуга» МИЗ

заводлар, Ford двигательләре, МДФ, ДСП, ОСБ плитәләре), «Чердаклы районы» муниципаль берәмлеге территориясендә (Ульяновск өлкәсе) порт МИЗн төзү буенча проект һәм эшче документация эшләүне алып бардылар. «Байкал капкалары» МИЗ проекты буенча эш тә дәвам итә.

2015 елда «Казан Гипронииавиапром» белгечләре катнашында 2018 елда узачак дөнья чемпионатына «Лужники» Зур спорт аренасын (Мәскәү ш.), Дмитров төбәкара мультимодаль логистика үзәген, «Татнефть» ГАҖнең «Сколково»дагы фәнни-техник үзәген реконструкцияләү проекты тормышка ашырылды. «Электродепо – Лихоборы» Мәскәү метрополитены объекты проекты буенча эшләр дәвам итә.

Институт белгечләренең үз эшләрен югары дәрәҗәдә белүе, проектлаштыруның иң яңа коралларын һәм ысулларын куллану, инженерлык һәм җитештерү карарлары өлкәсендә эшләнмәләрнең җитди базасы аркасында институт бик күп юнәлештәге масштаблы проектларны – төзелеш объектларын төзүдән алып, тар профильле җитештерүләрне техник яктан яңадан җиһазлауга кадәр – тормышка ашыруда катнаша. Шулай итеп, «Казан Гипронииавиапромы» Россиянең төрле төбәкләрендә 20дән артык төзелеш объектында техник заказчы һәм генераль подрядчы функцияләрен башкара. 2015 елда аларның берничәсе эксплуатациягә тапшырылды, шул исәптән «Климов» АҖдә (Санкт-Петербург ш.) термик эшкәртү һәм ябыштыру корпусы һәм сынау стендлары, «Деталь» ААҖндә электрофизик корпус (Свердловск өлкәсенең Каменск-Уральск ш.). «Салют» ААҖндә реконструкцияләү тәмамланды һәм җитештерү эшләтеп җибәрелде.

«Казан Гипронииавиапромы» инжиниринг компаниясе белгечләре җитештерү компонентларын чит илдә җитештерелгәннәрне алмаштыруны күздә тоткан проектлар өстендә эшли. Шулай итеп, «Серго исемендәге завод»ның (Яшел Үзән ш.) ике цехын реконструкцияләү кысаларында технологик җиһазлар куелды. Моңардан тыш, «Тактик ракета коралларының корпорациясе» АҖ (Королёв ш.) өчен җиһазлар, Казан электромеханика заводы (Казан ш.), «Сәгать сәнәгате фәнни-тикшеренү институты» ААҖ (Мәскәү ш.), «Рейтинг» техник хезмәт күрсәтү үзәге (Жуковск ш.) өчен вибростендлар кую, монтажлау һәм эшләтеп җибәрү башкарылды. Институт белгечләре әлеге барлык объектларда да сервис хезмәте күрсәтәләр.

Институт казанышлары төбәк һәм федераль дәрәҗәләрдәге күпсанлы бүләкләр белән билгеләп үтелгән. Мәсәлән, институт 2009 һәм 2014 елларда Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең сыйфат өчен премиясе лауреаты булды. Предприятиенең динамик үсешендә аның җитәкчесе «Казан Гипронииавиапром»ын 30 елга якын җитәкләгән Борис Тихомиров зур роль уйный. Тәҗрибәле һәм сизгер җитәкче, ул өметле идеяләр таба һәм аларны тормышка ашыру максатына бөтен коллективны бергә туплый белә. Шуның нәтиҗәсендә институт хәтта яңа, Россия практикасында киң кулланыш тапмаган проектларда да уңышларга ирешә. Сүз уңаеннан, «Казан Гипронииавиапром» АҖ 2016 елда BIM*-лидер булды. Бу белемнәр һәм мөмкинлекләргә югары бәя. BIM-лидер статусын илебезнең BIM технологияләре ярдәмендә югары нәтиҗәләргә ирешкән архитектура-төзелеш компанияләре һәм экспертлары түгел, ә иң мөһиме, архитектура-төзелеш җәмгыятенең башка катнашучылары белән үз белемнәре белән уртаклашырга әзер торучылар ала, моны 2014 һәм 2015 елларда Autodesk Innovation Awards** та җиңү дә раслый.

Күпьеллык хезмәт стажы һәм төрле катлаулы икътисадый һәм базар каршылыкларын җиңеп чыгу, дөрес курс сайлый белү һәм иң мөһиме – үз һөнәренең осталарыннан тупланган командасы «Казан Гипронииавиапром»ына киләчәккә кыю карарга гына түгел, ә аны проектларга да ярдәм итә. Предприятиенең соңгы биш елдагы девизының «Киләчәкне проектлаштырабыз» дип яңгыравы да очраклы түгел!

* BIM – архитектура-төзелеш өлкәсендә технология.

** Autodesk Innovation Awards – архитектура-төзелеш тармагындагы проектларның ачык бәйгесе.

75 КАЗАНСКИЙ ГИПРОНИИАВИАПРОМ

420127, Казан шәһәре, Дементьев урамы, 1
Тел. (843) 571-95-48, факс (843) 571-96-56

PRESSA.RU

ЭТАЛОН:
ҮРНӘК СЫЙФАТ

2011 елда «Эталон» Казан тәҗрибә заводы» ААҖ банкротлык чигендә тора иде. Бүген исә ул – тотрыклы рәвештә эшләп килә торган предприятие.

Предприятие тарафыннан биш ел дәвамында үтелгән юлны саннар ачык күрсәтә. 2011 ел нәтиҗәләре буенча «Эталон» Казан тәҗрибә заводы» ААҖ тулаем продукты 15 млн сум тәшкил итә иде, берләштерелгән кредит бурычы – 10 млн сумга, ә хезмәт хакы буенча бурыч күләме 2 млн сумга җиткән. 2015 елда предприятиенең кереме 24 млн сум тәшкил итте, кредит бурычы 3 млн сумга калган, хезмәт хакы буенча бурычның инде менә өч елдан артык булганы юк.

«Эталон» заводының генераль директоры Борис Колик, «батып бара торган» предприятиене 2011 елда җитәкли башлый, мондый күрсәткечләргә ирешергә мөмкинлек биргән чаралар турында сөйли:

– Финанс хәлен яхшырту җитештерүнең күләмен зурдан кубып арттыру хисабына түгел (без эшли торган базар күләмгә карата шактый тотрыклы бит), ә чыгымнарны оптимальләштерү бәрабәренә ирешелде. Әйтик, административ-идарә персоналын тотуга каралган еллык чыгымнар 6 млн сумнан 2,5 млн сумга кадәр киметелде. Хезмәт күрсәтү буенча функцияләрнең бер өлеше безнең тарафтан аутсорсингка тапшырылды. Без ресурслар белән тәэмин итә торган оешмалар белән турыдан-туры эшли башладык, шул рәвешле арадашчылардан котылдык. Күрелгән әлеге чаралар кредит бурычын кыскартырга гына түгел, ә предприятиедәге хезмәт хакы күләмен күтәрергә дә ярдәм итте.

Заводны уникаль дип атарга мөмкин: «Эталон» – ул мерник дип атала торган махсус приборларның барлык спектрын җитештерә торган Россиядәге бердәнбер предприятие. Әлеге әсбаплар технологик сыеклыкларның күләмен үлчәү өчен һәм әзер продукцияне агызган чакта кулланыла.

«Эталон» заводы беренче разрядлы мерникларны нигездә Россиянең якынча 25 төбәгенә Росстандарт системасы оешмалары өчен китерә, шул рәвешле илнең әлеге приборларга булган ихтыяҗының 40%ка кадәр өлешен канәгатьләндерә. Росстандартның төбәк бүлекчәләреннән тыш, беренче разрядлы мерникларны кулланучылар булып фәнни-тикшеренү институтлары тора.

«Эталон» продукциясен кулланучыларның тагын бер эре төркеме – спирт һәм шәраб-аракы сәнәгате предприятиеләре. Аларның бер өлеше, үз җитештерүләрен камилләштереп, Казанда аерым приборлар гына түгел, ә тулы бер җитештерү линияләренә дә заказ бирә. Мәсәлән, 2016 елның февралендә «Эталон» Инкерман маркалы шәраблар заводына (Севастополь ш.) агызу линиясе китерде. Ә махсус җитештерелгән техник мерник исә хәзер әрмән маркалы коньякларны агызу өчен «Мульти-Групп» концернының Белоруссиядәге филиалы тарафыннан кулланыла.

Шуңа да карамастан, хәзерге вакытта предприятенең төп заказчылары – Россиянең автомобильләргә ягулык салу станцияләренең киң тармаклы челтәренә ия булган нефть эшкәртү компанияләре, алар рәтендә «Роснефть», «Башнефть» һәм башкалар.

«Эталон»да чыгарыла торган мерникларның сыйфаты Казанда урнашкан Бөтенроссия расходометрия фәнни-тикшеренү институты белгечләре тарафыннан гарантияләнә.

– Бүгенге көндә тикшерүче (тикшерү лабораториясе белгече) шәхесе закон тарафыннан регламентланмый: мерникларны куллана торган компания төбәк стандартлаштыру һәм метрология үзәкләренә яки аккредитация алган башка оешмаларга мөрәҗәгать итә ала, яки үзендә штатта торучы тикшерүчеле булырга мөмкин. Безнең продукция БРФТИ белгечләре тарафыннан тикшерелә, алар белән чын партнёрлык элемтәләре урнаштырдык инде. Бәлки шуңа күрәдер дә инде күп еллар дәвамында без метрология юнәлешендә кулланучылардан бер генә дә дәгъва алмадык, – дип сөйли Борис Александрович.

2012 елдан предприятие җитештерүне модернизацияләү программасын тормышка ашыра, аның нәтиҗәсе булып чыгара торган продукциянең аерым өлешләрен унификацияләү һәм буяу технологияләрен камилләштерү тора. Базарындагы чикле күләмнән тыш, предприятиедәге күләмне арттыруны тармактагы намуслы көндәшлек тыеп тора. Шулай ук соңгы елларда предприятие салым инспекциясенең чамадан тыш зур игътибары астында тора.

Ә «Эталон»ның өстенлекле максаты – завод заказлары портфелендә Татарстан компанияләре өлешен арттыру. Без төгәл вакытларны билгеләдек: 2016 елның икенче яртысы – 2017 ел. Хәзерге вакытта «Татспиртпром» компаниясе, шулай ук Татарстанның эре нефть эшкәртүче компанияләре белән сөйләшүләр алып барыла. Һәм бу юнәлештә республика җитәкчелегенең чын ярдәмен тоябыз.

Реклама

МӘГЪЛҮМАТНЫҢ ҮТӘКҮРЕНМӘЛЕЛЕГЕ – НАМУСЛЫ ЭШ ГАРАНТЫ

Россиянең «Ел җитәкчесе – 2016» милли премиясе җиңүчеләренең берсе булып Казан шәһәренең Бердәм исәп-хисап үзәге генераль директоры Дмитрий Анисимов танылды.

Оешма 2011 елда төзелде, әмма аның эшчәнлегенең актив фазасы 2014 елның мартында Дмитрий Анисимов килгәннән соң башланды.

Бүген БИХҮ –Татарстан башкаласындагы торак-коммуналь хезмәтләр өчен исәпләүләр һәм хисап ясаулар өлкәсендәге 34 идарә компаниясе, торак милекчеләре ширкәтләре һәм торак-төзелеш кооперативы белән үзара хезмәттәшлек итә торган иң эре агентларның берсе. БИХҮ гомумән алганда шәһәрнең 770 мең кешесенә хезмәт күрсәтә, бу 334 меңнән артык шәхси счет белән эшләү дигән сүз.

Казан шәһәренең БИХҮ эшчәнлегенең төп принциплары булып ТКХ хезмәтләре өчен исәпләп язуларның һәм акча агымы хәрәкәтенең үтәкүренмәлелеге, халык, идарә компанияләре һәм торак-коммуналь хезмәтләр күрсәтүчеләр арасындагы үзара хезмәттәшлекне координацияләү, идарә итү ысуллары һәм идарә оешмалары алмашкан чакта мәгълүмат базаларын саклап калу, торак-коммуналь хезмәтләрне исәпләүнең бертөрле методологиясен куллану тора.

Ай саен БИХҮ хезмәтләр өчен 1,2 млрд сум күләмендә исәпләп язулар үткәрә, халык өчен бертөрле түләү документларын бастырып чыгара, килгән акча чараларын бүлүне һәм, идарә оешмалары счетларын урап, хезмәт күрсәтүчеләр буенча акча чараларын үз вакытында күчерүне башкара.

Казан шәһәре БИХҮ эшчәнлеге халыктан җыелган акчаларның «югалу» һәм халыктан акча җыеп та 7 млн сумнан артык чараны хезмәт күрсәтүчеләргә күчермәгән «Слобода» ИК белән булган хәлнең кабатлану ихтималын юкка чыгара.

– Исәпләп язуларны һәм акча чаралары хәрәкәтен үзәкләштерү һәм ныклап тикшерү БИХҮнең ике еллык эшчәнлеге эчендә 2016 елның 1 гыйнварына ресурслар белән тәэмин итә торган оешмалар алдында булган 2014 елга кадәр җыелып килгән 600 млн сумга якын бурычны капларга мөмкинлек бирде. Һәм бу әле агымдагы түләүләрне исәпкә алмыйча, – дип тәгаенли үз сүзен Казан шәһәре БИХҮ генераль директоры.

Моннан тыш, БИХҮнең халыктан түләүләрне комиссиясез кабул итә торган 20 пункты бар. Кешенең кайда яшәгәнлегенә карамастан, әлеге пунктларның һәркайсында коммуналь хезмәтләр өчен түләү буенча уңайлылык тудырыла.

Түләүләр турында мәгълүматның мөмкин кадәр ачыграк булуын тәэмин итү максаты белән ике ел элек БИХҮ мәгълүмати системасы Татарстанның Дәүләт хезмәтләре порталы белән берләштерелде. Бүген шәһәрдә яшәүчеләр – «шәхси кабинет» хуҗалары онлайн-режимда исәп приборлары күрсәткечләрен кертә, счетчик күрсәткечләренең архив күрсәткечләрен һәм түләү тарихын карый, шулай ук хезмәтләр өчен түли ала.

Агымдагы елда Дәүләт хезмәтләре порталындагы «шәхси кабинет» аналогы булган ТКХ хезмәтләре өчен исәпләп язулар һәм түләүләр буенча хезмәт күрсәтү җыелмасын үз эченә алган мөстәкыйль мобиль кушымтаны эшләтеп җибәрү планлаштырыла.

Тагын бер яңа продукт (эшләтеп җибәрү һәм тест үткәрү 2016 елның азагына планлаштырыла) – тармак эшчәнлеген тәртипкә сала торган законнар үзгәрүгә (ә мондый хәл айга бер мәртәбәдән дә сирәгрәк булмый) бәйле рәвештә оператив яңартыла торган программа белән тәэмин ителеш. Яңа софтны гамәлгә кертү БИХҮ хезмәткәрләрен үзгәрешләрне системага кулдан кертү ихтыяҗыннан азат итәчәк, һәм шуңа бәйле рәвештә хаталар китү ихтималын да киметәчәк.

“

Дмитрий Анисимов, Казан шәһәре Бердәм исәп-хисап үзәге генераль директоры:

– ТКХ – ул, беренче чиратта, социаль яктан әһәмиятле тармак. Традицион рәвештә халык тарафыннан БИХҮ халыктан кала кемнең дә булса ихтыяҗын кайгырта торган структура буларак кабул ителә иде. Әлеге хәлне үзгәртү бездән бик зур көч таләп итә, һәм әле бу эш тәмамланды, дип әйтеп булмый.

Әмма минем белән бергә эшләүче кешеләр булмаса, шәхси хезмәтем генә бернәрсә дә бирмәс иде – урынбасарлар, бүлек җитәкчеләре һәм территориаль бүлекчәләрдә халык белән эшләү буенча төп авырлыкны үз өстенә ала торган белгечләр.

Әлеге премия Бердәм исәп-хисап үзәген оештыручылар, миңа ышанып, ике ел элек Казанның Бердәм тикшерү-хисап үзәге белә идарә итүне ышанып тапшырган «Казэнерго» АҖ, «Водоканал» МУП һәм «Казан энергия сервисы үзәге» МУП җитәкчеләре өчен дә мөһимдер, мөгаен.

Казан шәһәренең Бердәм исәп-хисап үзәге:

27
территориаль бүлекчә

300
дән артык хезмәткәр

ТКХ өчен комиссиясез түләүләр кабул итүне тормышка ашыра торган
20
өстәмә пункт

Халыктан исәп приборлары күрсәткечләрен кабул итү буенча **call-үзәк**

Реклама

PRESSA.RU

«ПОЛИМЭКСИМПОРТ»: ИННОВАЦИЯЛӘР, ЫШАНЫЧЛЫЛЫК, ҖАВАПЛЫЛЫК

«Ел җитәкчесе – 2016» милли премиясе йомгаклары буенча җиңүчеләренең берсе булып «Полимэксимпорт» ҖЧҖ генераль директоры Виталий Говоров танылды. Премиягә номинантлар төбәкләрнең эшкуарлык берләшмәләре тарафыннан тәкъдим ителсә, биредә җиңү яулаулары инде эшкуарларның бөтен Россия танылуын раслый.

ТИҢДӘШЛӘР АРАСЫНДА БЕРЕНЧЕЛӘР

Полимерлар җитештерү өчен кирәк булган компонентларны китерүгә махсуслашкан «Полимэксимпорт» компаниясе әле яшь: аңа 2012 елда нигез салына. Шул ук елны «Полимэксимпорт» Казанның синтетик каучук заводына 600 тоннага якын күләмле бәясе 1 млн АКШ доллары булган бутадиен (каучук җитештерү өчен кирәк булган сыекландырылган газны эшкәртү продукты булып тора) партиясен китереп үзенең беренче килешүен үткәрә.

Бүген «Полимэксимпорт» – Үзбәкстан Республикасы территориясендә тормышка ашырыла торган җитештерү күләмнәре буенча тармакның гигантлары булган «Казан Оргсинтез» һәм «Түбән Кама Нефтехим» белән тиңдәшсерлек нефть-химия проектында катнашучыларның берсе: катнашучылары арасында «Самсунг», «Шелл», «Эвоник» кебек дөньяви нефть-химия корпорацияләре булган тендерда җиңү яулап, компания Uz-Kor Gaz Chemical* предприятиесенә еллык күләме 6,5 мең тонналык N-гексан (шулай ук полиэтилен һәм поли-

Реклама

пропилен җитештерү өчен чимал компонентларының берсе буларак мөһим) китерүгә эксклюзив хокук алды. Шуны да билгеләп үтик, Россиянең үзендә N-гексан җитештерү оешмасы юк, һәм бездәге барлык нефть эшкәртү предприятиеләре аны чит илдән, күбесенчә Европа илләреннән китерергә мәҗбүр. «Полимэксимпорт» Румыниянең Rompetrol** компаниясе вәкиле булып тора. Бутен-1, үз чиратында, Иран һәм Берләшкән Гарәп Әмирлекләре предприятеләреннән китерелә (компонентларны «Полимэксимпорт» ҖЧҖ тарафыннан башкарыла торган Uz-Kor Gaz Chemicalга китерүнең еллык күләме 4,5 мең тонна тәшкил итә).

Җитештерүчеләрнең мондый киң географиясе (Үзбәкстанга бару юлында N-гексан биш дәүләт: Румыния, Молдавия, Украина, Россия, Казахстан территорияләре аша уза) компания каршына логистиканы төгәл төзү кебек мөһим максатны куя.

– Хәзер ул бар нәрсәне дә берничә клавишага басып һәм кирәкле документларны тутырып хәл итәргә була, – дип сөйли Виталий Говоров. – Ә менә 2015 елда без, РФнә экспортлый яки транзит ярдәмендә йөк күчерә торган күп кенә башка компанияләр кебек үк, Украина ягыннан Россия белән булган чик аша барлык йөк составларын уздыруга карата чикләүләр (аның иркле сәүдә зонасыннан чыгуы белән бәйле рәвештә) белән очраштык. Килешүләр буенча йөкләмәләрне башкаруның бердәнбер юлы булып вагоннарны Белоруссия территориясе аша җибәрү торды, ул очракта без үзебез шактый чыгымнар ясадык. Бәхеткә, мондый карар кабул иткәннән соң күп тә көттермичә Украина Президенты тарафыннан указга кул куелды, аның буенча Россия территориясеннән уза торган транзит йөкләрне чик аша үткәрү мөмкин булды.

Күптән түгел Иранга каршы санкцияләрне бетерү бутен-1 белән тәэмин ителешкә бәйле барлык проблемаларны да чишәргә мөмкинлек бирде. Хәер, бутен-1 белән тәэмин итүчеләрне компонентны чит илдән сатып алудан котылырга ачылышы 2016 елның көзендә «Түбән Кама Нефтехим»да планлаштырылган производство ярдәм итәргә тиеш. Татарстанның нефть-химия тармагы гиганты үз җитештерүендә Иран предприятиеләрендә файдаланылган лицензиар технологиясен куллана.

– Татарстанда бутен-1не җитештерү буенча үз предприятиебезне эшләтеп җибәрү компаниябезнең логистика һәм финанс куркынычларын юкка чыгарды дип әйтергә була, бу исә безнең ышанычлы бизнес-партнер дигән статусыбызны ныгытты гына, – дип ышандыра «Полимэксимпорт» ҖЧҖ җитәкчесе.

ҮЗ ҖИТЕШТЕРҮЕБЕЗ – ҮЗ ТЕХНОЛОГИЯЛӘРЕБЕЗ

Составына шул исәптән «Полимэксимпорт» ҖЧҖ да кергән компанияләр төркеме дүрт юнәлешне үз эченә ала: нефть-химия җитештерүе өчен чимал китерүдән тыш, бу – полиэтиленнан эшләнмәләр җитештерү (сырлы шланглар, торбалар һәм сантехника өчен сырлы арматуралар), он тарттыру предприятиеләре һәм тимер-бетон конструкцияләрен җитештерү буенча заводлар өчен технологик җиһаз һәм аның компонентларын чыгару, шулай ук нефть химиясе продукциясен аз тонналы җитештерү (соңгы икесен эшләтеп җибәрү түбән стартта тора – җитештерүләрне ачу якын-тирә айларга билгеләнгән).

Шуны билгеләп үтү мөһим: технологик җиһаз һәм нефть химиясе продуктларын җитештерүдә үзләре булдырган эшкәртмәләр һәм технологияләр кулланылачак.

– Без инде булган схемаларны сукырларча күчермәскә булдык. Аның урынына инженер һәм белгечләрне җәлеп иттек, технологияне камилләштердек һәм инде элементларның тәҗрибә өчен булган партиясен чыгардык та. Үз эшкәртмәләребезне гамәлгә кертү соңгы продукциянең үзкыйммәтен төшерергә, димәк, аны киң даирә кулланучылар сатып алыр өчен уңайлы ясарга ярдәм итәчәк, – дип аңлата Говоров.

Вибромашиналар, вибротегермәннәр һәм аспирация системалары өчен төеннәр һәм агрегатларның беренче үрнәкләре җәй башында Мәскәүдә узган «Төзелеш техникасы һәм технологияләре» тармак күргәзмәсендә тәкъдим ителде. Һәм кыйбат импортлы технологик җиһазның аналогы буларак күп кенә Россия компанияләрендә кызыксыну уятты.

Нефть-химия җитештерүендә (компания актив өслекле матдәләр, ДАФлар (диаммонийфосфатлар), химикатлар җитештерүне башларга планлаштыра) шулай ук үз эшкәртмәләре кулланылачак. Шулай, химия сәнәгатендә стабилизатор һәм актив өслекле матдә сыйфатында киң кулланыла торган кальций стеараты С.М.Киров исемендәге КМТТУның лаборатория базасында шулай ук камилләштерелгән технологияләр нигезендә синтезланган. Хәзерге вакытта алу ысулы патент процессын уза; химикатның үзлекләре КМТТУ белгечләре тарафыннан расланды. Әгәр таләпләргә туры килү «Түбән Кама Нефтехим»да да расланса, кальций стеаратын, шулай ук башка химикатларны республиканың нефть-химия тармагында әйдәп баручы предприятиесенә китерү башланачак.

Гомумән алганда, яңа юнәлешләрне үстерүгә компанияләр төркеме тарафыннан 6,5 млн сумга якын акча инвестицияләнгән. Җитештерүләрнең проект куәтенә чыгуы үз артыннан 20 яңа эш урыны булдыруны көз уңында тота.

ТАБЫШКА ГЫНА ИСӘП ТОТЫП ТҮГЕЛ...

Һәр бизнесның «җитлеккәнлеген» бары тик икътисадый күрсәткечләр – җитештерү күләмнәре, табыш, салым исәпләүләре һ.б. гына түгел, ә аның социаль җаваплылыгы да күрсәтә. «Полимэксимпорт» компаниясе җитәкчелеге үз хезмәткәрләренең иҗтимагый проектларда катнашуына ярдәм итә.

Узган елның март аенда Виталий Говоров һәм тагын берничә хезмәткәр ТР икътисад, сәнәгать һәм сәүдә министрлыкларының рәсми делегациясе составында Кыргызстан Республикасына барды. Анда Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов катнашында эшлекле форум узды. Сәфәр нәтиҗәләре буенча Татарстанда Кыргызстан Республикасының Мактаулы консулы институтын ачу турында карар кабул ителде.

Ә инде быелның маенда, Россия һәм Ислам хезмәттәшлеге оешмасының (ИХО) VIII Халыкара икътисадый саммиты кысаларында, Кыргызстанның Россиядәге илчесе Болот Отунбаевка Мактаулы консул вазыйфасына «Полимэксимпорт» компаниясенең сатулар бүлеге җитәчесе Марат Әхмәтов тәкъдим ителде.

– Кыргызстан Республикасының 2,5 меңгә якын гражданы Татарстанда яши. Мактаулы консул институтын төзү безнең республикалар арасында икътисадый, сәүдә, мәдәни һәм иҗтимагый элемтәләрне җайларга һәм ныгытырга ярдәм итәчәк, – дип саный Марат Әхмәтов.

Шунысын да аерым билгеләп үтәргә кирәк: Татарстанда Кыргызстанның Мактаулы консулы институтын булдыру проектын «Полимэксимпорт» компаниясенең сатулар бүлеге җитәкчесе «Кадрлар резервы» республика проекты кысаларында яклады: меңнән артык кеше катнашкан турыдан-туры һәм читтән торып үткәрелгән өч этап иләге аша узып, Марат Әхмәтов үз проектларын уңышлы яклаган 40 финалист арасына керде.

Тәэмин итүләр географиясен киңәйтеп, үз эшкәртмәләрне гамәлгә кертү белән бергә шәхси җитештерүне үстереп, социаль проектларны тормышка ашырып, «Полимэксимпорт» компаниясе республикада кече һәм урта эшкуарлыкны үстерүгә һәм тулай төбәк продуктында КУЭ өлешен арттыруга үз хезмәтен кертә.

* Uz-Kor Gaz Chemical – җаваплылыгы чикләнгән җәмгыять формасындагы уртак предприятие.
** Rompetrol – нефть компаниясенең сату маркасы.

PRESSA.RU

ЫШАНЫЧЛЫЛЫК ИСЕМ ӨЧЕН ГЕНӘ ТҮГЕЛ

«Казан-Арена».

Түбән Кама ГЭС.

Түбән Кама НЭЗ факелы манарасы.

Эретеп ябыштыру эшләре торбаларны, аппаратларны, төзелеш конструкцияләрен эшләү һәм монтажлау процессында иң җаваплы этапларның берсе санала. Еш кына объектның тулаем куркынычсызлыгы эретеп ябыштыруның сыйфатына бәйле. Яшьләр арасында эшче һөнәрләргә ихтыяҗ кискен кимегән 2000нче еллар башында ил күләмендә, аерым алганда, республикада квалификациясе эретеп ябыштыру эшләренең югары сыйфатына гарантия бирерлек кадрларга кытлык күзәтелә башлады.

«Надёжность» АП ЖЧЖ нәкъ шушы вакытта – 2003 елның ноябрендә барлыкка килә. Яңа фирманың төп көчен элек Кама металл конструкцияләре заводында эретеп ябыштыручы булып эшләгән белгечләр тәшкил итә. Компания белән Татарстан Республикасының атказанган төзүчесе, РФ Җылылык һәм энергетика министрлыгының атказанган хезмәткәре Анатолий Сергеевич Сергеев җитәкчелек итә.

Яңа гына барлыкка килгән фирма алдына җаваплы конструкцияләрне эретеп ябыштыручы белгечләрне, шулай ук инженерлар составының белем дәрәҗәсен раслау өчен аттестация үткәрү, эретеп ябыштыру эшләрен башкаручы оешмаларга технология һәм нормативлар буенча ярдәм күрсәтү, җимерүче һәм җимермәүче контроль ысуллары белән эретеп ябыштыру кушылмаларының сыйфатын контрольдә тоту бурычлары куела.

Хәзере вакытта «Надёжность» АП РФнең техник күзәтү системасы һәм Эретеп ябыштыруны контрольдә тотуның милли агентлыгы тарафыннан аккредитацияләнгән – компания «Техносвар» Идел буе төбәге үзәгенең аттестация пункты вазыйфаларын башкара. Моннан тыш, «Надёжность» «Сыйфат» Инженер-техник аттестацияләү үзәге составында аттестация үткәрү пункты сыйфатында Дәүләт төзелеш күзәтү органы структурасында да эшли. Ниһаять, компания РФ Транспорт министрлыгының Россия елга регистрында аттестацияләү пункты да булып тора. Компаниянең аттестация системасында эшләү һәм эретеп ябыштыру эшләренә рөхсәт бирү хокукы күзәтүче органнар ведомстволарының таныклыгы һәм сертификатлары белән расланган. Бүгенге көнгә «Надёжность» АП ЖЧЖ 6 меңнән артык белгечкә аттестация үткәргән.

Компаниянең һөнәри портфолиосында – Татарстанның һәм Россиянең башка субъектларының эре, шул исәптән стратегик объектларында эшләгән эшләре. Беренче чиратта, болар Түбән Камадагы «ТАНЕКО» Нефть эшкәртү заводлары комплексы, Менделеевскида бер елга якын элек кулланылышка тапшырылган «Аммоний» минераль ашламалар җитештерү комбинаты, Казандагы Халыкара ат спорты комплексы һәм Көрәш сарае, 45 мең тамашачыга исәпләнгән «Казан-Арена» стадионы, Яр Чаллыда Боз сарае, «РусГидро» компаниясенең Жигулёвская һәм Маткожненская (Кольск ярымутравы) ГЭСлары, Мәскәү өлкәсендә Сыгылмалы төргәк җитештерү заводы һ.б. «Надёжность» АП белгечләре көче белән Түбән Кама ГЭСында, «Алабуга» МИЗ объектларында, Яр Чаллы катыргы-кәгазь комбинатында җиһазлар, савытлар, торба һәм газүткәргечләргә, шулай ук эчке янулы двигательләргә һәм Елга регистры системасында теркәлгән көймәләр элементларына тикшерү үткәрелгән.

Компания хезмәткәрләре квалификациясен Татарстанның бөтен территориясендә дә диярлек төзелә торган объектларда Италия, Кытай һәм Төркия белгечләре белән уңышлы хезмәттәшлек итүе дә раслый. Аерым алганда, Кытай милли химия-инженерлык корпорациясе «Надёжность» АП җитәкчелеге исеменә югары һөнәри осталык һәм уңышлы эшчәнлек өчен рәхмәт хаты юллаган.

Ышанычлы партнёрлык статусын шушы еллар дәвамында заказчыларның канәгатьсезлек белдермәве дә раслый. 2015 ел йомгаклары буенча компания РФ Икътисадый үсеш министрлыгы мәгълүматлары буенча Россиянең Эшкуарлык үсеше фондыннан мактаулы медаль һәм «Милли сыйфат билгесе» турында сертификат алган.

Компания үзенең социаль өлгергәнлеген дә күп тапкырлар раслады: «Надёжность» АП даими рәвештә балалар йортларына һәм коррекция мәктәпләрендә тәрбияләнүчеләргә ярдәм итү йөзеннән оештырылган хәйрия акцияләрендә катнаша. Компания хезмәткәрләре «соры хезмәт хакы» дигән төшенчәне белми – гамәлдәге хезмәт һәм пенсия турындагы законнарга ярашлы, алар хезмәт хакын вакытында һәм тулысынча алып бара. Дәвалануга мохтаҗ хезмәткәрләрнең матди ярдәм алу мөмкинлеге бар. Өлкән буынны да онытмыйлар – компания Кама металл конструкцияләр заводы ветераннарына ярдәм итеп тора.

Реклама

ИПОТЕКАГА **АЛЬТЕРНАТИВА**

«ТРИУМФ-НК» торакка акча туплау кооперативы 2004 елда, беренчеләрдән булып, торакка акча туплау кооперативлары турындагы 215-ФЗ санлы Федераль закон кабул ителү белән барлыкка килгән иде. Быел аның нигез салучысы һәм алыштыргысыз җитәкчесе Валентина Михайловна Анисимова «Ел җитәкчесе – 2016» Милли премиясенең лауреаты булды.

Торакка акча туплау кооперативы – кулланучылар кооперативының бер төре, ул үзендә финанслар һәм торак-төзелеш кооперативлары сыйфатларын берләштерә. Торакка акча туплау кооперативы (ТАТК) пайчыларның акчаларын җәлеп итеп һәм аларның акчаларын торак алуга файдаланып, торак төзелешендә өлешчә буларак катнаша. Еш кына аз керемле кешеләр – бюджет оешмалары хезмәткәрләре, яшь һәм күп балалы гаиләләр, югары уку йортларын яңарак тәмамлаганнар өчен ТАТК әгъзасы булу торак шартларын яхшыртуның бердәнбер мөмкинлеге булып тора: пайчылар кооперативка кергәндә, банкларныкына караганда йомшаграк «иләк» аша үтә.

Кызганычка каршы, торак базарында ТАТК сегментының үсеш алуына шушы тармакка караган законнарның камил булмавы комачаулый – законга кабул ителгәннән алып шушы көнгә кадәр бернинди үзгәреш тә кертелмәгән диярлек. Гадәти ипотека кредиты яки кече финанс хезмәтләре механизмнарын кулланмый гына торак сатып алу мөмкинлеге булуы белән дә кыйммәтле әле ул.

«ТРИУМФ-НК» кооперативының тармаклы офислар челтәре бар: компаниянең икешәр офисы Түбән Кама белән Яр Чаллыда, бер офисы Әлмәттә эшли. Моннан тыш, кооперативның бүлекчәләре Казан белән Самарада эш итә. Компаниянең эшчәнлек географиясе әлеге шәһәрләр белән генә чикләнми: кооператив әгъзалары өчен фатирларны, ә бүген алар 350 тирәсе, Татарстаннан гына түгел, Россиянең башка төбәкләреннән дә, шул исәптән Мәскәү һәм Санкт-Петербургтан да сатып алалар. «ТРИУМФ-НК» үзенең пайчылары өчен атна саен уртача дүрт фатир сатып ала.

Банкларның ипотека кредитыннан аермалы буларак, ТАТКта әгъза булу билгеле бер сумманы мәҗбүри рәвештә түләп баруны таләп итми, сумма кооператив пайчыларының финанс мөмкинлекләреннән чыгып исәпләнә, шулай ук бурычны кайтару графигы да. Бурычның калган өлешенә «ТРИУМФ-НК» акча биреп тора, кагыйдә буларак ул озак вакытка бирелә. Шулай да еш кына кооператив әгъзалары бурычны вакытыннан алда, өч-дүрт ел дәвамында кайтара. Бу ике як өчен дә отышлы: бурычка алучы, әлеге дә баягы гадәти банк ипотекасыннан аермалы буларак, бурычны алдан кайтарган өчен штраф түләми; кооператив, үз чиратында, үзенең ресурслар базасын тулыландыра һәм җыелган акчаны башка пайчыларга торак сатып алуга яки төзелешкә юнәлтә. Кооперативка әгъза булып керү өчен түләнә торган сумма сатып алыначак фатир бәясенең алты процентыннан да артык түгел.

Хәзерге вакытка «ТРИУМФ-НК» тулаем 500дән артык фатир сатып алган, шуның 150гә якынының хакы тулысынча түләнеп беткән.

– 215-ФЗ санлы закондагы аңлашылмый гына түгел, ә еш кына абсурд дәрәҗәсендәге кайбер нормалар булмаса, фатир алган бәхетле гаиләләр саны күбрәк булыр иде, – ди Валентина Анисимова. – Мәсәлән, ТАТК турындагы гамәлдәге закон кооперативка юридик затларның керүен тыя; анда ана капиталын беренче кертем сыйфатында файдалану турында төгәл билгеләнмәгән; кооперативның һәрбер әгъзасы салым хезмәтендә теркәлгән һәм ЕГРЮЛ (юридик затларның бердәм дәүләт реестрына) кертелгән булырга тиеш, ә ТАТК әгъзалары өчен гариза формалары эшләнмәгән. Мондый төгәлсезлекләр бик күп. Мин гамәлдәге законга төзәтүләр кертергә кирәк, дип саныйм, һәм моны тиз арада эшләү зарур: торак сатып алу безнең гражданнарның киң катламының хәленнән килерлек булырга тиеш.

Телефон: 8 800 555 92 62

Реклама

PRESSA.RU

«КОНТРОЛЬЭЛЕКТРОСЕРВИС»: КУРКЫНЫЧСЫЗЛЫК САГЫНДА

Узган ел йомгаклары буенча «КонтрольЭлектроСервис» компаниясе «Ел предприятиесе – 2015» Милли премиясенә лаек булды. Компаниянең бурычы – янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү өлкәсендә хезмәтләр күрсәтү аша шәхес һәм җәмгыять мәнфәгатьләрен яклау.

«КонтрольЭлектроСервис» компаниясе базарда 2007 елда пәйда булды; оешкан көненнән алып аның алыштыргысыз җитәкчесе булып Александр Александрович Загумённов тора. Фирма үз эшчәнлеген янгыннан килгән зыянны минимильләштерүче янгын сигнализациясе һәм объект территориясенә рөхсәтсез кереп-чыгып йөрүне кисәтү өчен файдаланылучы видеокүзәтү системаларын монтажлау һәм техник яктан хезмәтләндерүдән башлый. Йорт булсынмы, офисмы, социаль инфраструктура объектымы, сәүдә үзәгеме яки җитештерү бинасымы – «КонтрольЭлектроСервис» компаниясе урнаштырган системалар һәм ул куллана торган технологияләр янгын яки ватып керү чыганагын күз ачып йомганчы билгеләп, туган куркыныч турында тиешле хезмәтләргә хәбәр итү мөмкинлеге бирә.

2011 елда компания дәүләт заказы системасында эшли башлый. Тагын өч елдан соң, 2014 елда, «КонтрольЭлектроСервис» ҖЧҖ үзенең эшчәнлек өлкәсен киңәйтә һәм ремонтлау, төзелеш базарына чыга. Бүген «КонтрольЭлектроСервис» ҖЧҖнең стратегик партнёрлары һәм заказчылары булып төбәктәге иң эре предприятиеләре һәм учреждениеләре тора – Кама балалар медицина үзәгеннән тыш, бу – «Трест Камдорстрой» ЯАҖ, «Яр Чаллы шәһәренең мәшгульлек үзәге» учреждениесе, «Татфондбанк» ГАҖ һ.б.

Хәзерге вакытта компаниянең эшчәнлеге дистәдән артык юнәлешне үз эченә ала. Алар арасында – янгынны кисәтү сигнализацияләрен хезмәтләндереп тору, видеокүзәтү системалары урнаштыру, локаль компьютер челтәрләрен, электр җиһазларын, аз токлы системаларны монтажлау, шулай ук кондиционерлар урнаштыру. Үзләрендә җитештерү көчләре булуы һәм югары квалификацияле хезмәткәрләр нинди генә катлаулы һәм зур күләмле эшне дә югары сыйфатлы итеп һәм төгәл вакытында башкарып чыгу гарантиясен бирә.

Милек формасының нинди булуына карамастан, клиент «КонтрольЭлектроСервис» ҖЧҖнә мөрәҗәгать иткәндә, аңа шунда ук җавап бирәләр, хезмәткәр объектка бушлай чыгып, иң оптималь җиһазлар сайлап ала, смета төзи һәм алга таба да урнаштырылган аппаратурага техник күзәтү ясап тора.

«КонтрольЭлектроСервис» ҖЧҖ эшчәнлегенең ышанычлы булуы турында күпсанлы сертификатлар, дипломнар һәм рәхмәт хатлары сөйли. Алар арасында Россиянең Эшкуарлыкка булышлык итү фондының «Милли сыйфат билгесе» дигән мактаулы медален тапшыру турындагы сертификат, «Кама балалар медицина үзәге» ДАССУ баш табибы. «Яр Чаллының 2 нче балалар дәваханәсе» ДАССУ баш табибы һәм Яр Чаллы наркология диспансерының җитәкчесе исеменнән бирелгән рәхмәт хатлары бар. Эшкуарлыкка булышлык итү фонды тарафыннан гамәлгә куелган «Ел предприятиесе – 2015» Милли премиясе дә «КонтрольЭлектроСервис» ҖЧҖнең тугрылыклы һәм ышанычлы партнёр булуын тагын бер тапкыр раслады.

Реклама

БУРЫЧ КУЕЛГАН – ХӘЛ ИТЕЛЕР!

Нәрсәгә тотынсалар да, булдыра торган кешеләр була. Кемдер аларга уңыш елмая, дип уйлый. Чынлыкта исә мондый «уңышлар» – күпьеллык тырыш хезмәт нәтиҗәсе. «Автомобилист» гараж-төзелеш кооперативы (Түбән Кама) рәисе Илһам Булатов – нәкъ шундыйлардан.

– Илһам Илдарович, сез «Автомобилист» гараж-төзелеш кооперативына 2000 елда җитәкче булып килгәнсез. Шушы вакыт эчендә ниләр эшләнде?

– Беренче адым гараж кооперативларын барысын да бер структурага берләштерү булды: ул вакытта алар 30 тирәсе иде. Бүген «Автомобилист» 40ка якын кооперативны берләштерә, аларда гаражларның гомуми саны – 16 мең. Бу бик зур сан! Моның белән зур коллектив кына шөгыльләнә ала – бүген бездә 200гә якын кеше эшли. Беренче урында һәрвакыт төзеклек, чисталык һәм экологик яктан куркынычсызлык мәсьәләләре булды һәм шулай булып кала да. Хәзерге вакытта чүп чыгару һәм электр белән тәэмин итү буенча проблемаларыбыз юк. Алай гына да түгел, гараж хуҗалары электр энергиясе өчен исәпләү җиһазлары күрсәткечләренә карап түләп бара. Милек куркынычсызлыгына килгәндә, без Түбән Каманың Эчке эшләр идарәсе белән актив хезмәттәшлек итәбез – шәһәрнең Эчке эшләр идарәсенең ведомстводан тыш сак бүлеге белән килешүләр төзелгән.

– Сез шулай ук бүгенге көнгә 15 бакчачылык ширкәтен берләштергән СНТ-НК Ассоциациясен җитәклисез. Ассоциация белән җитәкчелек иткәндә, сез нинди проблемаларга юлыктыгыз һәм аларны хәл итү өчен нинди чаралар күрдегез?

– 2003 елга бакча кишәрлекләренең яртысы диярлек ташландык хәлдә иде. Кәгазьдә аларның милекчесе бар, ә чынлыкта хуҗалары юк. Түбән Кама хакимияте һәм шәхсән мэр Илсур Метшин тарафыннан бакча хуҗаларын участокларына кайтарып, процессны системага, бакчаларны тәртипкә салу бурычы куелды. Без эшне хосусый милеккә хокук бирүче бөтен документларны күтәреп, аларны актуальләштерүдән башладык. Бу эштә безгә дача амнистиясе бик ярдәм итте. Шактый гына кыска вакыт эчендә бакчачылык ширкәтләре су һәм электр энергиясе белән тәэмин ителде, биш массивка без трансформаторлар куйдык.

Инфраструктураны торгыздык – кешеләр янә бакчаларына тартыла башлады. Хәзер инде ун ел элек ташландык хәлдә яткан бакчаларда тормыш кайный – кешеләр җир эшкәртә, төзелеш бара, хуҗалар янына балалары һәм оныклары килә. Эш шушы тизлектә дәвам итсә, тагын бер-ике елдан соң шәһәрдә ташландык участоклар калмаячак.

– Сез «Автомобилист» гараж-төзелеш кооперативы һәм бакчачылык ширкәтләре ассоциациясенең рәисе генә түгел, Афанас авыл җирлеге депутаты да булып торасыз…

– 2015 елда кабат депутат итеп сайлангач, мин, асылда, биредә дә кооперативтагы һәм ассоциациядәге эшли торган эшләрем белән шөгыльләнәм, ягъни кешеләргә көн кадагында торган проблемаларны хәл итәргә ярдәм итәм. Бу депутатның төп вазыйфасы. Кешеләр бу хакта белә, алар миңа ышана. Минем телефон номерын бөтен шәһәр белән диярлек. Бу җәһәттән кыенлыклар кичермим – үзем дә, гаиләм дә моңа күптән күнектек инде. Әгәр кешеләргә ярдәм итәргә алынгансың икән, монысына да әзер булырга кирәк.

– Сез «Бердәм Россия» партиясенең беренчел бүлекчәсе секретаре да. Партия юнәлеше буенча сезнең алда нинди бурычлар тора?

– Мин «Бердәм Россия» партиясенә 2000 елда – Владимир Путин дәүләт башлыгы булып сайлану белән әгъза булып кердем. Партиядә «Автомобилист» кооперативының күп кенә хезмәткәрләре тора. Яшермим. Партия әгъзасы булу гаражлар һәм бакча хуҗаларына проблемаларны хәл итәргә дә ярдәм итә.

– Илһам Илдарович, күптән түгел сез «Россия профессионаллары» ордены белән бүләкләндегез. Сезгә бу бүләк нәрсәсе белән кадерле, ул бит беренчесе генә түгел?

– Ничәнче премия булуы мөһим түгел, ул һәрвакыт эшкуарлык җәмәгатьчелеге, экспертлар һәм гади кешеләр тарафыннан синең эшеңә карата югары бәя дигән сүз. Һәр премия – алга таба эшләү өчен этәргеч ул. Һәм, әлбәттә, мин аны шәхсән үземнең генә премия дип әйтә алмыйм – бу бөтен коллективка тапшырылган бүләк.

Реклама

PRESSA.RU

СТАНДАРТЛАР – СЫЙФАТНЫҢ НИГЕЗЕ

Бүгенге дөньяда чәчрәп торган затлы этикетка астында тәме һәм ясалышы буенча бик үк әйбәт булмаган продукт та яшеренгән булырга мөмкин. Көн саен, товар сатып алганда, безгә сертификат, ГОСТ, ТУ кебек төшенчәләрне эченә алган мәгълүмат белән очрашырга туры килә. Татарстанда товарларның сыйфаты һәм үлчәүләрнең төгәллеге белән эшләрнең ничек торышы турында «Татарстан» журналы хәбәрчесенә Росстандарт системасында әйдәп баручыларның берсе булган «Татарстан Республикасы Стандартлаштыру, метрология һәм сынаулар буенча дәүләт төбәк үзәге» ФБУ директоры Фәрит Туктаров сөйләде.

– СМҮ өчен һәрвакыт нәрсә актуаль булып кала?

– Үзәк эшчәнлегенең төп юнәлешләреннән берсе булып метрология тора, аның өстенлекле бурычы – сәнәгатьтә, сәламәтлек саклауда, элемтә системаларында, сәүдәдә, оборонада, су, газ, нефть, электр энергиясе кебек ресурсларны исәпләүдә һәм шулай ук табигатьне саклау һәм хуҗалык эшчәнлегенең башка өлкәләрендә бердәм үлчәүләрне тәэмин итүдән һәм саклап калудан гыйбарәт.

Гади тел белән әйткәндә, бу – авырлык, күләм, озынлык, көчәнеш, басымның «бердәм үлчәмен» тапшыру. Мәсәлән, озынлык «үлчәме» инструментларга – төгәл детальләрне үлчи торган штангельләргә, микрометрларга, калибрларга күчерелгән. Безнең бурычыбыз – һәр приборның төгәл эшләвен тәэмин итү.

Үлчәү нәтиҗәләре кеше эшчәнлегенең барлык өлкәләрендә кулланыла диярлек. Шуңа күрә үлчәүләрнең төгәллеге гаять әһәмиятле.

Ел саен үзәк хезмәтеннән 20 меңгә якын юридик һәм физик зат файдалана. Республика җитештерүчеләре продукциянең көндәшлеккә сәләтлелегендә җитештерә торган продукцияләренең сыйфаты һәм куркынычсызлыгы төп нигез булып торуын күптән аңлады.

Бүгенге этапта безнең төп бурычларыбыз яңа сынау һәм тикшерү җиһазларын гамәлгә кертү, эш һәм хезмәт күрсәтү өлкәләрен киңәйтү, кулланучыларыбызның ихтыяҗларын канәгатьләндерүдән тора. Без, республиканың IT-эшчәнлегенә, инвестиция һәм инновация өлкәләренә кушылып, Татарстанның даими күтәрелә барган икътисадый активлыгы шартларында эшләргә тиеш.

Шул ук вакытта республика территориясендә тикшерү эшләрен максималь үзәкләштерү (локальләштерү) стратегиясен тормышка ашыру эше мөһим булып кала.

Әйтелгәннәргә йомгак ясап, шунысын да билгеләп үтәргә мөмкин, бүген үзәкнең төп бурычларыннан берсе – Татарстан Республикасының икътисадына һәм социаль өлкәсенә максималь файда китерү.

– Гади кулланучылар сезгә нинди мәсьәләләр белән мөрәҗәгать итә?

– Гражданнарны барыннан да ешрак су, электр энергиясе, газ исәпләү приборларының төгәл эшләве борчый. Бүген, ТКХ тарифлары елдан-ел үсә барганда, гражданнарны үз фатирларында исәпләү приборлары куярга үгетләргә туры килми. Бу мәсьәләне алар үзләре өчен уңай хәл иттеләр – һәр кулланучы үз гаиләсенең матди иминлеген кайгыртырга тырыша.

– 1 июльдән «Россия Федерациясендә стандартлаштыру турында» гы федераль закон үз көченә керде, бу закон нәрсә бирә?

– Беренче чиратта «Россия Федерациясендә стандартлаштыру турында»гы закон милли стандартлаштыруга яңа хокукый статус бирә, чөнки без ун елдан артык бары тик техник көйләү кагыйдәләре буенча гына яшәгән идек. Стандартлаштыру, сыйфат һәм Россия базарында көндәшлеккә сәләтлелек мәсьәләләрен читтә калдырган хәлдә, продукциянең куркынычсызлыгын гына тәэмин итеп, асылда техник көйләү элементы гына булып тора иде.

Техник көйләү системасыннан, мәсәлән, оборона продукциясен, медицинаны, әйләнә-тирә мохитне саклау, экологик куркынычсызлык һәм традицион рәвештә стандартлаштыру эшчәнлеге өлкәсенә кергән башка күп өлкәләрне стандартлаштыру мәсьәләләре төшеп калды һәм алар хәзер яңа федераль закон белән көйләнәчәк.

Халыкара стандартлаштыру турында әйткәндә, бу законның тулысынча халыкара принципларга һәм мөнәсәбәтләргә нигезләнүен, законда кулланыла торган бөтен терминологиянең халыкарага туры килүен билгеләп үтәсе килә. Бу, сынау нәтиҗәләрен үзара аңлашуны тәэмин итү, продукциянең сыйфатын күтәрү һәм тәэмин итү, әйләнә-тирә мохитне саклау һәм, ахыр чиктә, үз продукциябезне чит ил базарларына чыгару максатларында, безнең милли стандартларны халыкара таләпләр белән яраклаштыру, көйләү өчен бик мөһим.

– Товарның (хезмәт күрсәтүнең) сыйфаты аның куркынычсызлык

Реклама

гарантиясе икәнлеге билгеле. СМҮ фальсификатка каршы ничек көрәшә һәм сыйфатны ничек контрольдә тота?

– Продукцияне сынау өчен без үзебезнең тикшерү һәм сынау базасын кулланабыз. Бу – үлчәү чараларын (СИ) раслау өчен дәүләт аккредитацияләгән үлчәү чараларын сынау үзәге, нефть химиясе продуктларын сынау лабораториясе, азык продукциясе һәм азык-төлек чималын сынау буенча ике лаборатория.

Ел саен нефть лабораториясе – 800дән артык продукция үрнәген, ике азык-төлек продукциясе лабораториясе 10 меңнән артык үрнәкне сыный.

Азык-төлек лабораторияләре кайбер сыйфат күрсәткечләрен генә түгел (органолептика, физикохимия, продуктлар составы), продукция һәм чималда агулы элементлар, пестицидлар һәм кеше сәламәтлегенә зыян салучы башка матдәләр булу-булмавын да тикшерә.

Сертификация буенча аккредитацияләнгән органнар сынау узган – шул исәптән, безнең лабораторияләрдә дә – продукциягә яраклылык сертификаты һәм декларацияләр бирә. Күптән түгел бу эшчәнлектә продукцияне (хезмәт күрсәтүне) сертификацияләү органы – «Татарстан Республикасында Стандартлаштыру, метрология һәм сынау буенча дәүләт төбәк үзәге» ФБУ булдырылды, һәм ул якын арада аккредитацияләнәчәк.

– Нефть продуктларының түбән сыйфатлылыгы проблемасы әле дә актуальме?

– Сатыла торган мотор ягулыкларының сыйфат мәсьәләсе берничә ел дәвамында республика җитәкчелегенең игътибар үзәгендә, чөнки начар ягулык экологиягә һәм кешеләр сәламәтлегенә зарар китерә – зыянлы калдыкларның 80%ын атмосферага транспорт бирә. Сыйфатсыз ягулык двигательләрнең дә ватылуына китерә.

Республикада сатыла торган мотор ягулыкларының сыйфатын тәэмин итү буенча чаралар системасы булдырылды, аның нигезендә – даими контроль.

Татарстан хөкүмәте, республика базарында сыйфатсыз нефть продуктларын кертмәү өчен тулы чаралар комплексын тормышка ашырып, һәм шул исәптән, республика АЗСларында сатыла торган мотор ягулыкларын тикшерү буенча ел саен аерым айлыклар үткәреп, бу мәсьәләгә гаять зур игътибар күрсәтә.

СМҮ сайланган үрнәкләрне, шул исәптән күрше төбәкләрдән алынганнарны да, үзенең тиешле җиһазлар белән тәмин ителгән сынау лабораториясендә тикшерә.

2015 елда, РФ Президенты Владимир Путин һәм РФ Хөкүмәте Рәисе Дмитрий Медведевның «Автомобиль һәм авиация бензинына, дизель һәм су транспорты ягулыгына, реактив двигательләр ягулыгына һәм яга торган мазутка таләпләр турында»гы ТР ТС таләпләренә туры килми торган мотор ягулыгын АЗСларда сатарга рөхсәт итмәү чараларын күрү турындагы күрсәтмәләре буенча үткәрелгән тикшерү чаралары кысаларында, генераль прокуратура һәм Росстандартның (Госнадзор) төбәкара территория идарәләре белән берлектә, И(б)ФОнда сайлап алынган мотор ягулыкларын сынау үткәрелде, аларның 32%ында кайбер күрсәткечләр буенча тайпылышлар табылды.

Сынау нәтиҗәләре безнең республикада нефть продукциясе белән тәэмин итү өлкәсендә уңай һәм системалы эш алып барылуын күрсәтә.

– 19 ел инде Россиядә «Россиянең иң яхшы 100 товары» дигән программа эшли һәм 13 ел «Татарстан Республикасының иң яхшы товарлары һәм хезмәтләре» дигән конкурс бара...

– Бу иң массакүләм һәм популяр конкурслар. «Россиянең иң яхшы 100 товары» конкурсы оешканнан башлап, Татарстан – аның иң актив катнашучысы. Конкурсны уздыруның көйләнгән механизмы, төгәл методикасы, нәтиҗәләрнең объектив ясалуы һәм үтәкүренмәлелеге аны иң абруйлылардан итте. Анда 4 меңнән артык товар һәм хезмәт катнашты инде. 1200 катнашучы, дипломантлары – 1500. Конкурста катнашучыларның 70%ка якыны – елдан-ел үз продукцияләренең сыйфатын һәм көндәшлеккә сәләтлелеген расларга омтылучы тотрыклы предприятиеләр составы.

Кече һәм урта бизнесның конкурс белән кызыксынуы арта, аларның өлеше конкурста катнашучыларның 40 процентына кадәр җитте инде.

Кулланучылар белән үткәрелгән сораштырулардан күренгәнчә, «Россиянең иң яхшы 100 товары» һәм «Татарстан Республикасының иң яхшы товарлары һәм хезмәтләре» конкурсларының логотиплары, сыйфат һәм куркынычсызлык гарантларына әверелеп,товарга ышанычны арттыралар. Конкурс лауреатларының товарларын сату күрсәткече уртача 20%ка арта. Конкурсны оештыру буенча системалы эшләү нәтиҗәсендә Татарстан, 2007 елдан башлап, РФ субъектлары арасында «Россиянең иң яхшы 100 товары» программасын тормышка ашыруда әйдәп баручы урынны алып тора.

Республика җитәкчеләре әлеге конкурска җитди игътибар итәләр һәм аның үсешенә зур ярдәм күрсәтәләр.

Әлбәттә, без бер урында басып тормыйбыз, даими рәвештә камилләшергә тырышабыз. Узган ел конкурс кысаларында инфраструктур өлешләр сыйфатында яңа республика конкурслары булдырылды: «ТРның иң яхшы метрологы», «ТРның иң яхшы стандартизаторы», «ТРның иң яхшы сынаучысы», «ТРның стандартлаштыру, метрология һәм сыйфат өлкәсендә студентларның иң яхшы диплом эше».

Бу ел башында «ТРның иң яхшы товарлары һәм хезмәтләре» конкурсының оештыру комитеты тарафыннан конкурсның торышына анализ ясалды, аның үсешенең яңа концепциясе каралды һәм кабул ителде, анда кулланучыга юнәлеш тоту, медиа яклавы, продукциянең сыйфаты һәм куркынычсызлыгының гарантиясе буларак, логотип статусын күтәрү, Татарстан товарларын тәкъдим итү һәм Татарстанның иң яхшы җитештерүчеләрен пропагандалау йөзеннән, сәүдә челтәрләре белән үзара бәйләнештә тору мөһим урынга куелды.

РФ Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы (министрның беренче урынбасары Г.С.Никитин) һәм Техник көйләү һәм метрология буенча федераль агентлык (җитәкче – А.В.Абрамов, җитәкче урынбасары – С.С.Голубев) җитәкчелеге «Төгәл исәпләүләр – сыйфат һәм куркынычсызлыкның нигезе» халыкара форумында «Татарстан СМҮ» ФБУ экспозициясендә. (2016 елның май ае, Мәскәү).

Реклама

PRESSA.RU

ҖИЛӘКЧЕДӘН КҮРМӘКЧЕ

Автор:
Линар Закиров

Европаның күпчелек илләреннән азык-төлекне Россиягә кертүне тыйгач, күршеләрнеке генә түгел, безнең тавыклар да күркә булып күренә башлады. Ниһаять, үзебездә үскән яшелчә, җиләк-җимешне татып карап, чит илнекеннән бер дә ким түгеллеген белдек. Импортны алыштыру программасы башлангач, республикада җиләк үстерүчеләр дә барлыкка килде, Хөкүмәт аларны башларыннан сыйпап кына тора. Нәтиҗәдә, Татарстанда җиләк кластеры барлыкка килде.

«БАКЧА ҖИЛӘГЕ – КЫСКА, КУРА ОЗЫН ГОМЕРЛЕ»

Илдар Ситдыйков озак еллар төзелештә эшләп, 2012 елда тормышын тамырдан үзгәрткән – Яшел Үзән районының Олы Яке авылында ике гектар мәйданда бакча җиләге үстерә башлаган. Беркем дә хатадан хали булмаган кебек, Илдар әфәнденең дә эшкуарлык юлы сикәлтәләрсез генә булмаган.

– Баштарак җиләк үсентеләрен Россиядә сатып ала идек. Аларны чит илдән кайтарабыз, дип ышандырдылар безне. Соңыннан бу сүзнең дөреслеккә туры килмәгәнлеген, ягъни безне алдаганнарын ачыкладык, – диде әңгәмәдәшем.

2015 елда Әлмәт районының яңа башлыгы Айрат Хәйруллин Илдар Ситдыйковка җиләкне шәһәрдән ерак булмаган Ямаш авылында күпләп үстерергә тәкъдим иткән. Эшкуар, чакырудан баш тартмыйча, бүгенге көндә 20 гектар мәйданда – бакча җиләге, 15 гектарда кура җиләге үстерә, шуның 25 проценты – ремонтант: сезон дәвамында үсентеләр, бер тапкыр уңыш китереп, бераз ял итә дә икенчегә җиләк бирә.

Кура җиләге бакча җиләге кадәр сөендерә алмаячак, ул өч-дүрт елдан

Фото: Линар Закиров

гына тулы көченә уңыш бирә. Шуңа күрә быел аңа әллә ни өмет багламыйлар, бирсә – бирә, бирмәсә – юк. Әмма кураның хезмәт итү вакыты озаграк – 15 ел, җиләкнеке – биш ел.

Быелгы көздә хуҗалыкта 80 гектар мәйданда карлыган утыртырга җыеналар. Әлегә булачак түтәлләргә су сибү системасын сузалар.

Әлмәт районындагы җиләк басуы зурлык ягыннан Россиядә икенче урында. Без анда барган көнне кояш үҗәтләнеп кыздыра, ә җиләкләр аның нурларында рәхәтләнеп кызына иде.

– Биредә җиләкнең Италиядә чыгарылган дүрт сорты үсә, кайберләре иртәрәк, кайберләре соңрак өлгерә, – дип аңлата башлады Илдар Ситдыйков. – Россиядә соңгы елларда җиләкнең яңа сортларын чыгармый башладылар, шуңа да чит илнекен утыртырга туры килә. Җиләкне Италиядәге технология буенча үстерәбез. Яз көне җирне яхшылап эшкәртәбез, май башында үсентеләрне түтәл итеп мулчәләү пленкасына утыртабыз. Аның берничә уңай ягы бар. Анда чүп үләне үсми. Су җир астыннан тамчылап килеп, пленка дымны саклый. Бөтен ашлама су белән кертелә. Өлгергән җиләк җиргә сыгылып төшеп пычранмый, пленкада чиста килеш саклана.

Әңгәмәдәшем сүзләренчә, кайбер сортлар июнь башында ук кызарып пешә башлагач, тирә-күрше авыл-районнардан ике йөзләп кеше килеп, иртәнге дүрттән төшкә кадәр дәррәү җыя. Көннең кыл уртасында җиләк кыза, җыярга ярамый. Кайвакыт кичке биштән җидегә кадәр икенче смена оештырыла. Эшчеләрне Әлмәттән Ямашка вахта китерә. Җыелган җиләкнең һәр килосына 15 сум түлиләр, көн дәвамында 2500 сум эшләүчеләр дә бар.

ҖИЛӘК КАРАКЛАРЫ

– Бакча җиләге түтәлләренең гомуми озынлыгы – 121 километр, кура җиләгенеке – 80 километр, – дип шаккатырды хуҗалыкның агрономы Илнар Насыйров. Ул белеме буенча кыр белгече, җиләк хакына бакчачылыкны да үзләштергән. Бер гектарда 40 мең төп җиләк үсә, ди.

– Бакча җиләген клубника дип атау дөрес түгел, «садовая земляника» дияргә кирәк. «Клубника» да, «земляника» да – кыргый үсемлекләр, ә «садовая земляника» шушы ике культураны катнаштырып, ясалма рәвештә чыгарылган, – дип аңлатты агроном. – Татарстандагы иң тәмле җиләк – бездә! – дип тә мактанды.

– Шулай дип әйтү өчен иң элек республикадагы бөтен җиләктән авыз итеп карарга кирәк бит, – дип каршы төшкән булам.

– Мин республикадагы җиләк хуҗалыкларында эшләүче агрономнар белән аралашып торам, шалтыратышабыз. Шуңа күрә кайда нинди җиләк барлыгын беләм. Безнең якларда җиләк үстереп булмый, дип күпме генә әйтсәләр дә, аны мондагы табигать шартларына яраклаштыра алдык. Нитратлар кулланмыйбыз. Алай эшләгән булсак, җиләкләребез озак саклана алмас, агып бетеп, бозылыр иде. Товарыбыз дәүләт стандартлары буенча әзерләнә.

Илнар әйтүенчә, быел, караңгы төшкәч, берничә кеше (күбесе бала-чага) хуҗалык җирләренә җиләк урларга кергән. Алай эшләргә ярамаганын аңлаткач, каракларның эзе суынган.

– Күрүебезчә, тагын бер дошманыгыз бар икән: түтәлләр арасында чүп үләннәре шактый күренә, – дим.

– Алар белән дә көрәшәбез: чабабыз яки утыйбыз, җиләк арасында үскән чүп үләннәренә каршы рөхсәт ителгән препаратлар юк шул. Җиләкнең күбесе җыелып беткәч, мыекларын кисәбез, рәт араларын тәртипкә китерәбез.

ЭШЛӘПӘЛЕ ҺӘМ КОЙРЫКЛЫ

Бер төркем ирләр арасында күзәмә бер туташ чалынып китте. Исеме – Диләрә Афандеева, Әлмәттәге 16нчы мәктәпнең 10нчы классын тәмамлаган. Ул биредә бригадир, җыелган һәм машинага төялгән җиләкне санап, теркәп бара. Диләрә хуҗалыкта икенче ел эшли. Былтыр ике көн җиләк җыйган да өченчесендә, язуың матур дип, кулына ручка белән папка тоттырып, бригадир итеп билгеләгәннәр.

– Ир-атлар белән эшләү кыен түгел, киресенчә, барысы да игътибар күрсәтә, каршы дәшми, – ди ул. – Көненә 5-10 тонна җиләк җыела. Басу җиде секциягә бүленгән, һәрберсенең бригадиры бар. Иртән чык төшмәгән булса, җиләкне җыябыз, чык төшсә, аның юкка чыкканын көткән арада рәт араларындагы чүпне утыйбыз. Эшчеләр, җиләкне картон контейнерга җыеп, бригадирга тапшыра. Җиләкнең эшләпәсе һәм койрыгы булырга тиеш. Койрыгы булмаса, ул тиз бозыла.

Әңгәмәдәшем әйтүенчә, җыелган җиләкне берничә көн суыткычта ике градуслык температурада саклыйлар. Ә кибеттә ул 2-3 тәүлек кенә тора ала.

– Җыйганда бозылганнары дә очрый. Андыйларны йә ыргытабыз, йә кешеләр әче бал ясарга дип килеп алалар, – диде әңгәмәдәшем.

Диләрә сөйләвенчә, көненә 50-60 эшче килә. Алар өчен тулай торак та төзиләр. Җиләк җыючылар арасында хөрәсән ялкаулары да, шул ук вакытта төшке ашка бүленмичә эшләүчеләр дә бар. Әйтик, берсе сигез сәгать эчендә 31 тартма (һәрберсендә – сигезәр контейнер) җиләк җыйган. Үзенә күрә рекорд инде бу!

PRESSA.RU

СӘЯХӘТЧЕ ҖИЛӘК

Студент Мария Мельникова белән мәктәп укучысы укучысы Татьяна Домнина җиләкләр өеме арасында эшли: яхшы җиләкне начарларыннан аералар. Мария Ямашка Әлмәттән бирегә йөкче булып эшләүче дус егете белән машинада килә. Ә Татьяна – күрше Рус Акташы авылыннан вахта белән килеп җитә. Ул авылдан хуҗалыкта күп кеше эшли.

– Чүпләүгә караганда, җиләкне утырту авыррак. Сәгатенә 70 сум түлиләр. Ай ахырына кадәр эшләргә җыенам, мәктәпкә барыр алдыннан ял итеп аласым килә, – дип, планнары белән уртаклашты Татьяна.

Шул арада ирләр, берничә тонна товарны йөк машинасына тутырып, Мәскәүгә озатырга җыена иде. Анда кадәр җиләк 18 сәгать сәфәр кыла.

– Бозылып бетмәсме? – дип борчылам.

– Юк, машинаның арбасы суыткыч белән җиһазландырылган, – дип тынычландырырга ашыга шофер.

– Кайвакыт, машина сикәлтәгә очрап, өстәге әрҗәләр килеп төшәргә һәм җиләк таралырга мөмкин. Юлларның шундый булуына без гаепле түгел, бозылган җиләк бәясен беребезнең дә хезмәт хакыннан тотып калмыйлар, – дип аңлатты Диләрә.

«ХАЛЫК АШАП ТУЙГАЧ, БӘЯ ТӨШӘ»

Хуҗалык янында ук корылган палаткада Ямаш авылыннан Олеся Талиманчук җиләк сата. Иртәнге сигездән кичке сигезгә кадәр. Җәй башында продукция кыйммәт торса, сезон ахырына таба, кеше җиләкне ашап туйгач, бәясе төшә. Авыл Сабан туйларында аның килосын 350 сумнан сатканнар.

Олесяның җиләкне җыйганы да булган, тик сатуы җиңелрәк, ди.

– Җиләкне ирләр дә, үсмерләр дә, гаиләләп тә җыялар. Араларында яше җитмештән узган бер әби дә бар. Җиләк җыюда ул яшьләрдән дә уздыра. Яшен сорасаң, ул һәрвакыт: «Миңа 18!» – ди.

– Җиләк ашарга яратасызмы?

– Аны күп ашап булмый. Кайнатма әзерләп, чәй белән эчәргә яратам. Үзебезнең бакчада да җиләк үсә. Мондагысыннан аерылса да, тәме шундый ук диярлек, – диде Олеся.

– Кара нинди эре җиләк! – дип гаҗәпкә калды палатка янына килеп баскан Людмила Антонова. Ул озак еллар Нижневартовск шәһәрендә яшәп, күптән түгел Әлмәткә күченеп кайткан.

– Бакча җиләген, гадәттә, ашыйбыз гына, ә урманныкыннан кайнатма әзерлим. Җәй көне витаминнар ашап калырга кирәк. Быел беренче тапкыр авыз итәм, – диде ул, сатып алган бакча җиләген татып карап. – Әлмәттә яшәүче бертуган абыем үз бакчасында яшелчә үстерә, мин аңа булышам. Ел саен кыш көне кибеттән төче чия алам, быел бер килограммын 270-280 сумнан саттылар. Ярты килограмм гына алдым, безнең ише пенсионерга җитә.

«САЛАМ ҺӘМ НАРАТ ЫЛЫСЛАРЫ КУЛЛАНАМ»

Әлмәт районындагы Нәдер авылында яшәүче Ринат Азизов умарта тота, бер гектар мәйданда җиләк тә үстерә. Шулардан һәм нарат күркәләреннән кайнатмалар әзерли. 12 ел элек җиләкнең үсентеләрен сатып кына көн күрсә, алты ел элек бакча җиләген утыртып карыйсы иткән.

– Мин диндәге кеше. Билгеле булганча, мөселманнарга кредит алырга ярамый, шуңа да бөтен эшне үз акчама башкарып чыктым. Төп кыенлыгы шул булды, – ди ул.

Ринат әфәнде әйтүенчә, элек Татарстанга үсентеләрне Голландиядән кайтартсалар, хәзер андый сыйфатлы чимал республикада юк диярлек. Шуңа да турыдан-туры чит илдән китертергә туры килә.

– Хуҗалыгымда Америка, Голландия, Италиядән кайткан төрле сортлар үсә. Голландиянеке сыйфат ягыннан яхшырак та, тәмлерәк тә. Иң югары бәяне Кимберли сортына бирер идем. Италия сортларыннан иң иртә өлгергәне – Альба, аның җиләкләре рәсемдәге кебек матур һәм идеаль формада. Американыкында әчкелтем тәм бар, – дип, һәркайсына характеристика биреп чыкты фермер.

Җиләкләр тизрәк өлгерсен, матуррак һәм баллырак булсын өчен, Ринат Азизовка химик ашламалардан файдаланырга тәкъдим иткәннәр, әмма ул алардан баш тартып, табигый чимал гына – салам, нарат ылыслары куллана.

Нәдердә дә җиләк июнь башында өлгерә. Җыярга Ринат әфәнденең гаиләсе чыга, кайвакыт читтән дә кеше җәлеп итәләр.

– Җиләкне күпләп үстерү аның бәясенә тискәре тәэсир итә – очсызлана, – ди фермер, былтыр Ямашта ачылган җиләк басуын күздә тотып.

– Аның каравы, сатып алучыга кулайрак бит, – дим, үземне дә, беренче чиратта, кулланучы урынына куеп.

– Анысы шулай да бит, тик җиләккә болай да бик күп чыгым китә. Аны бер гектарда утырту 1,5 миллион сумга төшә. Җирле җитештерүчеләр арасында көндәшлек булмаса да, кибет киштәләрендә җиләкне күпләп үстерә торган Краснодар һәм Ставрополь крайлары белән ярышабыз. Узган елларда шул яктан килгән кайбер сатучылар үз продукциясен минеке – Нәдернеке, дип халыкка тәкъдим итте. Ямашта хуҗалык барлыкка килгәч, минем җиләккә сорау кимеде, – диде Ринат Азизов.

– Европа продукциясенә эмбарго кертелү хәлләрегезне яхшыртты-мы?

– Дөресен әйткәндә, сизмәдем. Европа җиләкләре мартта килә иде, тик ул вакытта безнекеләр өлгереп җитми.

Ямаш авылындагы хуҗалык вәкилләре шушы сорауга болай дип җавап бирде:

– Европа, Төркия продукциясенә чикләү куелса да, җиләкне башка илләрдән китерәләр иде. Әмма без кибет киштәләрендә үз урыныбызны барыбер булдырачакбыз.

Рөстәм Миңнеханов, Татарстан Республикасы Президенты, – 2015 елның августында Әлмәт районының Ямаш авылындагы җиләк хуҗалыгы эшчәнлеге белән танышканда:

– Безнең ил импортны алыштыру белән генә шөгыльләнеп калмыйча, күп кенә азык-төлекне читкә дә сатып җибәрә ала. Моның өчен дөнья күләмендә эшли алырлык эре җитештерүчеләребез бар. Шушындый җиләк кластерларын булдыру экологик яктан чиста продукция кулланырга мөмкинлек бирә. Җиләк-җимеш плантацияләрендә яңа эш урыннары да булдырыла, бу бик мөһим.

Людмила ПАВЛОВА, Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының игенчелек тармакларын үстерү бүлеге мөдире урынбасары:

– Кластер, беренче чиратта, җиләк-җимешне үстерүдән башлап сатуга кадәрге бөтен циклларны башкарып чыгу өчен кирәк. Яхшы җитештерүче һәрвакытта да әйбәт сатучы була алмый. Кайвакыт фермерлар продукцияне арзан бәядән арадашчыларга тапшырырга мәҗбүр була.

Былтыр кластерга республикада җиләк белән шөгыльләнүче 22 фермер берләшсә, быел аларның саны 25кә җитте. 2015 елда җитештерү мәйданы – 55 гектарга, 2016 елда 30 гектарга артты. Яшел Үзәндә мең тоннага исәпләнгән җиләк саклау урыны төзелә, шунда ук үсентеләрне үзебездә чыгару өчен микроклональ үрчетү лабораториясе корыла. Тагын бер җиләк саклау урынын Тәтеш районында төзү нияте бар. Ул Ульяновскига якын урнашкан, Россия базарына чыгарга кулай булачак.

Фото: Линар Закиров

PRESSA.RU

«ЯШЕЛ» ТЕХНОЛОГИЯЛӘРНЕҢ ҖИҢҮЕ

Түбән Каманың 50 еллыгына, экологик программага яраклы рәвештә, «Түбән Кама Нефтехим» ГАҖ, биологик чистарту корылмалары (БЧК) үзгәрешләр кичерәчәк. Өч яңа объект барлыкка килеп, аларның һәркайсы шәһәр һәм сәнәгать агынтыларының сыйфатын күп тапкыр яхшыртачак. Тик бу – эшнең башы гына әле.

Шәһәрнең тәүлегенә 150 мең кубометрга кадәр көнкүреш-хуҗалык һәм шулай ук сәнәгать суы калдыкларын чистартучы биологик чистарту корылмалары бүгенге көндә ТКНХ өчен иң мөһим яңартып төзү объекты булып тора. Моннан 50 ел элек төзелгән БЧКны реконструкцияләү зарурлыгы болай да ап-ачык. Предприятиенең бу эшкә җитди алынуы да аңлашыла. Бөтен территория бүген тоталь төзелеш мәйданын тәшкил итә: кешеләр һәм техника мыжлап тора, чүпрәдә күтәрелгәндәй, яңа биналар үсеп чыга.

Моннан бер ел элек механик узелны модернизацияләү һәм газ ташландыкларын нейтральләштерү өчен сәнәгать җиһазларын кую турында перспектив планнар каралган иде. Бүген инде өч объект тәмамлану алдында тора һәм шәһәр юбилеена суны туфрак юынтыларыннан аерып, эре чүпләрне, ком-ташларны тоткарлап калучы яңа рәшәткәләр бинасы һәм аннан ары биологик чистарту өчен көнкүреш-хуҗалык һәм сәнәгать агынтылары бергә кушыла торган смеситель эшләп китсен өчен барысы да башкарыла.

БЧКда төзелеш кайный, коммуникацияләр һәм электр кабеле эстакадасы үткәрелә. Торба үткәргечләрне кушу камерасы һәм өстәмә трансформатор подстанциясе төзелә. Тәүлек әйләнәсе 10 подряд оешмасы эшли. Бер үк вакытта мәйданда 80 эшче һәм ике дистә махсуслаштырылган техника берәмлеге эшләп тора.

«Түбән Кама Нефтехим» ГАҖнең капиталь төзелеш департаменты директоры Кирилл Слесарев объектларны төзү барышы турында мена ниләр сөйли:

– Рәшәткәләр бинасына нигез котлованыннан беренче чүмеч туфракны без 15 гыйнварда чыгарган идек, хәзер инде эшнең 60%ы эшләнде. Дүрт мең кубометр бетонның инде өч меңен кабул иттек. Төп гомуми төзелеш эшләрен июль уртасына тәгәлләүне күздә тотабыз, ә июль башында җиһазларны тоташ монтажлауга керешәчәкбез, алар чама белән 130 берәмлек. Шулай ук өч километр озынлыгында җир асты коммуникацияләре салыначак, аларның бер километры – 1600 миллиметрдан зуррак диаметрлы торба үткәргечләр.

Җиһазларның 80% тирәсе складларга кайткан инде, тулысынча алар 10 июльгә китереләчәк. Җиһазлар нигездә үз илебезнеке.

«Түбән Кама Нефтехим» ГАҖнең әйләнә-тирә мохитне саклау буенча баш белгече Анатолий Самольянов иске рәшәткәләр бинасын күрсәтеп, яңа бина тапшырылганнан соң чистартуның ничек яхшырачагын аңлата:

– Үзгәртеп коруның максаты – калдык суларны чистартуның сыйфатын яхшырту һәм агынтыларны чистарту процессында чыккан исләрне утилләштерү. Беренче этап – агынтыларны чистартуның механик узелы: шәһәр агынтыларын комнар һәм эре чүпләрдән тагын да тирәнрәк итеп беренчел чистарту. Элек рәшәт-

Реклама

кәләрнең тишекләре 14 миллиметр диаметрлы иде, яңа рәшәткәләр бинасында чистарту ике этапта ясалачак: башта 12 миллиметрлы рәшәткәләрдә, аннары 5 миллиметрлыда.

Рәшәткәләр бинасы белән комтоткычлар берләштерелгән, алар хәзер радиаль су агымнары исәбенә эшли. Хәзер һава агымы да кушылачак, ул агынтыларны комнан чистартуны яхшыртачак һәм аннан ары булган биологик чистартуны җиңеләйтәчәк. Моннан тыш, рәшәткәләр бинасы каршында агынтыларны нефть продуктларыннан арындыручы флотатор булачак.

Икенче яңа объект – беренче чистартуны үткән сәнәгать һәм шәһәр агынтылары смесителе. Анда болгаткычлар тора, агынтыларны гомогенизлау өчен һава агымнары эшли, аларга беренчел биологик чистартуны эшен башкарырга тиешле микроорганизмнар да кушылачак. Иске смеситель ачык типта булган, яңасы ябык булачак, һәм чистарту процессында барлыкка киләчәк барлык һава агымнары «Ятаган» җиһазына җыелачак.

Бәдрәфләрдән чыгучы начар исләрне юкка чыгаручы «Ятаган» җиһазын пилот режимында инде үткән җәйдә үк сынаганнар. Бүген аларның сәнәгать режимында өч данәсе җитештерелгән, аларны июль уртасына рәшәткәләр бинасына, смесительгә һәм химик пычранган калдык суларның беренчел тондыру урыннарына куячаклар. Бу тондыру урыннарына реконструкция ясала, алар да шулай ук ябык. Чистарту корылмаларында исләрне катгый рәвештә бетерергә карар иттеләр.

«Ятаган»ның принцибы гади, әмма куәтле – плазмалы чистарту: импульслы төп разрядта тондыру урыны көзгесеннән өскәрәк күтәрелгән парларга ут төртелә, ионлаштыру органик кушылмаларны (исләң чыганагын) гади фрагментларга тарката, алар, окисьләшеп, углекислый газга һәм суга әверелә. Тәҗрибә-сәнәгать сынаулары яхшы нәтиҗә күрсәткән – 89%ка якын чистарту.

БЧКны үзгәртеп коруның беренче этабы заказчыга 600 миллион сумнан артыграк бәягә төшә. Әмма инде икенче этапка да проект документациясе әзерләнә. Экспертизадан соң, 2017 елда аны тормышка ашыру башланачак.

БЧКны үзгәртеп коруның икенче этабы калдык суларны чистартуның сыйфатын яхшыртуга басым ясый. Төгәл максат бар: агынтылар сыйфат ягыннан балыкчылык хуҗалыгы билгеләнешенә ярашлы булырга тиеш. Бу җиңел бурыч түгел, диләр белгечләр, аеруча ике күрсәткеч буенча: фосфор һәм азот чистартуга иң авыр бирелүче пычраткычлар. Әлегә аммонийлы азотны чыгарып, нитратлыга әверелдерү генә кулланыла. Әмма аны зарарсыз, молекуляр хәлгә китерү инде көн тәртибендә тора. Денитрификация (нитратлашудан арындыру) узелы кушылачак.

Тиешле җиһазлар шулай ук бер ел элек тәҗрибә-сәнәгать сынаулары үтте һәм яхшы нәтиҗәләр күрсәтте. Биологик чистарту корылмаларын үзгәртеп кору өчен шулай ук үз илебез табышлары (ноу-хау) кулланылачак. Узган җәйне тәҗрибә-сәнәгать режимында пилот җиһазында эшкәртелгән ташландыкларны технологик чистарту инде куллануга әзер.

Өченче этап та булачак – «химия» белән нык пычранган калдык сулар өчен 1200 миллиметр диаметрлы 13 километр озынлыктагы яңа коллектор төзү. Агынтыларның артып торган күләменә хәзерге коллекторның көче җитмәячәк. Шушы ук этапта чыгу юлындагы фильтр станцияләре алыштырылачак – Камага чыгарыр алдыннан суны гравий һәм ком аша хлорлап чистартып бетерүче биниһая зур корылмалар бу. Биредә тагын да заманчарак һәм нәтиҗәлерәк дисклы фильтрлар урнаштыру күздә тотыла.

ТКНХның 2014–2020 елларга каралган дүртенче экологик программасы нәкъ менә БЧКны үзгәртеп коруга юнәлдерелгән. Аларны тулысынча реконструкцияләү компаниягә 3 млрд сумнан артыгракка төшәчәк. Мондый зур чыгымнарга ТКНХ Түбән Кама кешеләренең сәламәтлеге һәм иминлеге хакына бара. Расланган программа теләсә нинди очракта да тормышка ашырылачак.

PRESSA.RU

ЭКОМЕНЕДЖМЕНТ ГАМӘЛДӘ

Су саклау зоналары елында «Средволгаводхоз» ФДУ гадәти режимда эшли: Куйбышев сусаклагычы су саклау зонасы мониторингын үткәрә, аны тиешле халәткә китерү өчен тәкъдим-киңәшләр бирәләр. Нәтиҗәле экологик менеджмент өчен оешма республиканың «ЭКОлидер» конкурсы дипломына лаек булган.

«Средволгаводхоз» 2000 елда оештырылган һәм РФ Табигать министрлыгының Су ресурслары федераль агентлыгына карый. ФДУдагы 85 белгечнең 55е – инженер-техник хезмәткәр, шул исәптән дүртесе фән кандидаты. Алар су ресурсларын өйрәнү, рациональ файдалану һәм саклау, оешманың оператив идарәсе карамагындагы суларның тискәре йогынтысын кисәтү һәм юк итү, Түбән Идел БВУга су объектларын һәм аларның су ресурсларының торышы һәм кулланылышы мәсьәләләре турында мәгълүмат җиткерү белән шөгыльләнә.

«Средволгаводхоз» директоры Фоат Мөхәммәтшин әйтүенчә, соңгы еллардагы иң кискен проблемаларның берсе – ярларны ныгыту корылмаларының гамәлдә булганнарын төзек хәлдә тоту һәм яңаларын төзү. «2012–2020 елларда Россия Федерациясендәге су хуҗалыгы комплексын үстерү» федераль максатчан программасына Татарстан территориясендәге 10 объект кертелгән, аларның гомуми бәясе 1,5 млрд сумга якын. Хәзерге вакытта биш объект куллануга тапшырылган, ә менә калган төзелешләрне финанслый башлау кризис сәбәпле инде икенче ел рәттән кичектерелә. Шул ук вакытта Кукмара районының Нократ елгасы буенда урнашкан Лубян бистәсен су басудан саклау өчен ашыгыч чаралар күрергә кирәк. Моны нигезләү өчен таләп ителгән материаллар пакеты әзерләнгән һәм «Росводресурсы»га җибәрелгән.

«Средволгаводхоз» ФДУның оператив идарәсендә 11 яр ныгыту корылмасы бар, шуларның сигезе – ТР территориясендә. 2016 ел ахырында тагын өч объект кушылачак. Корылмаларның гомуми озынлыгы 15 км га якын.

Кызганычка, инде өченче ел федераль бюджеттан Менделеевск янындагы Тойма елгасын чистарту өчен акча бирелми, юкса, монда су басулардан шактый зыян килә. Әмма кризиска кадәр нидер эшләргә өлгердек. 2013 елда Буа янындагы Карлы, Саба районының Кызыл Мишә авылы янында Мишә елгасында һ.б. урыннарда су басуга каршы чаралар (елга төбен тирәнәйтү) үткәрдек.

Әле шушы көннәрдә генә урыннарда су саклау зоналарының чикләрен һәм Куйбышев сусаклагычының яр буе саклау полосаларын мәгълүмат белән билгеләү өчен бюджет бурычларының лимитлары җиткерелде. Бу моментны ике ел көткән идек.

ФДУның төп горурлыгы – гидрохимик лаборатория, ул коры җир өслегендәге суларга, норматив чистартылган агынты суларына һәм агынты суларга физик-химик һәм биологик күрсәткечләр буенча күләмле химик анализ ясау максатында 2007 елда аккредитацияләнгән. Лаборатория Куйбышев сусаклагычындагы суның сыйфатына Түбән Идел БВУ раслаган программага ярашлы рәвештә дәүләт мониторингы үткәрә.

Күзәтүләр елына җиде тапкыр 12 урында алып барыла: суларның сыйфаты – 44 күрсәткеч, төптәге утырмалар – 11 күрсәткеч, гидробиологик анализлар (фито-, зоопланктон) – 14 күрсәткеч буенча. Белешмәләр ЕАИС ГМВО ачык системасына («Су объектлары мониторингы») кертелә.

Моннан тыш, ФДУ суны кулланучылардан 2-ТП «Водхоз» («Су куллану турында мәгълүматлар») отчетларын кабул итә, һәм бу су сыйфатының торышы турындагы мәгълүматлар базасын тагын да киңәйтә.

Су ташу һәм су басу чорында махсус техника белән җиһазландырылган авария-ярдәм бригадасы даими әзерлектә тора. Пычраклардан арындыру өчен киртәләнгән бон, сорбентлар, сиптергечләр, вакуум җайланмасы, сүтелә торган резервуар бар.

ЮНЕСКО үткәрә торган «Тере су» (Идел көнә) программасы кысаларында «Средволгаводхоз» ел саен 67 нче гимназия кадетлары өчен тематик экология чаралары үткәрә һәм балалар рәсемнәре күргәзмәсе оештыра. Яшьләргә экологик тәрбия бирү эшебез Казан шәһәре мэриясенең Рәхмәт хаты белән билгеләнде. 2001 елдан башлап, оешмабыз «Хисап елында Татарстан Республикасы территориясендәге су объектлары, су хуҗалыгы системалары һәм корылмаларының торышы турында мәгълүмати бюллетень» чыгара.

– ТР Президентының Сусаклагычлар елына куйган бурычларын үтәү өчен чиктән тыш зур тырышлык кирәкми, – ди Фоат Мөхәммәтшин. – Законнар язылган, аларны бары тик барлык баскычларда да төгәл үтәргә генә кирәк.

«СРЕДВОЛГАВОДХОЗ» ФДУ Казан
420039, ТР, Казан шәһәре,
Коломенская ур., 12
Тел.: 8 (843) 560-52-40, 273-77-82,
e-mail: svvh@mail.ru

Реклама

facebook.com/protatarstan

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

ТАТАРСТАН

twitter.com/protatarstan

instagram.com/protatarstan

БЕЗНЕҢ ТӨРКЕМНӘРГӘ РӘХИМ ИТЕГЕЗ!

PRESSA.RU

Автор:
Ольга Туманская

ТАТАРСТАНДАГЫ КЛИМАТ. ТРОПИКЛАР ЯКЫНАЯМЫ?

Татарстанда җылыта. Һәм бу җылыну бик тиз бара. Безнең як өчен ят булган үсемлекләр, бөҗәкләр, хайваннар, шулай ук... вируслар һәм экзотик бактерияләр пәйда була. Климат үзгәрә, һәм бу гади бер кешенең фантазиясе генә түгел, ә галимнәрнең күзәтүе.

Күптән түгел генә Алабуга тирәсендәге Шишкин урманнарында йөргән идем. Кама буендагы ак чыршылар (пихта) юкка чыккан диярлек икән инде. «2010 елгы корылык бетерде», – ди, ачынып шундагы бер эксперт. Алты ел элек Татарстанда гадәттән тыш хәл игълан ителгән иде: июль аенда уртача айлык температура 26 градуска кадәр җитте – Сахараның төньягында диярсең! Ул елны ак чыршылар урманы гына түгел, игеннәрнең дә яртысы көеп беткән иде.

Хәер, мондый эсселек табигать хикмәтләренең соңгысы түгел әле. Туфан яңгырлары, гарасатлар, боз сугу Татарстанда сирәк күренеш түгел инде. Узган ел Казанда җил агачларны екты, реклама такталарын аударды, түбәләрне кубарып атты, ә Назарбаев урамында өр-яңа бер бинаның түбәсен кешеләр өстенә каплады...

ҖЫЛЫНУ? ҮЗГӘРҮ?

Норвегия галимнәре Җир шарының климат үзгәрешләренә ничек бирешүен күрсәтүче карта төзегәннәр. Иң күп зыянны Кытай, Океания илләре, Көньяк Америка күргән икән. Россиядә исә – Ямал һәм Таймыр. Ләкин без, татарстанлылар да, зыян күрүчеләр рәтендә – урта, сары, зонага керәбез.

– Бездә глобаль җылыну түгел, ә климатның глобаль үзгәрүе күзәтелүен аңларга кирәк, – ди РТ Фәннәр Академиясенең Экология һәм җир асты байлыкларыннан файдалану мәсьәләләре институтының биомониторинг лабораториясе мөдире Олег Аськеев. – Температура режимы гына түгел, явым-төшемнәр күләме дә үзгәрде. Табигать бәла-казаларының саны артты – зилзилә, гарасат, давыл, боз... Климатыбызга хас параметрларның үзгәрү динамикасын белдерүче әлеге трендлар, шул ук Европа белән

Кышның беренче яртыеллыгындагы температураның күпьеллык динамикасы (ноябрь–декабрь, Казан һәм аның әйләнә-тирәсе)

C⁰/ел



Җәйнең беренче яртыеллыгындагы температураның күпьеллык динамикасы (май–август, Казан һәм аның әйләнә-тирәсе)

C⁰/ел



ЯКЫН МЕҢЬЕЛЛЫККА ФАРАЗ

...Дакар белән Калькутта су астында. Санкт-Петербургны, Стокгольм белән Хьюстонны да су каплаган, Венеция, Копенгаген, Шанхай һәм Гонконг җир йөзеннән гаип булды, Майами һәм Яңа Орлеан да диңгез төбендә... Бозлар эреп, Дөнья океанындагы су өслеге 65 метрга күтәрелде, ә җир йөзендә һаваның уртача җылылыгы – 27 градус.

Бәхеткә, Милли география җәмгыяте экспертлары тарафыннан әзерләнгән бу прогноз якындагы елларны күздә тотмый әле. Ул алдагы биш мең елга исәпләнгән. Әмма бүгенге реаль прогнозлар да – әллә ни сөенерлек түгел. Исәпләүләр буенча, планетабызда климатның глобаль җылынуы соңгы 50 ел эчендә 0,6 градусны тәшкил итте. Әмма шушы күрсәткеч кенә дә кырыс Гренландия белән Антарктикадагы искиткеч зур күләмдәге боз запасының юкка чыгуына китерде: 1992 елдан башлап санаганда, еллык «югалту» 65 млн тоннаны тәшкил итә. Моның киләчәктә нәтиҗәләре нинди булыр, әлегә билгесез...

Графикларны Олег Аськеев әзерләде.

PRESSA.RU

чагыштырганда, Татарстанда бигрәк тә кискен чагыла.

Артык сүз куертып тормыйча, галимнәр миңа республикабызның тормышын климатология җәһәтеннән чагылдыручы таблица һәм графикаларын ачып сала.

– Әгәр дә дөньяда һава торышының 0,6 градуска гына җылынуы күзәтелсә, безнең төбәктә соңгы 25 елда еллык уртача температура 1,68 градуска артты! Тенденция тотрыклы: ел саен якынча 0,067 градуска җылына бара. Башка күпчелек илләр белән чагыштырганда, Россия территориясендә климатның җылынуы ныграк сизелә. Бездә бу процесс, Финляндия белән Скандинавиягә караганда, күпкә тизрәк бара. Явым-төшемнәргә килгәндә, 2010 елгы корылыкка карамастан, аларның да уртача еллык күләме республикабызда арта. Бу бигрәк тә кыш айларына хас.

АЛДА... БОЗЛЫК ЧОРЫ

– Климатның үзгәрү сәбәпләре хакында галимнәр күптәннән бәхәсләшә: табигый сәбәпләр ягындагыларга антропоген факторны сәбәп итүчеләр каршы баса, – ди Олег Аськеев. – Без лабораториябездә тарихи экология белән шөгыльләнәбез, күп гасырлар элек планетадагы табигый мохитне торгызабыз. Шуңа күрә шәхсән мин үзем климатның үзгәрүе 80 процентка табигый процессларга бәйле дип уйлыйм.

Галим әйтүенчә, кешелек климатны 250 еллап кына күзәтә әле. Аның глобаль җылынуын күрү өчен бу җитсә дә, сәбәпләре хакында дөрес нәтиҗә ясау өчен 250 ел гына аз. Табигатьтә бар нәрсә дә билгеле бер дулкынга көйләнгән диган фикер бар – һәр 100, 1000, 10 000 ел саен климат үзгәрә, ә инде бу цикллар туры килә икән, климат системасында баланс югала, нәтиҗәдә биосфера зыян күрә.

– Хәтта Идел буе Болгар дәүләте чорында да климат бөтенләй башка төрле булган, – ди Олег Аськеев. – Күпкә җылырак булган. Әлегә без аны куып җитмәдек, әмма инде ерак та калмады.

– Алда безне нәрсә көтә?

– Без бозлык чоры аралыгында, плейстоцен дәверенең чигендә яшибез. Голоцен дип атала ул. Бераздан (исәп меңнәрчә еллар белән бара) бик нык суытачак һәм чираттагы бозлык чоры урнашачак. Тигезлекләрне бик зур бозлык каплап алачак. Ләкин, миңа калса, тормыш шартлары аның кадәр үк кырыс булмаган берничә аерым утраулар калачак. Элеккегесе кебек, биота шунда сакланачак. Урта Идел һәм Көньяк Уралда тоташ боз катламы булмаган, дип уйлыйбыз без. Безнең җәнлекләр дөньясын тикшерүләребез, шул исәптән молекуляр-генетик анализ ярдәмендә дә, шуны исбатлый.

КЫШ – КЫСКАРАК, ҖӘЙ – ОЗЫНРАК

Аның каравы, якын киләчәктә безне искиткеч һава торышы көтә. Ә инде гел кабатланып тора торган бәла-казаларга килсәк, без беркайчан да куркыныч булмаган шартларда яшәмәгәнбез. Узган гасырларның тарихи язмаларында боз хакында да, давыл, гарасат һәм көчле корылык хакында да әйтелгән язмалар бар.

– Әйе, катаклизмнар ешаячак, ләкин гомуми климат үзгәреше Татарстан өчен уңай булачак. Җәйләр озынрак һәм җылырак, ә кышлар – карлырак, йомшаграк һәм кыскарак булыр, – дип ышандыра галим.

Һәм әйткәннәрен дәлилләп, яңадан таблицаларын чыгара. Алардан күренгәнчә, узган гасырның 60нчы елларыннан башлап майдан алып августка кадәр булган уртача температура ике градуска арткан. Шул ук вакытта бездәге климат Финляндия (андагы җәйләр нибары 1 градуска эссерәк) яки Скандинавия (1,6 градуска) караганда тизрәк үзгәрә. Бездә хәзер җәй дә иртәрәк килә. Кемдер аны күчмә кошларга карап билгели, кемдер – гөлҗимеш куагына. Ул температура үзгәрешләренә гаять сизгер. Быел бу куак янә иртәрәк чәчәк атты.

Уртача ел температурасының күпьеллык динамикасы (Казан һәм аның әйләнә-тирәсе)

C°/ел



Даими кар катламы пайда булу датасының күпьеллык динамикасы

1нче октябрьдән исәпләгәндә, көннәр саны/ел



Татарстан кышы да өметне аклады: расланган тренд – ноябрьдән алып декабрьгә кадәр ике градуска җылытты (минус җидедән минус бишкә калды). Раштуа суыклары хәзер инде тарихта гына калып бара. Ә иң мөһиме – Татарстанда кышлар сизелерлек кыскара. Кыш килүе эреми торган кар катламы ятуыннан чыгып билгеләнә. Соңгы 25 еллык күзәтүләр нигезендә галимнәр әйтүе буенча, кыш ел саен уртача берәр көнгә соңарып килә икән. Ягъни хәзер кар 25 көнгә соңрак ята!

– Климат яхшыру сәбәпле, безнең хәзер мөмкинлекләр дә күбрәк, һәм алардан файдаланып калырга кирәк! – дип инандыра галим. Үземнең хайваннар һәм үсемлекләр дөньясын күзәтүләрем вакытында теркәгән күрсәткечләрем 80 процент уңай үзгәреш бирә.

ШАКАЛ ҮТЕП КИТМӘДЕМЕ?

Уртача еллык температураның бер генә градуска артуы да флора һәм фаунаның сизелерлек үзгәрүенә китерә, ди биомониторинг лабораториясе мөдире.

– Кызыклы тенденция – климатның глобаль җылынуыннан Татарстан яшелләнә. Җылы һәм дымлы һавада үсемлекләр яхшырак үсә. Күп кенә бөҗәк, хайван һәм кошларның да популяциясе артты.

– Быел бөтен кеше сандугачлар күп сайрады, ди. Аларның да саны артканмы?

– Әлбәттә. Ләкин узган ел алар тагын да күбрәк иде – кошларның да үз цикллары бар.

– Татарстан урман-кырларында безнең өчен ят булган хайван һәм бөҗәкләрнең күренүен көтәсеме?

– Без аны ел саен күзәтәбез. Ачык бер мисал – суфи чикерткә (богомол). Элек ул көньяктарак яши иде, хәзер инде бездә дә күренә. Безнең өчен ул хәтта яхшы да. Суфи чикерткә турыканатлылар, мәсәлән саранча, белән туклана. Ул – авыл хуҗалыгында ярдәмче.

Галимнең сүзләренә караганда, көньяктарак яшәгән һәм безнең республика өчен ят булган дистәләрчә яңа төр бик тиздән безнең урманнарны, кыр һәм сулыкларны үз итәчәк. Мәсәлән, көньяк кошларының камышлыкта яшәүче төре булган мыеклач песнәк (усатая синица) инде Татарстанда да очрый. Җылы яратучылардан булган кызыл үрдәк (огарь), кызыл томшыклы чумгалак (красноносый нырок), озын аяклы шөлдинең (кулик ходулочник) яшәү ареаллары безгә кадәр киңәйде. Татарстанга хәзер шакал да кергәли.

Җылы яратучылардан булган кызыл үрдәк (огарь), кызыл томшыклы чумгалак (красноносый нырок), озын аяклы шөлдинең (кулик ходулочник) яшәү ареаллары безгә кадәр киңәйде. Татарстанга хәзер шакал да кергәли.

Кызганыч, ләкин климат җылыну белән бергә салкын яратучы үсемлекләребезнең дә бер өлешен югалтабыз. Андыйлар: мүк җиләге, күк җиләк. Ләкин башка төрле тенденция дә бар – тереклек дөньясының төньякта көн күрүче кайбер вәкилләре, киресенчә, көньяккарак күченә. Мәсәлән себер бурсыгы (росомаха) белән ак төлкенең яшәү ареалы хәзер көньяктарак. Тайгада яшәүчеләрнең күп кенә төрләре дымлы һаваны үз итә икән, аеруча кыш айларында. Шуңа күрә яңа климат флора һәм фаунаны тагын да ныграк үзгәртәчәк.

КЕШЕ ФАКТОРЫ

Ә менә кеше белән эшләр ул кадәр куаныч түгел. Һава торышының кисәк бозылуы, эссе белән салкын чиратлашуы, көн дәвамында температураның кисәк сикерүе сәламәтлеккә зарарлы.

– Хәзер санитар табиблар йогышлы авыруларның кинәт артуына әзер торырга тиешләр. Кайсыбер чирләрне бөҗәкләр таратырга мөмкин. Ләкин чирләрне төп таратучы шулай да кеше үзе.

Халыкның күченүе безнең территориядә элек күренмәгән чирләрнең таралуына китерергә мөмкин. Аларның кайберләре бернәчә ел элек кенә безнең «агрессив» җирлектә яши алмый иде. Хәзер инде җылы һәм дымлы климат африкалы кайбер чирләрнең таралуы өчен уңай шартлар гына тудырачак.

Галим әйтүенчә, әлеге тенденция елдан-ел үсәчәк кенә. Шулай да, кешелек дөньясының күпчелеге белән чагыштырганда, татарстанлыларны оҗмах шартларында яшәячәк дип әйтсәң дә була.

– Әгәр дә безнең төбәктә явым-төшемнәрнең күләме ел саен арта барса, Җир шарында моның киресе күзәтелгән урыннар да күбәя. Якын киләчәктә корылыктан Африка кыйтгасының күпчелек өлеше һәм Азиянең көньягы иза чигәчәк. Анда глобаль масштабтагы катаклизмнар көтелә. Экологик катастрофага кадәр Кытайга да күп калмады, ләкин бу антропоген тәэсир нәтиҗәсендә – әйләнә-тирәлекнең коточкыч пычрануы сәбәпче. Һиндстан, Пакыстан, Бангладеш, Иран һәм Әфганстан инде бүгеннән үк эсселектән җәфа чигә. Киләчәктә безне халыкларның бөек күчеше көтә. Монысы инде сәяси яки икътисадый сәбәптән түгел, ә климат аркасында булачак...

ИЯЛӘШЕРГӘ ВАКЫТ!

Кызганычка, яңа климат шартларына ияләшүнең конкрет программасы Татарстанда гына түгел, Россиядә дә юк. Климатологлар мондый планның кирәклеген искәртә – үзгәрүче әйләнә-тирәлек шартларына инде бүгеннән үк ияләшә башларга кирәк.

– Климатның үзгәрүе бөтен икътисадның һәм сәнәгатьнең дә үзенә яраклашуын таләп итә, ләкин, кызганыч, әлегә без бу мәсьәләне чишүдән бик ерак, – ди Олег Аськеев. – Юллар, күперләр, биналар төзеше технологияләрен үзгәртергә кирәк. Кышын кар күбрәк явачак икән, кардан чистарту өчен дә акчаны бюджетка күбрәк салып калдырасы...

Галим белән корган әңгәмәбездә авыл хуҗалыгы темасы аерым урынны били. Быелгыдай көзге уҗымнарны аның күптән күргәне булмаган икән. Моның кадәр печәнне дә. Майның җылы килүе һәм дым печәнгә яраган быел. Терлекчелекне үстерү республикага реаль файда китерәчәк.

– Читтән кертелгән товарларны үзебезнекенә алыштырган шартларда климат безгә булышчы гына. Менә шуның өчен дә адаптация стратегиясе кирәк. Без табигый катаклизмнарның зыянын гына киметергә түгел, ә бүген безгә табигать биргән мөмкинлекләрне үзебезгә файдалы итеп куллана да белергә тиеш, – ди Олег Аськеев.

PRESSA.RU

ТӘКЪДИМ ИХТЫЯҖДАН УЗЫП КИТКӘН ЧАКТА

Август аена ТР Премьер-министры өстәленә «Татарстан Республикасы муниципаль районнары үсеше стратегиясе» дип аталган документ ятарга тиеш. Әлеге документта муниципалитетларда кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү перспективаларына аерым игътибар бирелгән булырга тиеш. Күрәсең, сәнәгать гигантлары һәм углеводород ятмалары булмаган якларда, КУЭ район икътисадының локомотивы ролен уйнарга бик мөмкин.

Автор:
Татьяна Колчина

Июньдә республиканың Кече һәм урта бизнес предпритиеләре ассоциациясе үз советының хәзерге катлаулы икътисадый шартларда Татарстанның төньяк-көнбатыш төбәгендәге муниципаль районнарда инвестицион партнёрлыкны үстерүгә багышланган киңәйтелгән утырышын үткәрде. Утырыш өчен мәйдан итеп Теләче районы сайланды, бирредә 2014 елда Татарстан Президенты катнашында иң уңышлы сәнәгать паркларының берсе булган «Теләче» ачылган иде.

Мантыйк буенча, аграр районнарда кече бизнесны үстерүдә һәм ярдәм итүдә төп басым биредә үк үстерелгән авыл хуҗалыгы продукциясен эшкәртүгә ясалырга тиеш (бу җәһәттән Татарстандагы эш шактый җитди – мисал өчен, республика үз территориясендә җитештерелгән итнең өчтән берен генә үз көче белән эшкәртә, калганы яңадан эшләү өчен күрше Чувашия, Мари Эл һәм ТР белән чиктәш башка төбәкләргә китә). Ләкин авыл хуҗалыгы продукциясен беренчел эшкәртүдә тиешле инфраструктура булдыруны таләп итә, ә бусы, үз чиратында, аз булмаган күләмдә чаралар җәлеп итүгә китерә – хәтта браунфилд тибындагы зур булмаган сәнәгать паркын төзү өчен минималь инвестицияләр дә 100 млн сумга якын акча тәшкил итә (гринфилд төзү исә әлеге күрсәткечтән берничә мәртәбә кыйбатрак бәягә төшә). Һәм шул вакытта төп сорау килеп чыга да инде: бу очракта кем инвестор булып катнашырга тиеш: дәүләтме, муниципалитетмы, әллә шәхси эшкуарлыкмы?

Гамәлият күрсәткәнчә, дәүләт үз өлешен кертергә әзер – бу турыда Совет утырышында муниципалитетлар вәкилләре үзләре сөйләде. Шулай, Кукмара районы Башкарма комитетының җитәкчесе урынбасары Чулпан Хәнәфина сүзләре буенча, киләчәктә булачак шул ук исемле гринфилд-парк коммуникацияләр төзү этабында гына да 100 млн сум (шуларның 80 млн сумы – федераль бюджет чаралары) кертергә планлаштырыла.

Советта аның Мамадыш районыннан килгән хезмәттәше Шамил Сабиров әйткән сүзләргә караганда, «Зөя» индустриаль паркына инде 188 млн сум акча инвестицияләнгән; ел азагына кадәр тагын 137 млн сум кертеләчәк, ә проектның гомуми бюджеты 380 млн сумнан да ким булмаска тиеш.

Шулай да, сәнәгать парклары һәм мәйданчыкларының тулу күрсәткечләренә карасак, нигезле сорау туа – тирене эшкәртү нәтиҗә бирә торган эш микән: бүген инде әзер булган объектларның уртача тулылануы 35%тан артмый. Кем гаепле диган сорау туа: муниципалитетмы, паркларның идарәче компанияләреме яки эшкуарлар үзләреме? Әлеге хәл буенча Совет утырышында катнашучыларның фикерләр төрле булды.

Шулай, Кече һәм урта бизнес предприятиеләре ассоциациясе вице-президенты Рәфыйк Шәйхетдинов сәнәгать паркларын үстерүгә идарә ресурслары җитми дип уйлый. Җирле хакимият вәкиле – ТР Арча районы җитәкчесенең беренче урынбасары Олег Спичкин муниципалитетларның район бюджетына кергән акчаларны «корбан» итәргә куркулары һәм муниципаль дәрәҗәдәге салым ставкаларын киметмәгәннәре турында сөйләде (моннан тыш, Спичкин фикере буенча, районнар авыл хуҗалыгы продукциясен эшкәртүдәге технологик чылбырны булдыруда җитәрлек дәрәҗәдә актив түгелләр). Ә эшкуарлар үзләре җирле хакимиятнең республика дәрәҗәсендә кече бизнес ихтыяҗларына басым ясауда җитәрлек көч куймавына зарлана иде.

...2015 елның февралендә, ТР Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы һәм ТР Икътисад министрлыгының эшчәнлегенә нәтиҗә ясый торган уртак коллегиядә Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов һәр муниципаль районда инфраструктура мәйданчыклары булдыру максатын куйды. Әлеге процесс шактый актив: мәйданчыклар проектлана, чаралар бүлеп бирелә. Эш башлап җибәрү өчен күп кирәкми дә – бары тик мәйданчыкларга чын бизнесны җәлеп итү генә.

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

БУ САНДА ТӘКЪДИМ ИТӘБЕЗ:

Кама судагы турында **НИ ӨЧЕН** җырлар языла

Казан туристларны үзенә **НИЧЕК** җәлеп итә

Музей белән җилкәннәр арасында **НИНДИ** уртаклык бар

PRESSA.RU

НИ ӨЧЕН БЕЗГӘ КИЛӘЛӘР
ҺӘМ ТАГЫН ДА КИЛСЕННӘР ӨЧЕН НӘРСӘ ЭШЛӘРГӘ



Туристлар энергиясен саклау кануны, һичшиксез, бар ул. Һәрхәлдә, үз-үзләрен алга этәрү белән алдан ук шөгыльләнгән төбәкләр (алар арасында Татарстан да бар), хәзерге вакытта, чит илләрнең гүзәллегенә ихтыяҗ кимү шартларында, туристларның моңа кадәр күрелмәгән көчле агымын һәм туризм өлкәсендә хезмәт күрсәтү күләмнәренең артуын күрсәтә.

Безгә ни өчен киләләр һәм тагын да күбрәк килсеннәр өчен нәрсәләр эшләргә кирәк? «Татарстан» журналы җәйге туризмның кызган мәлендә шушы сорауларга җавап эзләде

PRESSA.RU

Автор:
Айдар Сәгъдиев

КАЗАН – УЛ «БАШКА»

– Чөнки Казан – ул «башка», – дип җавап бирә Мәскәүдән килгән Дмитрий, үзенең юлдашы белән Игенчеләр сараен күзәтә-күзәтә. – Шәһәрнең үз йөзе бар. Мәскәү, мәсәлән, өлешләргә бүленә, аны хәтта шунда туып-үскән кешегә дә бөтен итеп күзаллау кыен. Моннан тыш, Казан Идел буе шәһәрләренә караганда, төзегрәк. Биредә кунакханәләр кыйммәт түгел, сервис арзанрак. Иң кызыгы, әлеге сервис әдәпле. Биредә яшәүче халык та бик итагатьле.

«Казанның яңа феномены» төсен алган әлеге итагатьлелекне рациональ рәвештә аңлатып була. Татарстанның кунакханәләре, гомуми туклану учреждениеләре, транспорт компанияләре, сувенир кибетләре, гидлар – туризмга мөнәсәбәте булган хезмәтләр өлкәсенә караган һәркем өчен соңгы елларда мотив әйбәт булды, алар бу өлкәне үзләштерделәр.

– Аңлашыла ки, туристларны моннан алып чыгу белән шөгыльләнгән фирмалар хәзер, киресенчә, аларны бирегә җәлеп итүгә йөз тота. Ләкин, шуңа да карамастан, алар урамнан килгән кешеләр түгел, – ди «Казан шәһәренең туристик-мәгълүмат үзәге» генераль директоры Наталья Абрамович. – Бу җәһәттән берәүгә дә бернәрсә аңлатып торасы юк.

АЯК БАСАР УРЫН ЮК, АЛДА – МӘСКӘҮ

Бездә Татарстан туристик могҗизасы турында әлегә сөйләмиләр, гәрчә үзенчәлекле географик-климат рентасы булмаган төбәк өчен тармакның үсеш тизлеге шаккатырлык. Соңгы дистә елда туризм өлкәсендәге хезмәтләр күләме – 5,5 тапкырга (2005 елдат – 2 млрд сум, 2015 елда 11 млрд сум булган), туристлар агымы 4,5 тапкырга (600 меңнән 2,7 миллионга кадәр) арткан. Халык саны һәм географик урнашуы буенча бердәй территорияләрдә мондый күренеш күзәтелми. Әйтик, Түбән Новгород өлкәсенә былтыр туристик-экскурсия үткәрү максатлары белән 1,2 миллион кеше килеп киткән (2005 елда – 526 мең, Татарстандагы кадәр үк диярлек), Самара өлкәсендә туристлар агымын нибары 850 мең кешегә кадәр күтәрергә планлаштыралар… 2025 елга.

Өстәвенә Татарстанга нәкъ менә ял, рекреация максатлары белән килүчеләр саны арткан. Хәзер исә шул ук 600 мең туристны елына Болгар белән Свияжск тәэмин итә.

– Быелгы май бәйрәмнәрендә Казан отельләре йөз процентка диярлек тулган иде, – дип сөйли Абрамович ханым. – Һәм эш футбол буенча Россия кубогы финалына килгән җанатарларда да түгел: аны үткәрү мәсьәләсе хәл ителгәндә кунакханәләрдәге урыннарга алдан броньнар алып куелган иде инде. Быелгы җәйдә дә – бу юлы ул «югары ноктасыз» гына уза – кунаклар узган елгыга караганда күбрәк булыр, дип уйлыйм.

Казанның туристик киләчәге турында, шул рәвешле, борчылырлык түгел, дияргә дә ярый – аның Россиядәге өченче туристик башкала булуы турындагы иҗтимагый фикер формалашты һәм ныгый гына. Ә менә килгән туристны Татарстанда озаккарак калдыру мәсьәләсендә эшләргә була әле. Моның өчен башкаладан читтәге туризмны көчәйтергә кирәк – танып белү туризмының периферияләге үзәкләрендә, шулай ук табигатьтә.

ЕЛЫНА 12 ВАКЫЙГА

– Кешегә бер атналык ялы вакытында нәрсә кирәк? – ди «Companion SP» туроператорының генераль директоры Сергей Пасечник. – Башкаланы карап чыгу өчен аңа ике-өч көн җитә, алга таба аның шәһәрдән читтәге объектларга барасы килә, табигать белән хозурланасы, биредәге ашлардан авыз итәсе, башка төр активлык күрсәтәсе. Татарстанда бу ресурс әлегә җитәрлек дәрәҗәдә эшләми, бездә шәһәр янында тәрәзәләре елга-күлләргә, урманга һәм башка шундый табигать күренешләренә карап торган объектлар аз. Асылда, авыз тутырып Казан янында урнашкан «елның теләсә кайсы фасылында кабул итә торган шәһәр-курорт»ны гына әйтеп була.

(Җәя эченә алып шуны әйтеп китик: шуңа охшашлы икенче проект – Югары Ослан районындагы «туристик-рекреацион кластер» булырга тиеш. Төрле инфраструктурасы булган әлеге проект 2011–2018 елларга исәпләнгән «РФдә эчке туризм үсеше» федераль максатлы программасына кергән, 440 миллион сум дип бәяләнгән.)

Икенче яктан, ди эксперт, безнең тәкъдимнәргә вакыйгалар графигы җитеп бетми. Сабантуй, Шаляпин һәм Нуриев фестивальләре кебек «җанландырып җибәрердәй» этаплар кирәк.

– Аз дигәндә, елына 12 вакыйга, – дип төгәллек кертә Пасечник. – Циклы булса, тагын да яхшырак. Ул чагында без җәдвәл буенча партнерларга алдан ук сата алыр идек. Россиялеләр генә ял көннәрен Казанда үткәрү турында карарны бер атна эчендә хәл итә. Ә чит ил туристлары, кагыйдә буларак, үзләренең каядыр чыгу планын ярты ел алдан төзи башлый.

БЕР ДӘ ОЯТ ТҮГЕЛ

Наталья Абрамович, киресенчә, вакыйгаларга бәйле туризмны Татарстанда начар түгел, дип бәяли, ә менә ике йолдызлы һәм аннан да түбәнрәк арзанлы кунакханәләр санын арттыру комачауламас иде. Аларның табыш китерү вакыты озаккарак сузыла, шуңа да инвесторлар андыйлар белән бик кызыксынмый. Шулай да эконом-классны сегменттагы туристлар агымының көчәюе (яшьләр һәм аерым туристлар) хостел форматына ихтыяҗны арттыра. Соңгылары Татарстанда күбәя бара, ә алар өчен, Абрамович сүзләренә караганда, «бер дә оят түгел».

Туристик үзәкләрдән дә оялырлык түгел – һәркайсын аерым алганда. Эре һәм киң танылган Болгар, Свияжск, Алабуга, Чистай һәм Тәтештән башка (узган ел боларда туристлар агымының үсеше 30 проценттан артып киткән), туристларны Алексеевск, Кама Тамагы, Кукмара, Азнакай һәм башка районнар да җәлеп итә алыр иде. Әмма проблема шунда, булган куәтләрне туристик фирмалар өчен кызыклы итеп бер-ике көнлек уңайлы пакет белән бәйләү катлаулы. Бер яктан, әлеге ноктәлар бер-берсеннән ерактa урнашкан, икенче яктан, аларның кайберләре эшләнеп бетмәгән. Кайдадыр туристларны урнаштыру кыен, кайдадыр кунакларны кабул итү өчен кешеләр (мәсәлән, җирле музейларда), ашханәләр, сувенирлар, интерактив җитми.

ПОТЕНЦИАЛ БАР

Экспертларның фикере бер мәсьәләдә уртак: Татарстан көннән-көн бер көнгә туры килгән туристлар санын арттыруга таба бара. Бары тик ел фасыллары алышкандагы уңайсыз чорлар һәм фестивальләрне озайту мөмкинлеге булмау гына комачаулый. Ә югарыда телгә алынган Югары Ослан районындагы кластер кебек эре проектлар исә инвестицияләр эзләүгә дә, төрле документларга кул куюлар белән дә бәйле вакыт таләп итә.

– Потенциал, һичшиксез, бар. Безгә тагын да күбрәк кешеләрне китерү мөмкин булыр иде. Моның өчен төрле

Фото: Ната Смирнова



проектлар турында сөйләшүләр алып барыла, шул исәптән чит илләрдән дә акчалар җәлеп итү буенча да. Болар тиз генә эшләнми. – ди Сергей Пасечник. – Моннан тыш, туризм күп нәрсәләргә бәйле. Әйтик, чит илләргә круизга чыга торган туристларны безгә кайтару өчен күпләп яңа көймәләр төзергә кирәк. Күреп торасыз, әлегә бу эшләр эшләнми.

ЧИТ ИЛГӘ ЧЫГЫП УЙНАУ

Әгәр Россиядә эчке туризм советлардан соңгы тарихта үзенең иң яхшы чорын кичерсә, чит илләрдә ял итү базарында кәефләр бөтенләй башка. Узган елның көзендәге мәгълүм вакыйгалардан соң, Мисыр юнәлешләрендәге югалтуларга «букинг» һәм чит илгә чыгу туризмының интернетта тәкъдим ителә торган яңа юллары көндәшлек тудыра.

– Кешеләр бөтен дөнья буйлап фатирларны арендага ала, үзенекен бирә – бу бик яхшы, – ди «Терра инкогнита» компаниясе директоры Эльвира Маркова, торакларны арендага алу һәм бирү буенча онлайн-мәйданнарның популярлыгы үсүен шәрехләп. – Бу арзан һәм барган җирендә абориген сыйфатында яшәп алу өчен әйбәт вариант. Һәм ул безнең өчен көндәшлек тудыра.

Фатирларны алмашып торуны күздә тота торган «кунакчыллык челтәре»ннән аермалы буларак, рейтинглары һәм онлайн-уңайлыклары белән яхшы. Бу челтәрләр, Маркова сүзләренә караганда, кулланучыларның шактый тар даирәсенә исәпләнгән, һәм алар урта сыйныф кешеләре белән эшли торган компанияләр өчен куркыныч түгел.

Чит илләргә гадәти юл белән чыгуга килгәндә, ул хәзер, билгеле, сизелерлек дәрәҗәдә артка тәгәрәде.

– Туристик агентлыкларның саны Татарстанда, бөтен җирдәге кебек үк, азайды. Туроператорлардан алынган мәгълүмат буенча, элек республикада 600 килешү булган, хәзер – 400, – дип сөйли Маркова. – Туроператорларга финанс (аерым алганда, франчайзинг) вазыйфалары белән бәйле булганнарга авырга туры килде, Мисырга юллар ябылу белән бәйле алар күпне югалтты. Хәрбиләргә, судьяларга һәм күп кенә дәүләт хезмәткәрләренә чит илгә чыгу тыелу да аларның кесәсенә суга. Моннан тыш, 2014 елда банкротлыкка чыккан туристик фирмаларның кайтавазы да ишетелә әле – болар туризм тармагына тулаем ышанычны какшаткан иде.

Боларның барысы да быел чартер һәм даими авиарейсларның кимүенә, даими рәвештә чит илгә ял итәргә баручы клиентларның азаюына һәм чит илгә мөстәкыйль рәвештә барып ял итеп карарга теләүчеләр санының артуына китергән. Даими авиарейслары гамәлдә булган Мисырга да хәзер мөстәкыйль рәвештә йөриләр. Бу илләрдә ял итүне өстен күрүчеләрне куркынычсызлык гарантиясе, мөстәкыйль рәвештә броньлаштыруга караганда арзанракка төшә торган (күпләп булган өчен) туристик пакетларның булмавы да куркытмый, күрәсең. Аңлашыла ки, бу илләрдә ял итәргә теләүчеләр саны артык күп булмаячак.

Нәтиҗәдә, базарда 15–20 ел эшләгән эре уенчылар да кыл өстендә тора. Аларга базарны демпинг чүп-чарыннан чистартачак дулкын киләчәк дигән фаразлары ярдәм итә. Һәрхәлдә, алар чүп-чардан арынуны түземсезлек белән көтә.

Хәзер исә, бик күп туристлар яратып йөри торган ял итү урынынннан колак каккач, аларның да, аларны хезмәтләндерүче тармакның да диверсификация өчен этәргече барлыкка килде. Кемдер чит илләргә яңа маршрут сала, кемдер исә Россиянең көньяк курортларына йөз тота. Ә анда һәрвакытта да «бизнесны намуслы итеп алып бару»чылар көтеп тормый: кунак йортлары хуҗалары да, кечкенә кунакханә тотучылар да, хәтта ки эрерәк кунакханәләр хуҗалары да форсаттан файдалануны улай күрә.

– Минемчә, иртәме-соңмы безнең турист Мисырга әйләнеп кайтачак, – дип шәрехли Маркова. – Аңа хәтле Россия көндәшлеккә сәләтле продукт тәкъдим итәргә тиеш, бу процесска кушылып китәрлек булсын. Аны чарасызлыктан түгел, ә яхшы, сыйфатлы продукт булган өчен сатып алсыннар.

ТАТАРСТАНДА
КУНАК БУЛАСЫҢ –

«ТАТАРСТАН»НЫ
УКЫ!

PRESSA.RU

ЯШЕЛ СОУС БЕЛӘН БИРЕЛӘ ТОРГАН ФАХВЕРК

Франкфурт мәйданы янәшәсендәге Ремерсберг ресторанында – гомер бәйрәме. Агачтан тупас итеп ясалган өстәлләрдә – балчык кувшиннар, алардан алма исе бөркелә. Һәм Гулливерга исәпләнгән порцияләр. «Риндвюрст» сосискаларыннан өелгән таулар (Frankfurter Rindswurst), кәтлит белән тозлы кәбестә чүмәләләре (Rippchen mit Kraut), Франкфуртның катлам-катлам яшел соусы (Grüne Sauce) ...

Барысы да нәкъ өч йөз ел элек куну йортларында булган кебек. Бары тик шәрәфле бюргерлар урынына дөньяның бөтен почмакларыннан җыелган чит ил кешеләре генә бәйрәм итә. Озын өстәлләр әйләнәсендәге агач эскәмияләрдә салам кыстырырлык урын да калдырмыйча, кувшин арты кувшин бушата болар, ул арада берьюлы утыз өч телдә җирле кухняны макташалар – куптарган шау-шуларыннан колак тонарлык, билләһи…

– Би-эм – би-ел… – Күрше өстәл артында утыручы Гуамнан килгән кунаклар үзләренә ошаган сүзне бертавыштан кабатларга тырышкан булалар. – Килеп чыкмый гына бит. Бэмбел – бирәдә җитештерелгән алма шәрабын салып бирә торган балчык кувшин. Аны инде Гуам камардослары шулкадәр күп татып караган ки, үзләренчә дә телләрен көчкә әйләндерәләр.

– Бэм-бел. – Безнең компания әлегә дөрес итеп әйтә ала, шуңа да мәҗлесне дәвам итәргә һәм нәтиҗәләр ясарга була. Беренчесе: җиһазларның махсус тупаслыгы һәм гадилеге һәм, әлбәттә, биредәге ризыкларның күләмнәре – хуҗалар туристларны нәкъ шушы кармакка каптырып кына тора. Шулай дөрес тә: затлы менюга ия ялтырап торган типик ресторанда кайда да утырып була. Мәсәлән «музыкалы сыр»ны тагын кайда татып карап була? Әйтергә кирәк, сыр һәм башлы суган – шикләндерә. Мондыйны ашаганнан соң, билгеле инде, организм, сукрана-сукрана, җырлап җибәрергә әзер. Ләкин туристлар капланып ашамаса да, тәэссоратларын яшерми: экзотика!

Бездә берәр кайда чит ил кешесен шаккатырабыз дип, әйтик, борчак боткасы тәкъдим итәргә кыярлар идеме икән? Гәрчә, ә ни өчен тәкъдим итмәскә әле? Ул да безнеке бит, әллә кайчангы. Менталитет кушмыймы? Ә менә галиҗәнап бюргерлар, сезгә бэмбелдан шәраб коя-коя, әлеге салам төсле эчемлек салынган традицион тустыганның кайчандыр махсус рәвештә кытыршы һәм тонык итеп эшләнүен сөйләргә дә оялмый, гафу итегез, пычрак бармак эзләре күренмәсен өчен. Элек заманда һәр салган саен савытны юып тору гадәте булмаган шул…

Сүз уңаеннан, Майндагы Франкфурт тирәсендә генә җитештерелә торган алма шәрабы турында җирле халык сөйләү генә түгел, ә җырлап бирергә әзер. Шушы эчемлеккә төйнәлгән рестораннар гына – бер урам. Аны ресторанда чын-чынлап авыз итеп карыйм, дисәң – оттырасың. Моның өчен башка урыннар бар.

ВИНОГРАД БАКЧАЛАРЫН АШАП БЕТЕРГӘЧ

Зур һәм бәләкәй шешәләр арасында Йенс Беккер әфәнде урта гасырлардагы алхимикны хәтерләтә. Галимнәрдә була торган хыялыйлык, аскетларга хас йөз чалымнары һәм музыкантларча нечкә бармаклар.

Автор:
Әскәр Сабиров

PRESSA.RU

– Гомумән, мин үзем туризм буенча менеджер, – ди Йенс. – Әмма пенсиягә чыгар алдыннан рәтләрәк һөнәр үзләштерәсем килде. Һәм менә бу нәрсәгә китерде.

Ел саен 25 мең литр алма шәрабы җитештерә торган предприятие һәм Майндагы Франкфурт үзәгендә кибет килеп чыккан. Кибеткә анда яшәүче халык үзенең канистралары белән йөри – шәрабны монда шулай сату кулайрак. Ә безгә әлегә башкасын тәкъдим итәләр – шешәлесе бозлы чиләктә «тирли». Йенс аны цирк фокусчысы кебек җитез хәрәкәт белән ача, ә кытыршы тустыганнарга күбекләнеп уйный-уйный шәраб ага. Сизелер-сизелмәслек кенә нечкә хуш исе булмаса, сыйфатлы шампаннан аера да алмас идем. Гаҗәп тә түгел, Франкфурт эчемлеген әзерләү процессы гадәти шампанныкыннан бик аз аерыла. Монда гадәти алмалар, ә анда – кояш нурларын җыйган тәлгәшләр.

Йенс ул арада 2014 елгы уңышның шәрабын тәкъдим итеп шаккатыра. Алмаларның 15 төрле сорты һәм бары тик бирегә үсә торган ранет кына гөлләмәне төгәлләп куя – бу исә Бордо төбәген сөючеләрне дә уйланырга мәҗбүр итә.

– Ә менә монысы гадирәк, бэмбелдан эчә торганы, – дип тәмамлый Йенс дегустацияне.

Кайберләребез җирле эчемлекнең халыкчан вариантының да начар түгеллеген абайлап ала, һәм ул кувшинны үзең белән туган якка алып кайтып булмавы өчен борчыла – алып кайтып җиткереп булмый.

Дөрес, Франкфурт шәраб осталарының эзләнүләре мине әллә ни тәэсирләндермәде. Шушында ук, Гессен Җирендә, Франкфурт белән янәшәдә йөзләгән гектарлы бакчаларда рислинг сортлы виноград үстерә торган данлыклы Рейн үзәне булганда, ни өчен тагын бер төрле җимештән эчемлек уйлап чыгарырга кирәк булган инде?

– Бервакытны, уналтынчы гасырда, Майндагы Франкфурт әйләнәсендәге барлык виноград бакчаларын ниндидер бөҗәк ашап бетерә, шәраб коярга да калмый, – ди шәраб остасы уйларымны укыгандай. – Шунда алмаларны искә төшерәләр.

– Ә бездә уналтынчы гасырда бөҗәкләр бөтен алманы ашап китә, шунда бодайны искә төшерәләр, – дип шаярта безнекеләрнең берсе.

Ошыймы-ошамыймы, әмма җирле халык аннан туристлар өчен «фишка» ясый белгән. Сүз уңаеннан, бездә «алга киткән социализм» дәверендә алма шәрабын һәрбер кибеттә саталар иде. Ләкин ул болганчык, җитлекмәгән черек алмалардан коелган совет шәрабы хәтта ки туристлар өчен дә чамадан тыш экзотика булыр иде. Халык аңа «Мичурин яшьләре» дигән кушамат такты.

Күңелсез нәрсәләр турында сөйләмик әле. Аның каравы безнең авылларда әле дә шундый эчемлекләр ясыйлар – немецларның төшенә дә керми! Ә инде экзотикага килгәндә, дөнья кендеге ул түгел бит әле. Франфуртта да башкасы белән җәлеп итәрдәй урыннар күп. Лайза Минелли, «Роллинг стоунз» яшәп киткән борынгы отель янындагы коктейль-ресторанда туристларны менә дигән заманча ризыклар белән сыйлыйлар. Коктейльләрне биредә аяктан егып салырлык рецептлар (кайчак туры мәгънәсендә дә) буенча, тәтенләнә торган коры боз, Һималайдан китерелгән исләр һәм башка шундый экзотика белән ясыйлар. Һәркемгә – үзенекен.

Франкфурт янәшәсендә генә йөзләгән гектарда «рислинг» сортлы виноград бакчалары булган атаклы Рейн шәраб үзәне урнашкан.

БАД-ХОМБУРГНЫҢ КАРАҢГЫ АЛЛЕЯЛӘРЕНДӘ

Кич белән соң гына Бад-Хомбург үзәгендәге курорт паркның аллеяләре буйлап һава сулап йөргәндә адашa яздым. Кара күзлекле таныш түгел берәү ярдәмгә килә.

– Монда югалып булмый, – дип тынычландыра ул. – Бу бит Сукырлар аллеясе! Исләр буенча табарга була. Һәм тавышларны тыңлап…

Без йөри торган аллеянең уникаль булуы ачыклана. Аны начар күрүчеләр, читтән ярдәмгә таянмый, үзләре генә йөри алсын өчен махсус эшләгәннәр. Уртада фонтаннар каскады, аларның гөрләү тавышы – акустик ориентир. Аллея буйлап чәчәк түтәлләре сузылган, түтәлләрнең һәркайсының «үз чәчәге» бар: берсендә розалар, икенчесендә – болын чәчәкләре, өченчесендә – тәмләткечләр… Һәркайсының үзенең «кычкырып торган» исләре.

Хәтерлисезме, былтыр Парклар һәм скверлар елында Казан парклары танымаслык булып үзгәрде? Ә хәзер күз алдына китереп карагыз: аларны төзекләндерү эшләре бер яки ике ел гына түгел, ә күп дистә еллар дәвамында алып барыла, ди. Фантастика булып тоеламы? Һич юк. Бад-Хомбургтагы курорт паркын каядыр йөз илле ел дәвамында бала караган кебек карыйлар. Өч колач җитмәстәй иманнәр, мәһабәт чинар агачлары һәм гасыр яшендәге юкәләр аллея буйлап плацтагы солдатлар кебек тезелгәннәр. Саф сулы буалар камил итеп түшәлгән инглиз чирәмнәре кысаларында гәүһәр кебек ялтырый, чәчәкләрнең хуш исе Рейн рислингыннан да көчлерәк исертә.

Курорт паркын периметр буйлап йөреп чыгар өчен миңа бер сәгатьтән артык вакыт кирәк булды – бу алты чакрымнан озынрак. Әмма мондагы раритетларны күз йөгертеп кенә карап чыгар өчен дә бер көн җитмәс иде. Сәламәтләндерү чишмәләре булган галереяләр, фонтаннар, теннис кортлары (әйтергә кирәк, Европадагы иң борынгылары), гольф өчен кыр, СПА-үзәкләр, рус чиркәве һәм хәтта тай гыйбадәтханәсе – аны кайчандыр шәһәргә Чулалонгкорн патша бүләк иткән булган…

Ләкин бирегә килгән кешеләрнең күбесе бу матурлыкны күрми, диләр. Паркның үзе кебек борынгы Kaiser-Wilhelms-Bad – Вильгельм кайзерындагы коену урынында

тукталалар. Нәрсәсе беләндер рейхстагны хәтерләткән купшы бинада тормыш ыгы-зыгысыннан туйган әфәнделәр релакс-процедуралар ала. Һәм горурлык хисе белән тулыша. Аларның фани түшкәләре кайчандыр император үзе дәүләт эшләреннән ял иткән мәрмәр ванналарда гөлчәчәк таҗлары арасында чапырдый.

Мин бальнеология кебек мунчадыр-ваннадыр ише күңел ачуларга битарафрак кеше, дөресен әйткәндә, аны күңелсез, дип табам. Ләкин прәннек кебек фахверклы шәһәрчекләр, замок, кальгә, кирхалар буйлап берничә көн дәвамында марш-бросок биргән һәм немец кухнясы сынавын үткән туристлар өчен йөзьяшәр имәннәр астындагы СПА-ял, сауна, массаж һәм савыктыру сулары – мөгаен, иң кирәгедер. Ял иттерүче эшсезлекне яратмаучылар өчен дә шөгыль бар.

– Күңелсез?! – дип гаҗәпләнә Юлия Майер. – Ә сез казинога барып карагыз!

Курорт паркында казиноны унтугызынчы гасырда ук ачканнар. Кызыклы уруннар, кухня, ял һәм күңел ачу – туристик бизнесны уңышлы формуласын немецлар кичә генә түгел, хәтта өченче көнне ук уйлап тапканнар булып чыга.

Гөнаһ һәм озын акчаларга илтә торган юл караңгы аллеяләр аша үтә иде. Кайсыдыр мизгелдә мине кемнәндер авыр карашы туктатты. Борылып карасам: аллея читендә куаклар арасында сәерсенгән кыяфәттә Достоевский утыра. Соңгы тиененә кадәр оттырган. Бронзадан.

КИСИЛЁФФШТРАССЕДА ОЧРАШЫРБЫЗ

Рулеткалы берничә уен өстәле, ниндидер нәүмиз крупьелар. Өстәлләр артында – тонык күзле һәм ялтыр-йолтыр килеп торган гәүһәрләр таккан чал чәчле әфәнделәр. Басканнар да акчаларының каядыр агуын бер хафасыз гына күзәтәләр. Һәм «зеро»ның үләргәме-калыргамы икәнен хәл итүен көткән дуамал күзле бер генә яшь кеше дә юк...

«Тәмугтан» калган беренче тәэссоратлар мине командировкага бирелгән тәүлеклек акчаларымнан колак кагачагыма ишарә итә. Шөкер, бирегә килүемнең максаты да билгеле – Бад-Хомбург туристик үзәгенең прокуристы Бурхард Бигалке белән кичке аш ашау. Шулай да туристларның җиңелчә киемен костюм-чалбарга алыштырырга туры килде – казинога дресс-код паспорт кебек үк мәҗбүри, болардан башка сезне бирегә карточкагызда бер-ике миллион евро аунап ятса да кертмәячәкләр.

– Безнең шәһәрдәге казино тыйнак үзе, әмма шәҗәрәсе камил, – дип яклый аны Бурхард. – Унтугызынчы гасырның алтмышынчы елларында илдә комарлы уеннарны тыйгач, аның хуҗасы Монте-Карлода икенче бер казино ача. Ягъни Бад-Хомбургның уен йорты – Европадагы иң данлыклы казиноның әбисе булып чыга.

«Әби» дә шук әле! Бүген дә анда килгән кешеләр дистәләрчә мең евро акчасын калдырып чыга.

– Казиноның еллык табышы – 26 миллион евро, – дип аңлата Бигалке, – бу сумманың 65%ын салым буларак Гессен Җире һәм Бад-Хомбург ала. Җирле бюджет өчен зур булмаган керем.

«Зур булмаган» – ай саен бер миллион дүрт йөз мең евродан артыграк сумма дигән сүз. Илле мең кешелек халкы һәм югары технологияле предприятиеләре булган Бад-Хомбург (биредә, аерым алганда, гемодиализ җиһазлары ясыйлар) өчен казинодан кергән акча, чыннан да, төп керем түгел. Ә менә унтугызынчы гасыр урталарында биредә үзләренең байлыкларын калдырган чит ил әфәнделәре шәһәр-курортның төп инвесторлары булган да инде.

Һәм барысыннан да алдарак, әлбәттә, руслар булган. Бад-Хомбургта графиня Софья Киселева турында риваятьләр йөри. Янәсе, ул уен өстәле артында утыз елга якын гомерен уздырган. «Пәрдә артында» аны, авыру һәм хәлсез килеш, хезмәтчесе алып килә торган булган – ул инде үзе генә йөри дә алмаган, әмма яшьләрчә комарлыгын саклаган. Киселева рулетка артында аз утырмаган, әмма бу бер дә куркыныч булмаган – казино акцияләренең бер өлеше аныкы, һәм ул бирегә килүчеләр һәм үзе дә оттырган акчалардан тотрыклы рәвештә процентларын алып барган.

Бад-Хомбургтагы Кисилёффштрассе урамы – рус графинясы истәлеге ул, ә графиня исә «Уенчы» романындагы Антонида Васильевнаның прототибы. Достоевский үзе биредә бронзада мәңгеләштерелгән, исеме курорт паркындагы сукмакка бирелгән, портреты казино залында эленеп тора – биредә аңа уңыш елмая торган булган. «Мин паркта һава сулап йөри идем, әйтергә кирәк, биредә бер тылсым бар! Искиткеч парк, пансионат иң шәбе, яхшы музыка. Монда яшәп тә булыр иде, шушы каһәр суккан рулетка булмаса...»

Германиядә тарихны кадерли һәм саклый беләләр, үзләренекен генә түгел. Сезгә Бад-Хомбургта рус чиркәвен ачу тантанасына рус патшасы Николай IIнең хатыны белән килүен, Изге Мария католик гыйбадәтханәсендәге кыңгырау турында – аңа Варвара Столыпина күп суммада акча белән хәйрия ярдәме күрсәткән – сөйләми калмаячаклар. Ә Майндагы Франкфуртта Метцлер вилласына кадәр барырга киңәш итәчәкләр – анда Гоголь «Мертвые души»ның икенче томын язган... Һәм хикмәт монда немецларның безнең илне һәм мәдәниятне сөюендә түгел, аннан прагматиграк сәбәпләре бар. Беренче чиратта туристик базарның конъюнктурасы. Шушы ук сәбәп белән, мәсләлән, күп кенә рестораннарда менюлар, отельләрнең сайтлары һәм хәтта шәһәрләрдәге кайбер элмә такталар кытай телендә язылган: немецлар табышны планлаштыра белә.

...Бәлки, Безнең Казанга да кайчан да булса Германия туристлары университетка Энгельгардт бүләк иткән обсерваторияне карарга, Гудериан сугышырга өйрәнгән казармаларны күрергә дип махсус килә башлар? Яки бөек химик Бутлеров биләмәсендә урнашкан, ата-бабалары Курляндия немецларыннан булган Карл Фукс музеена? Үзебезнең дә, башкаларның да тарихын кадерләргә өйрәндек диярлек. Ә менә туристлар базарын яулау – алга таба бурычлар шул.

PRESSA.RU

Редакция кухнясы

КАМА СУДАГЫ *һәм* *аның туристик үзенчәлекләре*

Җәй көннәре кухня ышанычлы рәвештә табигатькә – мангаллар, казаннар, шарабаннар һәм ачык утта һәм саф һавада ризык әзерләү өчен адәм баласы уйлап тапкан башка шундый пешерү-ыслау корылмаларына күчә. Безнеке, редакциянеке дә, шулай эшләде әле.

Фото: Ната Смирнова

Без республиканың иң матур районнарының берсе – Кама Тамагына юл тоттык. Үз вакытында аны Ельцин да Татарстанның энҗесе дип атаган иде. Без дә Борис Ельцин белән килешми булдыра алмыйбыз. Мондый табигый гүзәллек, әлеге гүзәллекне һәрьяклап юып торган Идел-Чулманның мул сулары бүтән бер җирдә дә юк! «Татарстан» үзе тикшерде!

Автор:
Татьяна Вафина

PRESSA.RU

– Мин балыкны алты яшемнән үк әзерлим, – ди Татарстан Республикасының Туризм буенча дәүләт комитеты рәисе.

КАМА СУДАГЫ

Плитә янында, дөресрәге, корымланып беткән зур балык казаны янында бүген республиканың туризм буенча төп кешесе – Сергей Иванов кайнаша. Аның белән бергә Кама Тамагы районы башлыгы – Павел Лоханов, хәтерләсәгез, Кама судагы турында үзе иҗат иткән җыр белән ютубта ярты миллион карауны җыйган башлык үзе! Хәзер әнә шул судакның туган ягында балык тотарга теләүчеләр бермә-бер артты. Дөрес җыр әнә ниләр эшли ала!

– Мәскәүдән, Самарадан, Ульяновскидан, хәтта Омскидан үк киләләр, – дип санап китә танылган хитның автор-башкаручысы, үз районына туристлар җәлеп итү буенча әнә шундый пиар-адым ясавыннан бик канәгать булып.

Сөйләнгәннәргә таянып һәм тере тавышка, бернинди фонограммасыз башкарылган җырны тыңлап, без, әлбәттә инде, уха пешерәбез.

УХА ОСТАСЫ

– Мин уханы алты яшемнән үк пешерәм, – дип белдерә ТРның Туризм буенча дәүләт комитеты рәисе. – Балык тотуга мәхәббәтне миндә этием уятты. Балачагымнан ук аның белән бергә Ак диңгездә дә, Төньяк Двинада да балык тоттык... Ә инде Татарстанда балык тоту өчен мөмкинлекләр чиксез! Уханы бик еш пешерергә туры килде. Шуңа да мин балыкның да теләсә ниндиен, уханың да теләсә ниндиен пешерә беләм. Әмма иң яхшысы – иң гадие, ул классик санала инде – ниндие тотылган, шуннан пешерелгәне. Яшелчәләрне күбрәк саласы – үзебездә үскәннәрен. Һәм, әлбәттә инде, кулың килсен – балыгы да таралып китмәслек, яшелчәләре дә пешәрлек булсын, тоз белән борыч balansы сакланcын.

ТӨРЛЕ ВАК БАЛЫК

Кайнап торган шулпага шактый гына күләмдә вак балык салып җибәрәбез – монысы шулпа куерак булсын өчен кирәк. Аннары без аларны сөзеп алабыз да шулпага яшелчәләр салабыз. Һәм Сергей Иванович кишерне тәгәрмәчләп, суганны бөҗралап, әрчелмәгән яшь бәрәңгене икешәр кисәккә тураган арада, без уха пешерү өчен ник Кама Тамагын сайлавыбыз турында тыңлыйбыз.

– Хәзер иң яхшы вакыт, бу чорда җәен эләгә. Ул су температурасы белән бәйле: өстә – 22, тирәндә – 16 градуска җиткәндә була. Менә – яңа тотылган җәеннәрнең берсе, – дип үзенең уңышы белән



Безгә кирәк булачак:

- 3,5 кг авырлыктагы яңа тотылган судак балыгы
- 4 кг авырлыктагы яңа тотылган җәен балыгы
- Шулпа өчен үзең теләгән кадәр вак балык
- Бик зур өч кишер
- Бик зур өч суган
- 2 кг яшь бәрәңге
- Лавр яфрагын – кызганмаска!
- Тоз белән борыч – тәмена карап
- Бер чәркә аракы – ахырга таба
- Кисәү – 1 данә (ахырда)

1. Турыйбыз!

2. Салабыз!

3. Өстибез!

4. Агызабыз!

Фото: Ната Смирнова

– А судак инде бездә – һәрвакыт шәп!

мактана Павел Лоханов. – Игътибар итегез: браконьерларча түгел, җимгә тотылган. Ә судак инде бездә – һәрвакыт шәп!

БРАКОНЬЕРЛЫККА КАРШЫ КӨРӘШ

– Балыкны ятьмәләр белән браконьерларча аулаучыларны җаным-тәнем белән күралмыйм, – ди Сергей Иванович. – Алар сусаклагычның балык запасларын үтерәләр. Ятмәләр ыргыталар да, анда балыклар кереп урала, сасый, анда кысалар кереп тула, шунда барысы череп, еллар буе су эчендә ята... Минемчә, кешеләр булган байлыгыбызга җаваплырак карарга тиештер. Әгәр күршегезнең законсыз рәвештә ятьмәләр куюын күрәсез икән – туктатыгыз. Чөнки аерым балыкчыларның вакытын экономияләү, ялкаулыгын аклау хисабына табигатькә сакчыл мөнәсәбәттә булган һәвәскәр балыкчылар һәм профессионаллар бу эшне сыйфатлы эшли алудан мәхрүм. Браконьерлык аркасында безнең балык запаслары юкка чыга. Ә бит балык – ризык кына түгел, бирегә туристларны җәлеп итү чарасы да. Ятьмәгә тотылып тере авырлык бәясенә сатылган балыкка караганда, Омскидан монда балык тотарга килгән кешенең республикага китергән икътисадый файдасы күпкә зуррак. Ул кеше кунакханәдә туктала, азык-төлек, балыкчы кирәк-ярагы сатып ала... Шуңа да браконьерлык темасы шул дәрәҗәдә актуаль ки, аның белән көн дә көрәшергә кирәк.

– Көрәшәбез. Уылдык чәчү вакытында полиция һәм аучылар белән чыктык, браконьерларны тотып, камерага төшердек, интернет челтәренә куйдык, – дип искә ала Павел Лоханов. – «Тоттыңмы – җибәр!» акциясен киңәйтәбез. Ана балык эләксә, җибәрергә кирәк. Аерым балыклар өчен аерым зурлык исәбе бар. Үсеп җитмәгән икән – җибәр, үссен. Әйе, балыкчылыктан башка яши алмаган балыкчы-фанатиклар бар. Алар теләсә кайсы вакытта тоталар да, тотарга ярамаганын җибәрәләр. Мондый балыкчылык зыян китерми.

ИНФРАСТРУКТУРА ҖИТМИ

Шулпага яшелчәләр салына. Алар пешкән арада без Кама Тамагында бөтен Россия кешеләре диярлек балык тотуына карамастан, балыкчылар һәм туристларның әле җитәрлек түгеллеге турында беләбез. Ни өчен? Татарстан энҗесе турында бөтен кеше дә белмиме әллә?

– Безгә инфраструктура җитми, – ди туризм башлыгы. – Бирегә ерактан килгән балыкчылар өчен. Татарстанда уникаль табигать шартлары – акватория, балык, һава торышы... Бу – балык тоту гына түгел, истәлекле мәдәни-тарихи урыннар белән дә танышу – алар бөтен республика буенча таралган, һәм аның теләсә кайсы ноктасында янәшәдә туры килгәнен эләктереп калырга була. Әмма безгә инфраструктура кирәк. Моның өчен туризм буенча дәүләт комитеты тарафыннан «Пять ветров» дигән проект эшләнде. Ул бирегә вакытларын сыйфатлы итеп үткәрергә теләгән туристларны җәлеп итәргә тиеш.

ЯҢА ПРОЕКТ

Павел Лоханов, зур чүмече белән уханы болгата-болгата, проектның эчтәлеге белән яхшылап таныштыра:

– Менә бездә Куйбышев затоны дигән бистә бар, Куйбышев сусаклагычы ярында урнашкан ул. Анда – искиткеч култык. Анда керү юлындагы зур утрау ябык акватория хасил итә. Көймә станциясе – марина урнаштыру өчен бик тә уңайлы, һәрьяклап җилләрдән ышыкланган уникаль урын. Әйтик, сәяхәтчеләр ял көне туры алган очракта, бу станциягә барып, куныпчыга, ял итә алыр иде. Икенче көнне – Тәтешкә юл тотарга. Кайту юлында Болгарда кунарга һәм Казанга кайтырга. Ә бит хәзер, кагыйдә буларак, еракка китмиләр – йә Свияжскига, йә Маркиз утравына гына баралар. Чөнки бөтенесе кайдадыр яр буенда

5. **Пешерәбез!**

6. **Төнәтәбез!**

7. **Татып карыйбыз!**

8. **Бүләбез!**

PRESSA.RU

тукталудан, канистраны тотып, өскә үрмәләүдән, көймәне калдырудан курка... Гомумән, ягулык бетү турында туктаусыз борчылып тору... Шуңа да Көймә станциясе төзү – Татарстанның туристик структурасы өчен зур адым ясауда бер дигән мөмкинлек ул.

«КЫРГЫЙЛАР»ГА – ГАИЛӘ ТУРИЗМЫ ҮЗӘГЕ

Икенче проектыбыз – кемпинг-үзәк. Россиядә иң зуры. Куйбышев сусаклагычы ярындагы урын мондый мөмкинлекне бирә. Җир мәйданы инде сайланган, әзерләнгән, ТР Президенты тарафыннан хупланган, хәзер без бу җирне тиешле категориягә күчерү белән шөгыльләнәбез һәм... инвесторлар эзлибез.

– Нинди проект соң ул?

– Хәзер әнә теге яр буйлап үтсәгез, күрерсез – анда чатырлар корылган. Кешеләр кыргый рәвештә ял итә. Учаклар, чатырлар, балык тоту, уха, шашлык... Кама Тамагына ел саен 500 000 балыкчы килә. 98% очракта – балык тотарга яратучы әти, ә хатынына һәм балаларга нишләргә? Мин үзем гаиләле кеше, дүрт балам бар, һәм киеренке эш графигында бөтенләй вакытым калмый. Ял көннәрендә гаиләм белән буласы килә. Балык тотасы да килә. Ә бит күңеллене файдалы белән берләштерергә була! Һәм балыкка бөтен гаиләң белән бергә чыгып китәргә: әти кешенең балык тотып күңеле булса, хатыны белән балаларына да эш табыла. Нәкъ менә «Кама Тамагы туристик комплексы» бөтен гаилә белән ял итү өчен тиешле инфраструктураны булдыруны күздә тота. Шулай итеп, без «Кама Тамагы» брендын гаилә белән ял итү территориясе буларак үстерәбез. Комплекс өч зонадан торачак: файдаланып тору өчен кечкенә өйләр, ашау-эчүне дә кушып булган автойорт һәм электр куллану мөмкинлегенә дә ия чатыр варианты...

УХАНЫҢ ҮЗӘГЕ

Кама Тамагының киләчәге турындагы хыяллардан безне Сергей Иванов аерып ала, аермыйча булдыра алмый, чөнки хәзер иң мөһим вакыт килеп җитте!

– Хәзер уханың үзәге булачак балыкны салу вакыты! – дип игълан итә ул һәм кайнап торган шулпага балыкның зур-зур кисәкләрен чумдыра. – Бүген безнең үзәк – судак белән җәен. Балыкны 10–15 минут пешерәбез,

– Балтадан ботка?
– Юк, кисәүдән уха!

артык түгел. Иң мөһиме – таралмасын.

– Уха табигатьтә пешәргә тиеш, – ди бу эшне белгәнен күрсәтеп, безне кабул итүче район башлыгы. – Өйдә уха түгел, балык ашы була ул.

– Хәзер лаврушка! – дип команда бирә безнең баш пешекче. – Чынлыкта, без инде финалда. Иске матур традиция буенча ухага 50 грамм аракы өстибез һәм кисәү тыгып төнәтәбез. Чын балыкчылар моның уха әзерлегендә төп ритуал икәнен белә.

– Класс!

Капкач белән каплыйбыз да, түземсезлек белән биш-ун минут көтәбез. Бераз төнәсен дә... алга!

Уха төнәгән арада Сергей Иванов безнең төбәккә туристларны җәлеп итә торган төрле бәйрәмнәр һәм вакыйгалар турында сөйләргә дә өлгерә.

– Бәйрәмнәр күп булырга һәм төрле аудиторияләргә юнәлтелгән булырга тиеш. Иң күңеллесе, әлбәттә, Сабантуй. Без быел бу бәйрәмгә туристлар җибәрү буенча Арча районы белән эшләргә керештек инде. Әмма бездә башка бәйрәмнәр дә күп – Питрау да, Уяв да... Милли бәйрәмнәрдән тыш, «Спас ярминкәсе, «Бөек Болгар» урта гасырлар сугышы фестивале кебек күңел ачу чаралары да бар. Тагын әле һич көтелмәгән чаралар – «Кабак бәйрәме», «Төнге Сабантуй», «Фиш-Сабантуй»... Зөя утравында театраль фестиваль, Чистайда әдәби фестиваль үтә. Бу вакыйгаларның һәркайсы – Татарстанга кабат-кабат килү өчен сәбәп була ала. Кабат килүче туристлар өчен бу зур ресурс. Чөнки бәйрәм ел саен төрлечә уза. Кемдер – кабат шул ук бәйрәмгә, ә кемдер башкасына килергә теләр.

КАМА ТАМАГЫНЫҢ ТАРТУ КӨЧЕ

– Ә кемдер уха фестиваленә килергә теләр, – дип, Павел Лоханов үзенең Кама Тамагы брендын тәкъдир итә. – Яки «Идел – Кама» балык тоту фестиваленә, безнең бит монда ике бөек елга бер-берсе белән кушыла... Менә, 12 июльдә, Балыкчы көнендә, бу фестивальне икенче тапкыр үткәрәчәкбез. Балыкчылар иртән балыкка китә, ә төш вакытына кайталар – анда тотылган балыкларын рәсми рәвештә үлчәү тантанасы була. Аннан соң тотылган балыктан уха пешерәләр, теләгән бөтен кешене шуның белән сыйлыйлар, халык белән күңел ачулар оештырыла. Быел гаиләләр арсында зачет үткәрергә телибез, анда

Фото: Ната Смирнова

гаиләләр арасында уханың төрле рецептлары белән ярышу булачак. Вакыйгалы туризм күзлегеннән караганда, иң кирәге инде. Кемпинг, үзенчәлекле атмосфера, спорт һәм иҗади башлангыч. Кешеләр монда яңа сәбәп белән килсен өчен. Нинди дә булса мастер-классларга – ник ярамасын? Бирегә рәссамнар килүен телим – бу матурлыкны рәсемгә төшерергә, – район башлыгы кулларын җәеп җибәрә. – Музыкантлар – яшьләрне өйрәтергә. Кинематографистлар – безнең табигатьне төшерергә. Биредә төрле иҗади юнәлештәге кешеләрне берләштерергә мөмкин. Кама Тамагы үзенә чакырып тора торган урын булсын өчен. Мәскәү янындагы Переделкино язучыларны чакырып торган кебек. Рәссамнарга монда – иркенлек, кая карама – бар җирдә матурлык. Килсеннәр дә, рәсемнәр ясасыннар.

Хәзер инде Татарстан гастрономиясе белән бәйле берничә маршрут та бар.

РӘССАМНАРГА – КАМА КИҢЛЕКЛӘРЕ

Кама Тамагы районы башлыгы бик нык ыгытып чакырган рәссамнар килеп җиткәнче һәм безнең ухабызны ашап бетергәнче, аны тәлинкәләргә бүлергә ашыгабыз.

Бу җаваплы эш белгечкә – Татарстан Республикасының Туризм буенча дәүләт комитеты рәисе Сергей Ивановка тапшырыла.

– Ничә кеше әле безнең? Бер, ике… биш… тугызау без, – дип саный ул халыкны. – Кулинария туризмы Татарстанда тиешенчә җәелдерелмәгән әле, – дип, һәр тәлинкәгә балыктан башлап, бәрәңгегә кадәр һәр ингредиентны тигезләп сала-сала (берәү дә үпкәләмәсен!), Сергей Иванов тәме белән шулай ук ухадан калышмаган яңа темага күчә. – Ә бит бу безнең индустрия өчен Клондайк. Чөнки бездә, татар һәм рус кухняларыннан тыш, башка күп кухнялар да бар: һәм мордва, һәм чуваш, һәм мари… Бездә яшелчәләр һәм монысы да мөһим – ликёр-аракы продукциясе дә үзебездә житештерелә, Питрәч районында «Скорлупино» дигән йомырка фестивале узды – шулай ук кулинария темасы. Хәзер инде Татарстан гастрономиясе белән бәйле берничә маршрут та бар. Мәсәлән, «Бик тәмле» дигәне татар кухнясы һәм төп татар ризыкларын әзерләү ысуллары белән таныштыра. Быел Казанда нәкъ менә милли кухня буенча икенче гастрономия фестивален уздыру күздә тотыла. Ул бер атна дәвам итәчәк. Безнең мактанырлыгыбыз бар: татарча каклаган каз да, үрдәк тә, эчемлекләр дә…

Әмма саф һавада ачыгырга өлгергән халык каз белән үрдәк турында ишетми дә. Җәен белән судакка басым ясый. Соңгысының, сүз уңаеннан, өстәлдә киптерелгән-какланган төре дә бар.

– Судакны эчен алмыйча ысларга кирәк, – дип, үзенең рецепты белән урткалаша Илдар Берхеев – безнең кечкенә балык бәйрәменең һәм «Өч яр» балыкчылык клубының хуҗасы. – Шул чакта гына ул коры түгел, ә сусыл булып чыгачак.

Дәшми генә килешәбез, чөнки авызыбыз буш булмаганда сөйләшү әдәпсезлек, җырлау инде – бигрәк тә. Әмма күңел җырлый:

Камский судак – это не пустяк,
Знает каждый рыбак…

Күңел җырлый… Бәлки, ул күңел дә түгелдер, ә Кама Тамагы районы башлыгы Павел Лохановтыр – туган җиренең патриоты, димәк, безнең «Татарстан»ыбыз кешесе дә.

PRESSA.RU

ТАТАРСТАН ТИРӘЛИ СӘЯХӘТ

Автор:
Әскәр Сабиров

Россия елгаларында – күңелле ыгы-зыгы. Туристларны үзләренең самими гүзәллеге белән әсир иткән һәм әбиләр сандыгындагы хатирәләрдәй тарих белән бәләкәй шәһәрләр буйлап круизлар модага керә. Татарстанга әлеге дулкында булырга Ходай Үзе кушкан кебек: Идел, Чулман, Нократ һәм Агыйдел буйлап круизлар гына түгел, «Җир тирәли сәяхәтләр» оештырырга була.

Теплоходыбыз пристаньга җыр-бию көйләренә уралып керә – ярда кадерле кунаклар килү хөрмәтенә халык ансамбле мәш килә. Зур шәһәрләрдә артык игътибар күреп өйрәнмәгән «кадерле кунаклар» каушап калган. Трап янында һәркемне өчпочмаклы борынгы эшләпә һәм бәйрәм мундиры кигән городничий үзе каршылый: кунакларга шәһәрне карау хокукы бирә торган документ инде имзаланган. Уңайсызлану бәйрәм хисе белән алышына. Без – Тәтештә!

ТӘТЕШ АЧЫШЛАРЫ

Шуннан соң дүрт сәгать буе без ачышлар ясыйбыз. Вшиха тавындагы беренче бистә биредә моннан мең ярым ел элек диярлек пәйда булган икән бит. Атаклы Кукрыниксларның берсе – Михаил Куприянов Тәтештә туган һәм үскән икән. Ә Илья Ильф, биредә булганнан соң, үзенең куен дәфтәренә Иделдәге иң текә баскыч турында теркәп куйган (Нью-Васюкидагы баскыч шуннан түгел микән?).

Боларның барысы турында да сүз уңаеннан аңлап аласың, чөнки Тәтештәге туган якны өйрәнү музее хезмәткәрләре уйлап тапкан экскур-

Фото: Әскәр Сабиров

сиядә тарих белән бергә чынбарлык та үрелеп бара. Каравыл каланчасы макеты янында укчылар белән чын арбалеттан атып карарга була. Беренче гильдия сәүдәгәр Петр Серебряков йортында борынгы рецептлар буенча әзерләнгән җимеш төнәтмәсе белән сыйлыйлар. Молоствовларның дворян утарында исә тере табигый һәйкәлне – 130 яшьлек Тау Алтае чыршысын тотып карарга мөмкин.

– Молоствовлар утары – безнең якның энҗе бөртеге, – дип сөйли Тәтеш туган якны өйрәнү музее директоры Наталья Понедельникова. – Асылда бу безнең төбәктә хәзерге көнгә кадәр сакланып калган бердәнбер дворян утары. Музей откан грантка аны реставрацияләү башланды...

Бүген туристлар утарда аның хуҗабикәсе моннан йөз ел элек иҗат иткән романсларны тыңлый һәм Мәхәббәт аллеясында йөри: аны Владимир Молоствов 1899 елда туйдан соң утырткан – хатыны тәүге тапкыр утарга килгән җиргә. Хуҗалар инде күптән бакыйлыкка күчкән, ә менә аллея, 460 төп төз карагач чын мәхәббәткә гимн булып һаман үсәләр.

Теплоходлар Тәтештә моннан өч ел элек туктый башлаган, һәм бу озакка сузылыр, дип өметләник. Кечкенә өяз шәһәре туристлар күңеленә хуш килә.

Туристлар өч көндә республиканың күп кенә истәлекле урыннарын – Болгар һәм Зөянең изге ядкәрләрен дә, борынгы сәүдәгәрләр шәһәре Алабуганы да күрә алачак.

ЧУЛМАН ҺӘМ НОКРАТ БУЙЛАП – СЕНА ҺӘМ РЕЙНДАГЫ КЕБЕК

Үзебезнең дә чит илләрнең Сена һәм Рона яки Рейн буйлап елга турлары оештыру тәҗрибәсен кулланмавыбыз мине һаман гаҗәпләндерә иде. Анда Европаның сөйкемле бәләкәй шәһәрләре буйлап круизлар искиткеч популяр һәм чагыштырмача арзан. Нигә икәне аңлашыла да: мәсәлән, туристларны хозурландырган бик популяр Париж – Кодебек – Онфлер – Руан – Ле Андели атналык круизы нибары 140 километр аралыкта уза. Туристлар исә үзләрен Франция буйлап күпкөнлек сәяхәт ясагандай хис итә. Ә бит бу шәһәрләрнең арасы илле километрдан артык түгел. Чагыштыру өчен, мәсәлән, Казаннан Самарага һәм кире Казанга ял көне туры ике тәүлектән азрак дәвам итә, ә ара мең километрга якын. Димәк, ягулыкка киткән чыгымнар да берничә тапкырга артыграк.

Аңлашыла ки, безнең бәләкәй шәһәрләрдә Руан соборы яки Ричард Арыслан Йөрәкнең урта гасырлардагы замогы юк. Әмма безнең үзебезнең бай тарихыбыз һәм «берничә адым ераклыкта» гына урнашкан гаҗәеп истәлекле урыннарыбыз бар бит! Бөек Болгар, Зөя шәһәр-утравы, Чистайда Борис Пастернак музее, кайчандыр Тәтештә тотылган гигант кырпы балыгына һәйкәл... Иван Шишкин һәм Надежда Дурова музейлары урнашкан борынгы сәүдәгәрләр шәһәре Алабуга... Безнең Идел, Чулман, Агыйдел һәм Нократның искиткеч ярларын гүзәллек һәм мәһабәтлек буенча чит илләрдәге рафинадланган ярлар белән чагыштырырлык та түгел бит!

Хәер, без моны әкренләп аңлый башладык бугай. 2014 елда елга тур-

PRESSA.RU

Бүгенге Ак мәчет – болгарлар җирендә диннең яңарышы символы.


Болгар ядкәрләре янынннан халык өзелми.

ларының бөтенроссия конкурсында Идел, Чулман һәм Нократ буенча, Чистай, Мамадыш, Нократ Аланы һәм Кировка тукталуны күздә тоткан яңа маршрут «ел круизы» дип аталды. Аның оештыручысы – Түбән Новгород компаниясе. Әмма моның Татарстанга да файдасы тиде – элегрәк Мамадышның яңа пристанена круиз теплоходлары туктамый иде. Хәзер Нократ буендагы шәһәрдә сирәк булса да «Александр Свешников» яки «Василий Чапаев» туктый һәм пассажирлар үзәк мәчетне, шифалы чишмәне һәм борынгы сәүдәгәр рәтләрен карарга юнәлә.

Алабуга, Чистай, Тәтештә круиз теплоходлары ешрак туктый – «Водоход», «Спутник-Гермес», «Волжские путешествия» һәм «Инфофлот» компанияләре бирегә үз маршрутларын салган инде. Ниһаять, чыннан да кече «Татарстан тирәли» дип атарлык тур быелгы навигациянең төп вакыйгасына әйләнергә вәгъдә итә. Туристлар өч көндә республиканың күп кенә истәлекле урыннарын – Болгар һәм Зөянең изге ядкәрләрен дә, борынгы сәүдәгәрләр шәһәре Алабуганы да күрә алачак. Сүз уңаеннан, әлеге круизга билетлар әле ул башланганчы ук сатып беткән. Моннан да элегрәк җирле туроператорларның берсе Болгар, Тәтеш һәм Зөягә керүне күздә тоткан тур оештырган булган. Аны, билгеле, Сена һәм Рона буйлап атналык круиз белән чагыштырып булмый әле, шулай да туристларга ошый.

– Татарстанда гүзәл урыннар һәм уникаль тарихи һәйкәлләр шулкадәр күп дип беркайчан да уйламаган идек, – дип сөйлиләр май аенда круизга Ижевскидан килгән Елена һәм Владимир. – Бу гаҗәеп сәяхәтне без озак онытмабыз. Һәм һичшиксез бирегә тагын бер киләчәкбез әле.

МОДАГА КЕРТҮЧЕЛӘРЕ – АЛАБУГАДАН

Татарстан һәм аның шәһәрләре өчен су туризмын үстерү потенциалының никадәр зур булуы Алабуга тәҗрибәсеннән яхшы күренә. Җирле музей-тыюлык генераль директоры Гөлзадә Руденко әйтүенчә, моннан унөч ел элек, Чулмандагы шәһәр тәүге тапкыр бөтенроссия круизлар базарына керергә омтылганда, биредә сигез теплоход туктаган. Былтыр исә аларның саны инде 130 га җиткән! Соңгы 9 елда Алабугага килгән туристлар саны 83 меңнән 279 меңгә кадәр арткан!

Әмма бу әле шул ук Тәтеш, Мамадыш яки Чистайда да туристлар саны геометрик прогрессиядә үзеннән-үзе артачак, дигән сүз түгел. Әгәр берике туристлык маршруты белән генә чикләнеп калсаң, гәрчә беренче вакытта алар бик популяр булса да, берничә елдан алар сәяхәтчеләрне кызыктырмый башларга мөмкин. Мондый хәл үз вакытында Россия круиз базарында булган иде инде: экскурсияләрнең гел бертөрле булуы аркасында, ихтыяҗ шактый кимеде...

Алабугада исә мондый хәлнең булуы мөмкин түгел. Җирле дәүләт тарих-архитектура һәм сәнгать музей-тыюлыгы ел саен диярлек яңа мавыктыргыч маршрутлар уйлап таба, хәзер инде аларның саны дистәдән арткан. Бөтен нәрсә исәпкә алына: кунакларның яше, кызыксыну кырлары, финанс мөмкинлекләре... Һәм килгән туристларның кайберләре рәхәтләнеп Алабуганың борынгы урамнарында йөрсә, икенчеләре Шишкин картиналары янында һәм Марина Цветаева музей-йортында озаклап хозурлана, өченчеләре исә шул арада күрше Чаллыдагы дельфинарийга барып кайтырга өлгерә. Җаның ни тели – тәкъдимнәр бик күп, хәтта яшьләр өчен шәһәр буйлап махсус квест-тур да бар.

Дөресен әйткәндә, Россия туроператорлары ассоциациясенә керә торган музей-тыюлык шәһәргә туристларны җәлеп итү мәшәкатьләрен тулысынча диярлек үз өстенә алган да инде, хәтта сувенирлар белән тәэмин итүне дә ул кайгырта. Тыюлык структурасында туристлык-мәгълүмат үзәге дә эшли. Мондый «хакимиятне үзәкләштерү» Алабугага файдага гына.

Билгеле, Татарстанның Идел, Чулман яки Нократ елгалары ярында урнашкан башка шәһәрләре мөмкинлекләрен уңышлы Алабуга белән чагыштыру дөрес тә түгел. Ни әйтсәң дә, Шишкин ватанында 180нән артык тарих һәм мәдәният һәйкәле бар бит. Сәүдәгәрләр шәһәренең борынгы үзгендәге сугыш һәм революция елларын кичергән урам һәм йортлар әйбәтләп реставрацияләнгән, биредә уңайлы кафелар, яхшы кунакханәләр дә бар. Шул ук Тәтеш, мәсәлән, бу турыда әле хыяллана да алмый. Икенче яктан караганда, һәр районның үзенең «фишкалары» бар. Шунлыктан алабу-


Тәтешкә илне саклау максатында нигез салына. Каравыл манарасы (реконструкция).

Зөядәге Константин һәм Елена чиркәве.

Зөя утрау-шәһәре.

гальылар тәҗрибәсен, өлешчә генә булса да, һәркайда кулланып була торгандыр, мөгаен.

КОРАБЛЬ ГЕНӘ БУЛСЫН...

Татарстан буйлап елга круизлары пәйда булу – һичшиксез, бик шәп күренеш. Икенче яктан караганда, маршрутларның нәкъ менә республикада башлануы һәм тәгәлләнүе бер дә мәҗбүри түгел. Иң мөһиме – безнең су юлларының мөмкин кадәр күбрәк туристларны җәлеп итүе. Кызганычка, бүген бу хуҗаларның кунакчыллыгына һәм аларның туристлык потенциалына гына бәйле нәрсә түгел.

Хәзергә кадәр Татарстан чикләрендәге Идел һәм Чулманда зур круиз лайнерлары туктый ала торган бер генә даими «яшел тукталыш» та юк. Мондый тукталышлар Ульяновск, Самара, Саратов, Әстерхан өлкәләрендә бар – бездә генә юк. Алар пәйда булсын өчен, дебаркадерлар, комлыклар һәм минималь сервис таләп ителә. Чыгымнар әллә ни зур түгел, әмма дивидендлар гарантияләнә. Безнең ике мәгълүм туристлык үзәгенең потенциалы, мәсәлән, алар янына дүрт палубалы теплоходлар туктый алмаганга гына тулысынча файдаланылмый.

Татарстан шәһәрләре буйлап популяр круизга бүген арзанлы ике палубалы теплоходта гына чыгып була, анда каюталарның яртысыннан артыгы – бернинди уңайлыкларсыз, ә сервис һәм ашатуны «кризис чорыныкы» дигән нейтраль сүз белән бәяләп була. Европа круизларында тәкъдим ителә торган швед өстәле һәм панорамалы тәрәзәле каюталар белән, билгеле, боларны чагыштырып та булмый. Теплоход кытлыгы кайчак абсурд хәлләр дә китереп чыгара: мәсәлән, Татарстан тирәли круизларның берсе 4 сәгатькә соңрак башланган, чөнки чираттагы халыкара форумда катнашучыларга тиз арада теплоход кирәккән...

Совет чорында моннан 30–60 ел элек төзелгән теплоходлар бүгенге Россия туристлык флотының нигезен тәшкил итә. Тик хәтта бу флот та – башка төбәктәге туроператорлар кулында. Бүген Татарстанда елга круизларын нибары бер җирле туроператор гына оештыра. Табигый ки, музыкага «заказ биргән» кеше инде маршрутларны да формалаштыра, бәяләр сәясәтен дә билгели, табышның да зуррак өлешен үзенә ала...

Татарстан туроператорларының үз теплоходлары булырмы? Шунысы ачык: теплоходларны төзетергә хәтта туристлык бизнесының башкаладагы «китларының» да хәленнән килми әле. РФ Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы залогка салырга тәкъдим иткән круиз суднолары 2,5 миллиард сумга төшәргә мөмкин.

– Бер генә хосусый компания дә мөстәкыйль рәвештә мондый проектка тотына алмый, – дип саный «Водоходъ» компаниясе генераль директоры урынбасары Андрей Смолин.

Һәрхәлдә, Татарстанда тагын бер генә заманча круиз корабле булса да, өченче башкала Идел буйлап турлар җибәрү урынына әйләнер иде, шул исәптән чит ил туристлары өчен дә – халыкара аэропорт барында бу хәл итәрлек мәсьәлә. Алай гына да түгел, мондый хәл бер тапкыр булган бит инде – 1987 елда Казан чит ил туристлары өчен ил буйлап круиз башлана торган Иделдәге бердәнбер шәһәргә әйләнгән. Нигә әле тагын шуны искә төшермәскә? Бөек елга буйлап сәяхәткә чыгарга теләүчеләр саны Сена һәм Ронаның кысан ярларында сәйран кылучылар санынан бер дә ким булмаска тиеш.

Сергей Иванов, ТРның Туристлык буенча дәүләт комитеты рәисе:

– Хосусый бизнеска яңа суднолар төзүгә акча кертү файдасыз, алар кыйбат һәм 25 елда да үзен акламаячак. Әгәр РФ дә чит ил судноларына эшләргә рөхсәт бирсәң, керем аларның хуҗаларына китеп барачак. Яңа суднолар төзүне финанслауга булышу буенча дәүләт дәрәҗәсендә программа кабул итү зарур. Быел РФ Президенты катнашында Дәүләт Советы утырышын үткәрү планлаштырыла, Россия елгаларындагы транспорт, шул исәптән елга круизларын үстерү мәсьәләләре тикшерeләчәк. Без нәтиҗәдә кирәкле механизмнар табылыр, конкрет программа эшләнер, дип өметләнәбез. Татарстанда Президент Рөстәм Миңнеханов хуплавында круиз туризмын үстерү өчен шактый эш эшләнә. Быелдан, мәсәлән, Болгар бөтен типтагы, шул исәптән дүрт палубалы, теплоходларны кабул итә ала. Киләсе елда алар Зөягә дә керә алачак. Минемчә, Кама Тамагы да тиздән круиз судноларын кабул итәчәк – моның өчен бөтен шартлар да бар.

PRESSA.RU

Автор:
Линар Закиров

Фото: Ната Смирнова.

КЕЧЕ ВАТАН ПАТРИОТЛАРЫ БЕЛӘН – ҖИЛКӘННӘРДӘ

ТАТАРСТАН БУЙЛАП
йөзәсең –

«ТАТАРСТАН»ны
укы!

Татарстанның су киңлекләре йөзәргә һәм кояшта кызынырга яратучыларны гына үзенә ымсындырып тормый. Менә музей хезмәткәрләре дә, спортчылар белән берләшеп, чын осталарча су өстенә чыкты.

ТР Милли музее җилкәнле регатаны үз итте. Хәер, бу хәл 2014 елда ук башланган иде инде – ул вакытта беренче тапкыр Иделне аркылы чыктылар. 2015 елда музейларның җилкәнле ярышларын су спорт төрләре буенча дөнья чемпионаты аркасында кичектереп торганнар: Казан тирәсендәге су киңлекләрен ярышларга килгән төрледән-төрле спорт көймәләре һәм башка төр көймәләр иңли иде. Һәм менә, ниһаять, быел «Локомотив» яхта-клубыннан төрле зурлыктагы 35 көймә старт алды. Онытылмаслык тәэсирләр калдыра торган тамаша!

Фото: Ната Смирнова, Луиза Шарова

НӘФИС ЗАТЛАР ЭКИПАЖЫ КОМАНДУЮЩИЕ

– Койрыкларны җыярга! – дип команда бирә музей регатасындагы берләнбер хатын-кыз экипажы капитаны Мәдинә Исламгәрәева. Ул үзе Яшел Үзәннән, тренер булып эшли, балалар спорт һәм су туризмы, шулай ук ишкәкле слалом серләренә өйрәтә. Аның командасында дүрт кеше.

Өч ел буена яхта капиталь ремонтта булган, шуңа да кызлар коры җирдә яшәү рәвеше алып барганнар. Ә хәзер реабилитация узган көймә горур төстә «Чара» исемен йөртә. Әмма һәвәскәр спортчы кызлар, су киңлекләрен хатын-кызларга хас нәфислек белән түгел, ә физик әзерлек һәм чыдамлылык белән буйсындыра.

– Техниканы да, кагыйдәләрне дә белергә кирәк. Хатын-кызлар коллективындагы атмосфера яхшы булмый, диләр. Юк сүз! Безнең арада менә дигән мөнәсәбәтләр. Яшермим, без, капитаннар, еш кына кырыс булабыз. Бу җилкәбезгә төшкән җаваплылык аркасында гына: яхта, ярышлар һәм экипаж өчен борчылудан. Шуңа да экипаждагы һәркемгә сабыррак булырга туры килә, – дип көлә капитан.

Яхта да, машина кебек үк, үзенә зур игътибар һәм күп акча сорый булып чыкты.

– Бөтен акча шуңа китә, баштагы уйлар да аның хакында. Кибеткә барып, үзеңә нәрсәдер алыйм, дисәң, шунда ук яхта искә төшә. Борыласың да китәсең. Көймәнең һәр детале өчәр мең сум тирәсе тора. Яхтаны яхшы хәлдә тоту өчен запас частьләрнең заводта җитештерелгәнен алырга кирәк, – дип аңлата Мәдинә.

ҖИЛКӘННӘРГӘ ГАШЫЙК ЗАТ

Казанда яшәүче Игорь Зоткин җилкәннәргә 30 ел элек гашыйк була. Чөнки ул монда романтика да, экстрим да, үз мөмкинлекләреңне сынап карау өчен форсат та таба. Музей регатасы спортчыларны мәдәнияткә якынайта, дип ышандыра ул.

– Без үзебезне теләсә кайсы һава шартларына күнектерә алабыз. Бары тик вазгыятькә карап эш йөртергә кирәк. Мәсәлән, җилкәннәрне үз вакытында алыштырырга, култыкка керергә, җил-давылда җилкәннәрне төшереп, дрейфта ятарга кирәк, – дип уртаклаша үз эшенең нечкәлекләре белән Игорь Зоткин.

– Ә мин шкот ролендә булачакмын, – ди Анна Афтаева, кечкенә көймәдә яр буеннан этәрелеп.

– Һәм нәрсә белән шөгыльләнәчәксез? – дип кызыксынабыз аннан, бу сүзнең мәгънәсен аңламавыбыз турында әйтергә оялып.

– Менә бүген белим инде. Бер ел элек йөргән егетем яхта сатып алды, – дип елмая кыз. – Регатада беренче тапкыр катнашам, шулай да бары тик җиңүгә генә өметләнәм.

ҖИҢҮГӘ ӨМЕТ ИТҮЧЕ

ҖИЛКӘННӘРНЕ ҖИЛДӘ СЫНАУЧЫЛАР

Финанслар темасына сөйләшүне без Ринат Әгъләмов белән дәвам иттерәбез, аның хатыны һәм ике баласы старт алдыннан колбасалы бутербродлар белән тамак ялгап алдылар. Әгъләмовлар беренче тапкыр гаилә экипажы белән йөзәргә чыга.

Ринатка хәзерге вакытта 48 яшь, ул күп төрле ярыш төрләре – әйтик, йөгерү, йөзү, атыш, ишкәк ишү һәм җилкәнле көймәдә узышларны берләштергән диңгез спорты белән шөгыльләнә. 35 ел эчендә әңгәмәдешебезнең бер тапкыр да спортның бу төреннән күңеле кайтканы булмаган.

Дүрт ел элек Ринат ярты миллион сумга җилкәнле катамаран сатып алган. Аны 15 ел элек Казан осталары үз куллары белән җыйган булган.

– Минем өчен бу сумма мөмкин түгел кебек иде, гаиләдә башта аңламадылар, аерылыша яздык, – дип елмая Ринат, хатынына күз төшергәләп. – Шаяртам, әлбәттә. Шулай да акча күп китә. Ике ел элек көймәнең өске ягын буяу өчен генә дә 100 мең сум кирәк булды. Әлбәттә, арзанлырак көймәләр дә бар – 20 мең сумга һава өрдереп кабарта торган катамараннар – аларны сүтеп, җыеп һәм гаражга куеп була. Җилкәнле спорт белән шөгыльләнүчеләрне мин «авырулар» дип атыйм. Әйе, без «авыру»... – дип таный гаилә экипажы капитаны.

Яхталар бик күп төрле була икән: озынча, швертоботлар, һава өрдереп кабарта торган җилкәнле катамараннар, тримараннар һ.б. Музей регатасында һәвәскәр спортчыларның күпчелеге кулдан җыелган көймәләрдә катнаша.

Ринат безгә көймәсе буенча тиз генә экскурсия үткәреп алды. Без аның махсус өлешенә төштек – анда команда әгъзалары яңгырдан кача, ял итә ала. Аш бүлмәсе бар, анда капкаларга берәр ризык әзерләп алып була. Моның өчен кечкенә газ плитәсен кулланалар, ул бәләкәй генә сандыкта йөртелә.

«Татарстан» хәбәрчеләре үзләре булган һәр авылда, истәлеккә дип, герой портреты төшерелгән журнал тышлыгы калдыралар.

ГАДЕЛЛЕКНЕ ТОРГЫЗУЧЫ

Милли музей генераль директоры Гөлчәчәк Нәҗипова регатаның максатын аңлатып болай ди: «Казан – Иделнең тарихи үзәге. Идел буе Болгар дәүләте чорында да, Казан ханлыгы вакытында да ул Идел һәм Кама буендагы сәүдә үзәкләренең берсе булган. Вакытлар узу белән, «тарихи үзәк» дигән исем бездән киткән, һәм хәзер бу гаделсезлекне юкка чыгару өчен иң кулай вакыт. Шулай ук Татарстан башкаласына борынгы көймә һәм кораблар төзелешен җайга салырга да кирәк.

– Бишбалта бистәсендә Бишбалта верфе торгызылачак. Без быел аның концепциясен эшләдек, һәм аның бер юнәлеше – XVIII гасырдагы Петров верфенда эшләнгән көймәләрне реконструкцияләү. Без инде әлеге верфьта төзелгән корабның исемен һәм кайсы сугышларда катнашуын беләбез. Бистә территориясендә музей төзелергә, парк булдырырга тиеш, без бик күп тарихи документларны өйрәндек һәм экспонатларны кайдан эзләргә кирәген беләбез. Музей төзелеше – бик кыйммәтле проект. Төзекләндерү өчен күп акча сорала, аерым алганда, ул урында Иделне тирәнәйтү өчен. Хәзерге вакытта әлеге проектка алынырга әзер булган эре инвесторларны эзлиләр, – дип сөйләде ТР Милли музее генераль директоры. Музей регатасы Татарстанда сулыкларны саклау елына багышлана. Җәмәгатьчелек игътибарын Идел-елганың экологик проблемаларына юнәлтү бик кирәкле эш.

РЕГАТАНЫ КҮЗӘТҮЧЕЛӘР

Спортчыларның елга киңлекләрен иңләп йөрүен туристлар Югары Ослан районы Печище авылы тирәсеннән күзәтте. Соңрак алар белорус халык шагыйре Янка Купала музеена юл алдылар. Ул Печищеда 1941 елның 13 ноябреннән 1942 елның 18 июненә кадәр эвакуациядә яшәгән икән. «Татарстан» журналыннан «Кече ватан патриотлары» дип аталган агарту хәрәкәтендә катнашучылар музей кунакларына иярде.

Ә регатада катнашучылар ТР Милли музеен гына күрә алды, Печищедагы музейга кагылып булмады, анда без туктарлыкдай пристань юк иде.

– «Музей регатасы» – пилот проект, үзенә күрә разведка. Без матур урыннар, манзаралар ачыла торган урыннарны карап, сайлап йөрибез. Елгаларда мондый ярышлар уздыру кыен, елга җиле минут саен юнәлешен үзгәртеп тора, алдан белеп булмый, – дип шәрехли Гөлчәчәк Нәҗипова.

БОРЫНГЫ ӘЙБЕРЛӘР БЕЛӘН МАВЫГУЧЫ

Ләйсән Мотыйгуллина:

– Мин борынгы әйберләр белән бик кызыксынам. Мисал өчен, Балык Бистәсенең туган якны өйрәнү музеенда сугыш чорыннан калган әйберләр, фронтовикларның шәхси әйберләре саклана. Танылган якташларыбызга багышланган бүлек бар: Камал театры артистлары – Равил Шәрәфиевкә, Хәлим Җәләловка, Рауза Хәйретдиновага, шагыйрьләр – Равил Фәйзуллинга, Роберт Әхмәтҗановка һәм башкаларга.

Безнең якта балык тоту белән шөгыльләнәләр, районның исеме үк бу турыда сөйли. Кызганычка каршы, соңгы елларда балык тоту сизелерлек кимеде. Ә бит безнең сулыклардан тоткан чөгә балыгын патша өстәленә дә биргәннәр, дип сөйлиләр!

Фото: Ната Смирнова, Луиза Шарова

ӨЧ ТЕЛДӘ СӘЛАМ БИРҮЧЕ

Янка Купала музее директоры Римма Абызова «Кече ватан патриотлары»н өч телдә сәламләп каршы алды: русча, татарча һәм... белорусча.

– Римма Юрьевна, ихлас әйтәм, сезнең музей турында беренче ишетәм. Ни өчен сез аны таныту белән шөгыльләнмисез?

– Сезнең белән килешмәскә рөхсәт итегез. Шушы көннәрдә генә әле Самарадан Казанга килгән туристлар интернетта безнең музей турында укып, кереп чыгарга уйлаганнар. Җәй көне мәктәп укучылары килә. Ноябрьдән алып апрельгә кадәр азрак килаләр, ә менә навигация ачылуга безгә күпләп йөри башлыйлар.

Без башка музейларның күргәзмәләрен оештырабыз. Февральдә Муса Җәлилнең 110 еллыгына багышланган экспозицияне чакырдык, һәм районның барлык мәктәпләреннән график буенча килеп, бездә каһарман-шагыйрь турында тематик дәресләр алдылар, – дип сөйли директор үзенә тапшырылган музейның кайнап торган тормышы турыда.

Белорус шагыйренең чын исеме – Иван Доминикович Луцевич. Ул бөтен бәйрәмнәр арасыннан Иван Купала көнен яраткан, шуңа да әдәби тәхәллүс сайлаганда, ул озак уйлап тормаган.

Музей хезмәткәрләре, 2006 елдан башлап, шагыйрьнең яраткан бәйрәмен билгеләп үтә. Музейны күрергә килүчеләр саны елдан-ел арта, туристлар да тартыла башлаган. Иске стиль буенча Иван Купала көне 7 июльгә туры килә, ә Иван Луцевич нәкъ менә 1882 елда, 7 июль төнендә туган.

Римма Абызова 2005 елда Казанның 1000 еллыгын бәйрәм итү кысаларында үткән БДБ илләре җитәкчеләре саммитында республикада яшәгән һәр милли оешма үзенең көнкүрешен күрсәтте, дип искә төшерә. Чакырылучылар арасында Белоруссия президенты Александр Лукашенко да булган. Аңа Татарстанда яшәүче белоруслар тормышы турында сөйләгәннәр, Купала музее экспозициясен күрсәткәннәр. Лукашенко экскурсияне бәяләп, бу музей гына түгел, ә белорус мәдәниятенең бер почмагы, дип киткән.

МУЗЕЙЛАР ЯРАТУЧЫ

Эльвира Закирова:

– Без Балык Бистәсеннән 12 кеше килдек. Мин музейларда йөрергә яратам, узган ел Күлбай Мораса авылында Габдулла Кариев музеен карадык.

Балык Бистәсендә туган якны өйрәнү музее бар. Аның директоры – иҗади кеше, борынгылыкны заманчалык белән куша белә. Минем биш яшьлек кызымны балалар бакчасыннан музейга алып бардылар. Балалар да музейда күргәннәре белән тәэсирләнгәннәр, аларга бик ошаган. Ә регатаны минем беренче күрүем, хәйран матур тамаша икән.

ВАТАНПӘРВӘРЛӘРЧӘ ФИКЕР ЙӨРТҮЧЕ

Линар Закиров:

– Оятыма каршы, мин Янка Купала кебек танылган белорус шагыйренең Татарстанда яшәгәнен белми идем. Бөек кешеләр турында белмиләр, оныталар – бу дөрес түгел... Үткәнне белми торып, киләчәкне төзеп булмый бит. Мин, «Татарстан» журналының «Кече ватан патриотлары» хәрәкәтенә кушылып, шундый билгеле һәм матур урыннарда булуыма, яңа белемнәр алуыма шатмын. Дөрес юлдан барабыз һәм проектны тормышка ашыру вакытында күп кенә бөек кешеләрне – Татарстанда яшәп, иҗат иткән язучыларны, шагыйрьләрне, драматургларны, композиторларны искә төшерербез, дип уйлыйм.

БРЕНДЛЫ ИПИ ПЕШЕРҮЧЕЛӘР

Музей Печище икмәк ризыклары комбинатының бер бинасында урнашкан. Музей директоры раславынча, биредәге он үзенчәлекле, "тегә" вакыттагы технология буенча җитештерелә. Аны Чебоксар, Түбән Новгород, Владимирдан ук килеп алалар икән. Печище онынан Югары Ослан районының Введенский бистәсендә ипи пешерәләр. Ә ул ипи үзен күптән инде бренд булырак таныткан.

– Римма Юрьевна, – дип кызыксынабыз ахырдан, – спорт белән мәдәниятне болай берләштерүгә ничек карыйсыз?

– Шушы көнгә кадәр җилкәннәргә карап соклана гына идек. Ә хәзер инде аңлый, кызыксына, алар өчен борчыла башладым. Гади генә спорт төре түгел бит. Менә әле генә күк күкрәде, мин үзебез һәм туристларыбыз өчен түгел, ә спортчылар өчен борчылдым. Исән-сау булсыннар дип. Минем ирем Югары Осланда спорт комплексында җитәкче. Ул – спорт, мин мәдәният тапшыруларын карыйбыз. Шулай да, кайчак безнең кызыксыну кырларыбыз бер-берсенә якыная, бәхәсләшүгә кадәр барып җитәбез, – дип елмая ул.

P.S.
Төп бүләк – Казан мэры Кубогын һәм җилкәнле регатаның абсолют чемпионы исемен «Идел» яхтасы яулады.

Реклама
AYARIS
«Аярис» – "Кече ватан патриотлары" рубрикасының спонсоры
Адрес: Казан, Спартак ур., 2, корп. 1, оф. 238, тел.: 2-102-432
Видеобиографик, фильмнар төшерү, генеалогик тикшеренүләр үткәрү
«Аярис»: ата-бабаларыгызның киләчәк буыннар хәтерендә калырлык образларын тудырыгыз!
www.ayaris.ru

* Arbor vitae – нәсел агачы.
** AYARIS – АЯРИС.

PRESSA.RU

УКРАИНАДА ЯШӘҮЧЕ ТАТАР МИН!

Диләрә Шкурко, журналист, – дошманлык һәм үзара аңлаша алмаудан да көчлерәк нәрсәләр турында.

Аңлы гомеремнең яртысын мин Татарстанда үткәрдем. Икенче яртысын – Киевта. Шул 20 ел эчендә Украина минем икенче ватаныма әйләнде, әмма туган ягымны сагыну хисе дә кимемәде... Хәзергә кадәр минем өчен «өйгә кайту» «Лениногорскига» дигәнне аңлата. Үз алдыма чагыштыру һәм бәя бирү максатын куймасам да, туган ягыма кайткан саен мин барыбер ирексездән ике илнең охшаш һәм аермалы, тискәре һәм уңай якларын эзлим... Хәзер исә, Украина белән Россия арасындагы мөнәсәбәтләр суынган чакта, бу тагын да җитерәк күзгә ташлана.

«Йә чиктән чыгармаячаклар, йә бандеровчыга әйләндерәчәкләр», – дип куркыттылар мине дус-ишләремнең кайберләре. «Ник кирәк инде бу сиңа?! – дип аптырады икенчеләре. – Ул илгә кунакка бармасаң соң инде...» Әмма минем дус-танышларымның күпчелеге, бәхеткә, бодайны кибәктән аерырга сәләтле булып чыкты һәм мине туган ягыма тыныч күңел белән озатты, чәкчәк һәм казылык көтеп калды.

Туган якка юл бик кыен һәм озын булып чыкты. «Киев – Мәскәү» маршрутындагы фирма поездларының күпчелеге туктатылган – мин үтеп баручы Кишинев поездына гына билет таба алдым. Бу поезд түгел – вакыт машинасы иде... Аңа утыргач, совет тимер юлының бөтен «рәхәтлекләрен» искә төшердем – ватык тәрәзәләр, юеш, ертык җәймәләр, сабын исе килеп торган чәй... Ә бәдрәфтә исә нигәдер сабын юк иде. Әмма кызык: юлдагы уңайсызлыклар минем сәяхәтемнең

Әтием туган йорт. Мине бәби табу йортыннан алып кайткан йорт. Мәктәптә укыганда һәр җәемне үткәргән йорт...

Әнием (сулда) һәм аның пионервожатые – 60 ел үтмәгән дә кебек!

Фото Диләрә Шкурконың шәхси архивыннан

җирсү ноталарын бары тик көчәйтте генә…

Гадәт буенча, туган шәһәремә кайткан көннәрдә башта зиратка барам. Миңа «исәннәрнең кадерен бел, үлгәннәрнең каберен бел» дигән татар халык мәкале бик ошый. Әмма минем өчен татар зиратлары бакыйлыкка күчкәннәрне искә алу урыны гына түгел, бәлки культурологик экскурс та. Әти-әниемнең туган авылы Зәй-Каратайда каберләр тагын да борынгырак. Күп кабердән ташлар гына утырып калган – алардагы ашалып бетә язган язмалар гарәп телендә, даталар исә моннан ике гасыр элеккеге.

Ә тере тарих шул арада көянтәсен күтәреп чишмәгә бара, үрдәк ашата һәм крыжовниктан варенье кайната. Бу – әниемнең пионервожатые булган Халидә апа. Әнием сөйләвенчә, ул яшь чагында да хәзерге кебек җыр, уен-көлке яраткан. Халидә апаның сугыштан соң мәктәптә эшләү чоры хатирәләрен тыңлаганда, мин моңа тагын бер кат ышанам: өлкән буын, икмәк урынына алабута ашауга һәм бөтен гаиләгә бер генә пар аяк киеме булуга да карамастан, тормышка оптимистларча карашын саклап кала алган. Мин әниемнең балачак хатирәләреннән беркайчан да туймам, мөгаен. Мәсәлән, әтисенең сугыш азагында фронттан макарон тутырган посылка җибәрүе хакында. Ачлыктан интеккән гаилә исә аның нәрсә икәнен дә белмәгән… Сугыштан кайткач, бабам күп еллар буе Харьковтагы бакчачы полкташы белән хат язышкан, ул аңа хатка салып орлыклар җибәрә торган булган. Шуңа безнең яшелчә бакчасында ул вакытта күрелмәгән карбыз һәм кавыннар үскән.

Ә менә әтием ягыннан бабамнан өчпочмаклы хатлар гына калган… Аларын да укып булмый, чөнки гарәпчә язылганнар. Һәм минем икенче ватанымда, Җиңү көне ул – бәйрәм түгел, нибары хәтер көне генә дип ышандырырга маташканда, минем аларга сөйлисем – юк, кычкырасым! – килә: Фатыйх бабам, камалышта калып, үлем ядрәләре яңгыры астында окопта утырганда, хатынына, минем әбиемә, менә бу юлларны язган бит: «Әгәр мин җиңү көненә кадәр яши алмасам, аны, балаларыбыз белән бергә, минем өчен дә бәйрәм ит!» – дигән.

Быел мин ватаныма 9 Май тирәсендә кайттым. Лениногорскидагы Җиңү парадында катнашу, дулкынландыра, күзләрне яшьләндерә торган сугыш чоры җырларын ишетү, АНДА булганнарны күрү бәхетенә ирештем…

Әниемнең 18 яшеннән сугышта катнашкан өченче буын туганы бервакыт минем яныма Киевка килергә җыенган әниемә Украина башкаласын азат итүдә катнашкан Гариф Максудовтан шул җирләргә сәлам тапшыруын үтенгән. Без, татарлар, Украинада хәзер 70 меңнән артык. Мин татарлар һәм украиннар арасында туганлык хисләрен тоям. «Келәм» һәм «мәйдан» сүзләре украинча да, татарча да бер үк мәгънә белдерә. Безнең җырларыбызда да ниндидер уртаклык бар, алар күңелнең иң тирән кылларын тибрәтергә сәләтле… Минем исемем – татарча, фамилиям – украинча. Мин – татар украины һәм украин татары. Мин кем булырга да риза, тик безнең илләребез арасында тынычлык кына урнашсын иде.

Борынгы мөселман зиратында кабер ташы – Сәгыйдулла Әнвәр улы 1864 елның 27 мартында туган, 1905 елның 3 ноябрендә вафат булган…

80 ел элек бу чишмә янында үскән агачка минем ул чакта 20 яшьлек әбием көянтәсен элә торган булган. Бервакыт аны бабам сагалап торган һәм кияүгә чакырган. Әбием уйга калган… Бабам кулындагы пычагын агачка төбәп аткан һәм: «Син шул пычак сабы селкенүдән туктаганчы уйлый аласың», – дигән… Һәм әбиемә шул көнне үк яучы җибәргән.

PRESSA.RU

ТАТАРСТАНДА УКЫЙСЫҢ –
«ТАТАРСТАН»НЫ УКЫ

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА
ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАНДА ҖИҢӘСЕҢ –
«ТАТАРСТАН»НЫ УКЫ

ТАТАРСТАНДА ЭШЛИСЕҢ –
«ТАТАРСТАН»НЫ УКЫ

ТАТАРСТАНДА ЯШИСЕҢ –
«ТАТАРСТАН»НЫ УКЫ

WWW.PROTATARSTAN.RU

РЕСПУБЛИКАНЫҢ МИЛЛИ МУЗЕЕ ТӘКЪДИМ ИТӘ

Татарстан Республикасы Милли музее – безнең күпмилләтле республикабызның иң төп музейларыннан берсе. Аның фондлары дөньяви, Россия һәм Татарстанның матди һәм рухи мәдәниятенең 950 меңнән артык һәйкәлен үз эченә ала. Бары тик әлеге музейда гына бөтен Татарстанның тарихы һәм мәдәнияте турында иң тулы мәгълүматны алырга мөмкин.

Туристлар өчен махсус рәвештә төрледән-төрле экскурсияләр һәм мәдәни-күңел ачу программалары эшләнгән, аларның иң популярлары – «Тере экспозиция» дип аталган театральләштерелгән костюмлы интерактив экскурсия, «Сабантуй» бәйрәм-уены, квест-уеннар.

МУЗЕЙНЫҢ УНИКАЛЬ АКЦИЯЛӘРЕ:

МАЙДА «Музейлар төне»

ИЮНЬДӘ «Музей регатасы»

ИЮНЬДӘ Реконструктор клубларының «Көнчыгыш – Көнбатыш: Россиянең Ватан сугышлары» фестивале

ДЕКАБРЬДӘ «Музей базары» яңа ел бүләкләре ярминкәсе

МУЗЕЙ МАРШРУТЛАРЫ:

- Казан һәм аның әйләнә-тирәсе буйлап музейларга, китап кибетләренә, галереяләргә, остаханәләргә һ.б. керә-керә оештырылган ял көне экскурсияләре.
- «Яр Чаллы – үсеш территориясе» (Автошәһәргә экскурсия КАМАЗга – танылган автомобиль заводына керүне күздә тота)

АВЫЛ МАРШРУТЛАРЫ:

- «Осталарның алтын куллары: татарларның халык һөнәрләре» (җитештерү объектларына һәм музейга кереп, Кукмара районына сәяхәт кылу)
- «Шагыйрь бишеге» (бөек татар шагыйре Г. Тукайның туган ягы Арча районына экскурсия)
- Красновидовода Алма спасы (Кама Тамагы районына экскурсия-бәйрәм)

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИЛЛИ МУЗЕЕНА ҺӘМ АНЫҢ ФИЛИАЛЛАРЫНА РӘХИМ ИТЕГЕЗ!

Татарстан Республикасы Милли музее
Казан, Кремль урамы, 2 йорт.
Экскурсияләргә: +7 (843) 292-89-24 телефоны буенча шалтыратып заказ бирергә мөмкин
www.tatmuseum.ru

Г. Тукайның әдәби музее
Казан, Г. Тукай урамы, 74 йорт
+7 (843) 293-17-66
www.g-tukay.tatmuseum.ru

А.М. Горькийның әдәби-мемориаль музее
Казан, М. Горький урамы, 10 йорт
+7 (843) 238-47-78
www.gorkiy.tatmuseum.ru

Е. А. Боратынский музее
Казан, М. Горький урамы, 25/28 йорт
+7 (843) 236-13-22
www.boratynskiy.tatmuseum.ru

В. И. Ленин музей-йорты
Казан, Ульянов-Ленин урамы, 58 йорт
+7 (843) 236-90-12
www.lenin.tatmuseum.ru

М. Җәлил музей-фатиры
Казан, М. Горький урамы, 17 йорт, 28 фатир
+7 (843) 238-50-48
www.m-jalil.tatmuseum.ru

Каюм Насыйри музее
Казан, Париж Коммунасы урамы, 35 йорт
+7 (843) 292-76-94
www.nasiyri.tatmuseum.ru

Композитор Н.Г. Җиһанов музее
Казан, Кече Кызыл урамы, 14 йорт, 11 фатир
+7 (843) 236-12-84
www.jiganov.tatmuseum.ru

С. Сәйдәшев музее
Казан, М. Горький урамы, 13 йорт
+7 (843) 38-56-96
www.saydash.tatmuseum.ru

1941–1945 еллардагы Бөек Ватан сугышы музей-мемориалы
Казан, Кремль
+7 (843) 567-80-44
www.saydash.tatmuseum.ru

Ш. Камалның мемориаль фатирын үз эченә алган татар әдәбияты тарихы музее
Казан, Островский урамы, 15
+7 (843) 292-45-38

Янка Купала музее
Татарстан Республикасы, Югары Ослан районы, Печище авылы
+7 (906) 112-44-82
www.kupala.tatmuseum.ru

Красновидово авылындагы А. М. Горький музее
Татарстан Республикасы, Кама Тамагы районы, Красновидово авылы, Горький урамы, 17 йорт
+7 (843) 773-07-12
www.krasn.tatmuseum.ru

Элемтә өчен мәгълүмат:
420111, Казан шәһәре, Кремль урамы, 2 йорт
Тел.: +7 (843) 292-45-77, 292-45-88, 292-85-84

Реклама. 6+

PRESSA.RU

Ш.Мәрҗани музее, Әтнә районы, Комыргуҗа авылы.

«Иске Казан» музее, Биектау районы, Камай авылы.

Молоствовлар утары, Тәтеш районы, Долгая Поляна авылы.

Мәктәп музее, Балык Бистәсе районы, Олы Салтан авылы.

ТАТАРСТАН МУЗЕЙЛАРЫ: ТУРИСТИК МӨМКИНЛЕКЛӘР

Татарстанның тарихи-мәдәни байлыгы аны музейлар республикасы ясады. Дәүләт һәм муниципаль музейлар һәм музей-тыюлыкларның бергә 130дан артык, шулай ук меңнәрчә бик бай ведомство һәм югары уку йортлары музейлары, шәхси галереяләр һәм күргәзмә заллары бар.

КЫЙММӘТЛЕ ЯДКӘРЛӘР

Музей экспозицияләрендә илебез тарихының бик борынгы заманнардан безнең көннәргә кадәр сакланып калган кыйммәтле ядкәрләре, тарих һәм мәдәният, көнбатыш һәм көнчыгыш мәдәниятләре һәйкәлләре, танылган галимнәр, мәдәният эшлеклеләре раритетлары, фән һәм техниканың төрле казанышлары куелган.

УНИКАЛЬ КОЛЛЕКЦИЯЛӘР

Республиканың һәр муниципаль районында үзенең уникаль коллекцияләре белән тарихны һәм туган якның үзенчәлеген күрсәтә торган туган якны өйрәнү музее ачылды. Республикада танылган тарих һәм мәдәният хезмәткәрләренә багышланган мемориаль экспозицияләр эшли, үзләренең картина галереялары һәм әдәби музейлары бар.

ФЕСТИВАЛЬЛӘР, САЛОННАР, ТАМАШАЛАР

Бирегә килүчеләр һәм кунаклар өчен экскурсияләр оештырыла, әдәби салоннар һәм музыкаль кунакханәләр эшли, традициягә кереп киткән фестивальләр һәм ярминкәләр, театральләштерелгән-маскарад костюмлы тамашалар, туй тантаналары һәм туган көннәр һ.б. уздырыла.

ЯЗ, ТӨН, ЯРМИНКӘ

Республиканың барлык музейлары да туристларны ел саен «Татарстанның музей язы» (21–26 апрель), «Музейда төн» (май), «Музей базары» (декабрь) ярминкәсе кебек музейара акцияләрдә көтә. Бу вакытта бирегә килүчеләр республиканың бөтен территориясендә музейларның бәйрәм фестивалендә катнаша алалар. Программада: классик һәм хәзерге заман музыкасы, рок һәм джаз концертлары, мавыктыргыч-белем бирүче квестлар, флешмоблар, мастер-класслар һ.б.

МӘГАРИФ ҺӘМ ТАРТЫЛУ ҮЗӘКЛӘРЕ

Республика музейлары – алар мәгариф һәм иҗтимагый тартылу үзәкләре. Биредә эш рухият, патриотизм һәм гуманизм традицияләрендә алып барыла.

Күпчелек музейлар янында кунакханәләр, төркемләп туклану урыннары бар, шунда ук туган якны өйрәнү өчен уникаль басма продукция һәм җирле сувенирларны сатып алырга мөмкин.


Г. Кариев музее, Нурлат районы, Күлбай Мораса авылы.

Я. Купала музее, Югары Ослан районы, Печище авылы.

Мәктәп музее, Тәтеш районы, Пролей-Каша авылы.

Мәктәп музее, Югары Ослан районы, Мәйдан авылы.

PRESSA.RU

ГАСЫРЛАР ҺӘМ МӘДӘНИЯТЛӘР ОЧРАШКАН УРЫНДА

Дамбадан күренгән Казан тирән күл төпләреннән күтәрелгәндәй тоела. Күз карашына борынгы Кремле белән ачылып, ул гаҗәеп бер күренеш тудыра.

А. Дюма

З.Р. Вәлиева,
«Казан Кремле» дәүләт тарих-архитектура һәм сәнгать музей-тыюлыгы директоры

– Казан Кремле – һәркем өчен үзенчәлекле урын... Үткән һәм бүгенгенең, моңлы азан тавышының һәм чаң чыңының, мәдәният һәм сәясәтнең очрашкан урыны. Кирмәннең чал диварлары Казан ханнарын да, Явыз Иван гаскәрләрен дә, Татарстан автономиясен төзүне дә хәтерли.

Кремль күпне күрде: аның диварлары янгыннарда янды, Пугачёв гаскәрләре чолганышына түзде – биредә тарих күз алдында язылды. Күпме тапкыр кояш чыкты һәм ничә мәртәбә баеды... Кремльгә никадәр тарихи шәхесләр килде микән?!. Россиянең барлык императорлары да диярлек төрле вакытларда Кремльдә булып китте, хәтта Николай II дә губернатор сараен төзүгә акча бүлеп бирде.

Вакыт Казан Кремле тылсымы белән идарә итә алмый: ул танылган сәяхәтче Александр Гумбольдтның исендә калган, аның белән галим Адам Олеарий, шагыйрьләр Василий Жуковский, Александр Пушкин, артистлар Алиса Фрейндлих, Орнелла Мути, Пласидо Доминго хозурланды. Ә танылган сәясәтчеләр белән очрашулардан соң Казан Кремле нинди хатирәләрне саклый?! Шәһәребезнең үзәгенә сәяхәт кылганнан соң, Владимир Путин: «Биредә аерым бер мәдәният һәм аерым бер тарих», – дип соклануын белдерде. Кремльнең үзенчәлеге – ике мәдәниятнең озак гасырларга сузылган үзара тәэсир итешүендә, үзара йогынты ясашуында: әкияти Көнчыгыш һәм таләпчән Европа бәйләнешендә. Һәм бу йөз еллыклар дәвамында Казан Кремле кунакларын сокландырып һәм гаҗәпләндереп торган. Безнең шәһәрне моннан гасыр ярым элек сәяхәт кылган француз язучысы Дюма: «Биредә чиркәү һәм мәчет янәшәдә урнашкан, һәм алар хач һәм ярымайның туганнарча дуслыгына, мөгаен, бары тик Казанда гына очратып була торган үрнәк булып торалардыр», – дип, юкка гына язып калдырмагандыр.

XX гасыр, Казан Кремле силуэтын танымаслык итеп үзгәртеп, аның тарихына үз төзәтмәләрен кертә. XXI гасыр башында, Казан Кремлен үзгәртеп, тарих тагын бер яңа әйләнеш ясады: музей-тыюлык төзү аны Россиянең төп мәдәни һәм туристик үзәкләренең берсенә, Татарстан Республикасында яшәүче халыкларның дустанә булулары символына әйләндерде.

Әйләнә-тирә мохитебез даими рәвештә үзгәреп торуга карамастан, йөз еллар дәвамында үзгәрешсез кала торган кыйммәтләр дә бар. Бәхәссез, мондый кыйммәтләрнең берсе – ул ата-бабаларыбызның Казан Кремленең ак диварларында чагылыш тапкан һәм сакланып калган тарихы, туган ягыбыз тарихы. Әмма вакыт туктамый, яңа буыннар туа, һәм алар үз кыйммәтләрен булдыра – безнең музей-тыюлык аларга әлеге җиңел булмаган эштә ярдәм итәргә һәрвакыт әзер һәм шат.

Казан Кремле көн саен үткәнне һәм бүгенгене ача һәм яңа тарихны яза – Спас манарасы капкалары аша керергә генә кирәк...



1636

Адам Олеарий,
немец галиме һәм сәяхәтче

1833

Александр Пушкин,
рус шагыйре

1858

Александр Дюма,
француз язучысы



2005

Владимир Путин,
Россия Федерациясе Президенты

КАЗАН КРЕМЛЕНДӘ БУЛГАН ТАНЫЛГАН КЕШЕЛӘР

Император Пётр I

Императрица Екатерина II



Емельян Пугачёв, 1773–1775 еллардагы Крестьян сугышы җитәкчесе

Император Павел I



Александр Гумбольдт, немец галиме-энциклопедияче

Император Николай I

Василий Жуковский, рус шагыйре

Тарас Шевченко, Украина шагыйре

Император Александр II

Хильми-паша, Госманлы империясенең бөек вәзире



Никита Хрущёв, КПСС ҮК беренче сәркатибе

Борис Ельцин, Россия Федерациясенең беренче Президенты



Мәскәү һәм бөтен Русия патриархы Алексий II

Хиллари Клинтон, АКШның 67нче дәүләт сәркатибе

Алиса Фрейндлих, Россия актрисасы

Орнелла Мути, Италия киноактрисасы

Карен Шахназаров, Россия кинорежиссёры

Пласидо Доминго, Испаниянең опера җырчысы

PRESSA.RU

ТАТАРСТАН

«Татарстан» журналына язылу барлык элемтә бүлекләрендә кабул ителә

Индекс **П 2381** – татар телендә: алты айга язылу бәясе **892 сум 32 тиен**
Индекс **П 2378** – рус телендә: алты айга язылу бәясе **892 сум 32 тиен**

Ф.СП-1

Почта России

АБОНЕМЕНТ на ~~газету~~ журнал — П 2381 (индекс издания)

Татарстан (наименование издания) — количество комплектов:

на 2016 год по месяцам:

1	2	3	4	5	6	7	8	9	10	11	12
						✓	✓	✓	✓	✓	✓

Куда ____ (почтовый индекс) ____ (адрес)

Кому ____ (фамилия, имя, отчество)

ДОСТАВОЧНАЯ КАРТОЧКА

ПВ	место	литер

на ~~газету~~ журнал — П 2381 (индекс издания)

Татарстан (наименование издания)

Стоимость	подписки	892 руб. 32 коп.	количество комплектов:
	переадресовки	___ руб. ___ коп.	

на 2016 год по месяцам:

1	2	3	4	5	6	7	8	9	10	11	12
						✓	✓	✓	✓	✓	✓

Куда ____ (почтовый индекс) ____ (адрес)

Кому ____ (фамилия, имя, отчество)

Шулай ук электрон почта аша да язылырга мөмкин:
milyaushanb@tatmedia.com
Дистрибуция бүлеге хезмәткәрләре, шалтыратып, кызыксындырган сорауларыгызга җавап бирерләр.

Яки түбәндәге телефон буенча тарату бүлеге җитәкчесе Миләүшә Байрашевага үзегез шалтырата аласыз: **тел. +7 (843) 222 09 79**

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

БУ САНДА ТӘКЪДИМ ИТӘБЕЗ:

Тамашачылар күңелен **КЕМ** җилкендерә

Хан төрбәсендә **КАЙСЫ** хан күмелгән

«Җәйге» китаплар **НИНДИ** була

Шуран өрәкләре **КАЙДА** йөри

PRESSA.RU



ХАННАР ТӨРБӘСЕ ЯЗМЫШЫ

Автор:
Фаяз Хужин

1977 елның җәендә профессор Альфред Хәсәнович Халиков Казан Кремлендә Сөембикә манарасының көньяк-көнбатыш өлешендә казу эшләре алып барганда нииндидер борынгы таш корылма хәрабәләренә юлыга. Тикшеренүләр барышында археологлар әлеге корылманың Казан ханнары күмелгән төрбә булуын ачыклыйлар. Берничә кабер тулысынча казып чыгарыла. Табылдыклар, шул исәптән ханнарыбызның сөякләре бүгенге көндә «Казан Кремле» музей-тыюлыгында саклана.

Фотолар автордан алынды

Соңгы вакытта Казан ханнары күмелгән мавзолейга кагылышлы четерекле мәсьәләләр массакүләм мәгълүмат чараларында яңадан күтәрелә башлады. Бу төрбәләрдә чыннан да ханнар ятамы? Кайсы ханнар? Нишләп һаман да ул ханнарның җәсәде, элекке урыннарына күмелмичә, Кремльдәге археология фонды саклаулыгында тузан җыеп ята? Киләчәктә Кремль территориясендә казу эшләре планлаштырыламы? Сораулар күп, әлбәттә. Бу язмабызда шуларның кайберләренә җавап бирергә тырышырбыз.

Күптән түгел генә Татарстан Фәннәр академиясенең Археология институты галиме, антрополог Илгизәр Газимҗанов үзенең «Татарстан – Яңа гасыр» телевидениесе хәбәрчесе белән әңгәмәсендә «Халиков тапкан төрбәләрнең ханнарныкы икәнлеген исбатларга кирәк әле, мин үзем, мәсәлән, моңа шикләнәм», дигәнрәк фикер әйтте. Әлеге шикләрне бетерү өчен, имеш, яңа фәнни ысуллар кулланып, кыйммәткә төшә торган генетик тикшеренүләр үткәрергә кирәк. Сафсата! Биредә ханнар мавзолее булганлыгын исбатлау өчен элегрәк тупланган материаллар да җитәрлек.

Баштан ук бер мәсьәләгә ачыклык кертик. Безне кызыксындыра торган объект – борынгы таш корылма хәрабәләре – бик начар сакланган. Алар бит алдан планлаштырылган археологик казулар вакытында түгел, ә очраклы рәвештә, канализация торбалары өчен траншея казыганда экскаватор чүмече астыннан килеп чыга. Альфред Халиков бөтенләй диярлек җимерелеп беткән корылмаларның ханлык чорында тупланган культура катламында ятуларына игътибар итә. Әлеге корылмаларны чистартканда дүрт каберлек ачыла (алар шулай ук начар сакланганнар). Димәк, биредә ниндидер зират булган. Хан сарае һәм Хан мәчете белән янәшәдә генә нинди зират булырга мөмкин? Әлбәттә, ханнарныкы, бистә һөнәрчеләрен китереп күммәгәннәрдер бит инде?! Мәрхүмнәрнең сөякләре берсе эченә икенчесе кертеп куелган ике катлы агач табутларда ята. Табутларны яхшы сыйфатлы күн һәм ефәк материя белән тышлаганнар, көмеш кадаклар һәм фигуралы калайлар белән матур итеп бизәгәннәр. Алар төрбә идәне астына, тирәнлеге ике метрга җитәрлек итеп казылган каберләргә башларын кыйблага каратып урнаштырылганнар. Мәетне күмгәннән соң кабер өстенә ян-яклары баскычсыман менә торган кисек пирамида рәвешендәге таш корылма торгызылган. Төрбәләрнең идәнен чистартканда искиткеч матур бизәкле һәм язулы (кызганыч, аларны инде укырлык түгел иде) каберташ кисәкләре табылган.

Шулай итеп, таш төрбәләрдә күмелгән кешеләрнең Казан ханнары булуы 1977 елгы казу эшләре вакытында ук ачыклана. Ә инде безнең тарафтан 2004–2005 елларда үткәрелгән казулар әлеге нәтиҗәләрне тагын бер кат раслады һәм бераз төгәллек тә керттеләр. Мәсәлән, ханнарыбыз, Альфред Халиков уйлаганча, аерым төрбәләрдә (мавзолейларда) түгел, ә буе – 18, киңлеге 6 метрдан аз гына артык булган турыпочмак рәвешендәге бер бина эчендә урнашкан. Стенасының сакланып калган биеклеге бер метр чамасы. Шул мавзолей бинасы эчендә, рәт-рәт булып, ханнарның каберләре урнашкан. Аларның дүртесе (шул исәптән берсе XVIII гасырга караган балалар каберлеге), югарыда әйтелгәнчә, 1977 елда, өчесе 2004–2005 елларда казып өйрәнелде. Альфред Халиков тарафыннан ачылган каберләрдәге скелетларның бары тик икесе генә яхшы сакланган иде, һәм алар антропологлар тарафыннан җентекләп өйрәнелде. Без исә каберләрне бөтенләй ачмадык, урыннарын гына билгеләдек.

Сөякләре яхшы сакланган ике таш төрбәдә кайсы ханнар күмелгән соң? Берсендә Олуг Мөхәммәт яисә аның улы Мәхмүт, икенчесендә Сафагәрәй ята, дип фаразлаган иде Альфред Хәсәнович. Яңа фактлар белән расланамы алар?

Урыс елъязмаларында һәм фәндә билгеле башка тарихи чыганакларда Олуг Мөхәммәтнең Казанга килүе һәм аны сугышып алуы турында берниндәи мәгълүмат та юк. Ә менә Воскресение һәм Никон елъязмаларында, Олуг Мөхәммәтнең улы Мәхмүт 1445 елда Казанны алды, аның идарәчесе Либейны (Алимбәкне) үтереп, үзе патшалык итә башлады, дип ачыктан-ачык язылган. Казан әле 1438 елда ук Олуг Мөхәммәт кулына төшкәч, аны яңадан сугышып алу нигә кирәк булды икән? Дөресе шул: 1445 елда инде әллә кайчаннан бирле яшәп килүче Казан билегендә (кенәзлегендә) тәхеткә Алтын Урда ханнары, Җүчиләр нәселеннән чыккан идарәче килә. «Яңа» дәүләт, Казан ханлыгы, 1552 елга кадәр яши.

Шул вакыт аралыгында тәхеттә 13 хан утыра. Менә аларның исемлеге: 1) Мәхмүт (1445–1464 елларда идарә итә); 2) Хәлил (1464–1467); 3) Ибраһим (1467–1478); 4) Илһам (1478–1487); 5) Мөхәммәт Әмин (1487–1496, 1502–1518); 6) Мамук хан (1496); 7) Габделлатыйф (1497–1502); 8) Шаһгали (1519–1521, 1546, 1551–1552); 9) Сәхибгәрәй (1521–1524); 10) Сафагәрәй (1524–1531, 1535–1546, 1546–1549); 11) Җангали (1532–1535); 12) Үтәмешгәрәй (1549–1551); 13) Ядегәр (1552).

Ханнарыбызның барысы да Казанда җирләнмәгән. Менә андыйларның исемлеге:

Илһам (Ибраһим хан белән Фатыйма-Солтанның улы) тәхеттән 1487 елның 9 июлендә, Казанны бөек кенәз Иван III гаскәрләре басып алгач куыла. Аны әсирлеккә алалар, Вологдага сөргенгә озаталар, һәм ул актык гомерен шунда үткәрә.

Себер ханы *Мамук* Казанда ике-өч айлап кына була (Мөхәммәт Әминнән соң). Арча каласын талап башкалага кайткач, аңа берәү дә капка ачмый. Ул кире Себергә, үз йортына юнәлә һәм юлда үлеп кала.

Габделлатыйф (Ибраһим хан белән Нурсолтанның кече уллары), тәхеткә Иван III тарафыннан утыртылса да, мөстәкыйль сәясәт алып барырга омтылган һәм шуның аркасында Казаннан куылган. Ул Белоозерога озатыла, әмма соңгы көннәрен Каширада үткәрә. 1518 елның 19 ноябрендә вафат була (үтерелә).

PRESSA.RU

Сәхибгәрәй (Кырым ханы Миңлегәрәй белән Казан ханбикәсе Нурсолтанның улы) 1524 елда үз теләге белән Казан тәхетен калдырып китә. Озак еллар буе Кырымда хан булып тора һәм 1551 елда үтерелә.

Шаһгали Казанда өч тапкыр (җәмгысе өч елдан да кимрәк вакыт) хакимлек итә. Явыз Иван тарафдары буларак, 1552 елгы сугышта руслар ягыннан катнаша. Гомеренең соңгы 15 елын туган шәһәре Касыймда (Рязань өлкәсе) үткәрә. 1567 елның 20 апрелендә үлә. Шаһгали төрбәсе Касыйм шәһәрендә бүгенге көннәргә кадәр сакланып калган.

Үтәмешгәрәйне (Сафагәрәй хан белән Сөембикәнең улы) хан тәхетенә әтисе үтерелгәннән соң утырталар. Ул чакта әле аңа өч яшь тә тулмаган була. 1551 елда Үтәмешгәрәйне әнисе белән бергә әсирлеккә алалар һәм Мәскәүгә озаталар. 1553 елның 8 гыйнварында ул Александр исеме белән чукындырыла. 1566 елның 11 июнендә, 20 яшендә үлеп китә. Аның гәүдәсе Мәскәү кремленең Архангел соборына урнаштырыла һәм хәзер дә шунда саклана.

Ядегәр хан 1552 елның 2 октябрендә Явыз Иван сугышчылары тарафыннан әсир ителә һәм Мәскәүгә озатыла. 1553 елның 26 февралендә Симеон исеме белән чукындырыла. 1565 елның 26 августында вафат була һәм Чудов монастыреның Благовещение чиркәвендә күмелә (әлеге чиркәү бүгенге көннәргә кадәр сакланмаган).

Безнең алда, ниһаять, Казанда күмелгән ханнарыбызның исемлеге: Мәхмүт, Хәлил, Ибраһим, Мөхәммәт Әмин, Җангали һәм Сафагәрәй. 1977 елда табылган һәм антропологлар тарафыннан өйрәнелгән ике кабердә шуларның кайсысы ята?

Каберләрнең иң элгәрегесе, профессор Альфред Халиков фикеренчә, XV гасыр уртасына, икенчесе исә XVI гасырның беренче яртысына карый.

Баш һәм скелет сөякләрен төрле ысуллар белән тикшереп, антропологлар төрбәдә күмелгән ханнарның яшьләрен, буйларын, яшәү рәвешләрен, дөньялыкта нинди авырулар белән авырып, нинди авырудан үлгән булуларын ачыкладылар. Антропологларның әйтүе буенча, беренче төрбәдә күмелгән кешегә 30 (35)–40 яшь чамасы. Икенче төрбәдә күмелгәне өлкәнрәк, 50 яшьтән дә ким булмас. Йөзләренең антропологик типлары буенча икесе дә монголоидлар, яшьрәк чакта күчмә тормышта яшәгән булырга тиешләр, профессиональ сугышчылар, җайдаклар. Үзара бик якын туганлык мөнәсәбәтләрендә торганнар. Өлкәнрәк яшьтәгесе озак авырудан соң вафат булган. Остеохондроз, сөяк туберкулезы һәм тагын әллә нинди авыру билгеләре аның аяк сөякләрендә тирән эз калдырган.

Әлеге нәтиҗәләрне язма чыганакларда сакланып калган мәгълүматлар белән чагыштырып карыйк.

Альфред Халиков беренче төрбәдә йә Олуг Мөхәммәт хан, йә булмаса аның улы Мәхмүт күмелгән булуы мөмкин дип фаразлаган иде. Олуг Мөхәммәт түгелдер. Ни өчен дисәң, аның кайда үлгәнен һәм күмелгәнен тәгаен генә берәү дә әйтә алмый (һәрхәлдә, Казанда түгел). Аннан соң, безнең кулдагы мәгълүматларга караганда, Олуг Мөхәммәткә үлгәндә инде 50 яшьләр чамасы булган. Ә безнең беренче төрбәдәге ханга чама белән 35–40 яшь кенә.

Мәхмүт ханнан соң тәхетне яулаган аның улы Хәлилнеке дә түгелдер ул төрбә. Хәлил хан турында чыганакларда өзек-өзек хәбәрләр генә сакланган. 1460 нчы еллар башында (1462? 1464?) аны тәхеткә утырталар, 1467 елда инде ул үлә. Аның Мангыт ыруыннан булган Тимур-бәк кызы Нурсолтанга өйләнгән булуы билгеле. Нурсолтан, кайбер мәгълүматларга караганда, 1447 елда туган. Әгәр дә аны 15–16 яшьләрдә кияүгә биргән булсалар (ул чор өчен гадәти күренеш), бу 1460нчы елларның башы була, ягъни Хәлилнең хан тәхетенә утырган чоры. Әгәр дә Хәлилне 17–18 яшьләрендә өйләндергәннәр дип фаразласак, аның туган елы 1440 еллар башына туры килә. Димәк, Хәлил хан бик яшьли дөнья куйган булып чыга, аңа әле 30 да тулмаган була (яшьлегенә ишарәләп, кайбер чыганаклар аны «Хәлилек» дип атыйлар).

Ибраһим хан.

Мөхәммәт Әмин хан.

Мәхмүт ханның кече улы Ибраһим Казан тәхетендә 11 ел утыра. Ул 1478 (1479) елда вафат булган. Беренче төрбәнең төзелү вакыты элегрәк булган дип әйттек. Димәк, аның «хуҗасы» Ибраһим хан була алмый. Безгә, Альфред Халиков фикеренә бераз төгәллек кертеп, беренче кабердә Мәхмүт хан күмелгән булырга тиеш, дип нәтиҗә ясыйсы гына кала.

Алтын Урда ханнарының бер вәкиле буларак, Мәхмүт ханның Казанда хакимлек итә башлавы татар тарихында олы вакыйга булып тора. Казан ханлыгының тәмам оешып бетүе, халыкара мәйданда урын алуы, танылуы нәкъ менә аның исеме белән бәйләнгән.

Хәзер инде XVI йөзнең беренче яртысына караган кабернең кемнеке булуын ачыкларга тырышыйк.

Профессор Альфред Халиков, бу кабердә, һичшиксез, Казанның соңгы ханнарыннан берсе, 1549 елда вафат булган Сафагәрәй күмелгән, дип яза. Аның дәлилләре ышандырмый, чөнки икенче кабердә күмелгән хан 45–50 яшьләрдә үлгән. Антропологларның тикшеренү нәтиҗәләре буенча, скелет сөягендә күзәтелгән кайбер патологик билгеләр кешеләрдә 50 яшьтән соң гына барлыкка килә икән. Сафагәрәйгә исә үлгәндә әле 40 яшь тә тулмаган була.

Шулай итеп, икенче төрбәнең «хуҗасы» XVI гасырның беренче яртысында Казан дәүләте белән идарә иткән ике ханның берсе – йә Җангали, йә Мөхәммәт Әмин генә булырга мөмкин.

Касыйм ханы Шәйх-Әүлиярның улы, Шаһгалинең бертуган энесе Җангали 1516 елда туган һәм 16 яше тулар-тулмас борын Казан тәхетенә утыртылган. 17 яшендә нугай морзасы Йосыфның кызы Сөембикәгә өйләндерәләр. 1535 елның 25 сентябрендә үтерелә. Бу вакытта аңа әле 19 яшь кенә була.

Соравыбызга җавап табу өчен атаклы дәүләт эшлеклесе, әсәрләре халык арасында абруй казанган (һәм кайберләре безнең көннәргә кадәр килеп җиткән) күренекле шагыйрь һәм язучы Мөхәммәт Әмин хан шәхесенә генә мөрәҗәгать итәсе кала.

Тарихи чыганакларда күрсәтелгәнчә, 1478 елда, Ибраһим хан үлеменнән соң өлкән улы Илһамны тәхеткә утырткач, икенче улын, 10 яшьлек Мөхәммәт Әминне, әнисеннән аерып, көчләп Мәскәүгә озаталар. Ул анда олуг кенәз Иван III сараенда тәрбияләнә. 1487 елда, Казан каласы урыслар тарафыннан яулап алынганнан соң, тәхеткә нәкъ менә Мөхәммәт Әминне тәгаенлиләр. Урыс илендә тәрбияләнгән ич – сүз тыңлаучан булыр, дип уйлаганнардыр инде. Казанда Мәскәү протектораты урнаша, ягъни ханнарыбыз Русиядән буйсынып яшәргә мәҗбүр ителәләр. Чыннан да, 1487–1496 елларны эченә алган идарә итү чорында Мөхәммәт Әмин үзен дөрестән дә бик тәүфыйклы, урысларның чын дусты итеп күрсәтә. Әмма ләкин соңыннан, хан тәхетенә икенче тапкыр утыргач, ул Мәскәү контроленнән чыга, сәясәтен кискен үзгәртеп, мөстәкыйль идарә итү юлына баса. Күп еллар үткәч, Мөхәммәт Әминнең шушы «хыянәтен» искә алып, «Казан тарихы» авторы аның авыруын тискәрелеге өчен Аллаһ тарафыннан җибәрелгән гадел җәза дип бәяли. Мөхәммәт Әмин, чыннан да, озак һәм каты авырый. Урыс елъязмачылары аның авыруы турында 1516 елда ук хәбәр итәләр. Хан өч ел буе урын өстендә ята, аяклары, тәннәре сызлый, йөрерлек хәле дә булмый (антропологлар куйган диагноз: остеохондроз, сөяк туберкулезы, бизгәк авыруы һ.б.).



1518 елда 50 яшен тутырган Мөхәммәт Әмин фани дөнья белән хушлаша, мәңгелеккә китеп бара.

Күргәнегезчә, галимнәр Казан кирмәнендә күмелгән алты ханның икесенең генә исемнәрен атап күрсәтә алалар. Аларын да әлегә башлыча фараз рәвешендә генә. Кайчан да булса бу проблеманы йөз процент дөреслек белән чишеп булырмы? Бик шикле, чөнки ышанычлы чыганакларыбыз аз, ичмасам, кабер ташлары да сакланмаган бит. Безгә калса, бүген бу артык мөһим дә түгел. Ханнар зираты табылды – бусын шикләнмичә әйтергә була. Анда кемнәр күмелгәнен беләбез – исемнәре матур итеп эшләнгән таш стелага уеп язылган. Ә менә инде кырык елга якын изге сөякләрнең күмелмичә ятуы, безнеңчә, бер дә ярый торган эш түгел. Әмма күптән инде өлгереп җиткән әлеге мәсьәләне хәл итү археологларның вәкаләтенә керми. Бу турыда югарыдагы җитәкчеләрбезгә уйларга кирәк.

Фотолар автордан алынды

PRESSA.RU

«БЕРЕНЧЕ УРЫНДА – ЯҢГЫРАШ ҺӘМ КЕШЕЛЕКЛЕЛЕК»

Сезнең игътибар иткәнегез бармы икән, Казанга кайсы яктан гына килеп кермә, ерак-еректан сезне «Татар дәүләт филармониясе» дигән язу каршы ала. Берничә километр узасың, тагын шул ук язу! Мин элек гел аптырый идем: нигә шулай? Әйтерсең, Казанга һәркем филармония хакына гына килә. Тора-бара аңладым: чынлап та, үзен хөрмәт иткән һәр зыялы кеше гомерендә бер тапкыр булса да филармониягә аяк басып карарга тиеш. Һәм, һичшиксез, Анатолий Шутиков җитәкләгән Халык уен кораллары дәүләт оркестрын да тыңларга!

Автор:
Луиза Янсуар

Мин аны шундый гади кеше дип уйламый идем. Сәхнәдән караганда да бик зыялы, тыйнак, ягымлы күренә, әмма дирижерлар һәм җитәкчеләр, әйтүләренә караганда, еш кына диктатор була. Дөрес, ансамбльдә төп карарларны кабул итү һәм коллективның кыйбласын билгеләү – аның иркендә, һәм ул бу мәсьәләдә, күренеп тора, шактый җитди һәм таләпчән, әмма шулай да мин, оркестр белән аралаша башлауга, музыкантлар арасында хөкем сөргән җылы атмосфераны тоемлап алам. Әйтерсең, бер гаилә әгъзалары белән сөйләшәм. Иң беренче эш итеп, сүзне, әлбәттә, гаилә башлыгына – Анатолий Иванович Шутиковка бирәм.

«МИНЕМ ЛАБОРАТОРИЯМ»

– Ансамбльдә 65 кеше, аларның барысы да – Казан дәүләт консерваториясен тәмамлаган югары квалификацияле белгечләр. Күбесе – минем студентларым, аларны әле укыту процессында ук сайлыйм, тәрбиялим, аннары эшкә чакырып алам. «Бу минем лабораториям», – дип шаяртырга яратам. Әмма бу шаяртуда, үзегез күрәсез, дөреслек бар. Шулай ук оркестрның һәр музыканты – үзе бер дөнья. Күбесе – атказанган артистлар, чын педагоглар.

Ансамбльдәге инструментларның да һәрберсенең – үз тарихы. Алар арасында уникаль экземплярлар бар икән. Мәсәлән, раритет балалайкалар.

Анатолий Ивановичның кабинетына килеп кергәч тә, бер портрет күзгә ташлана: анда сурәтләнгән затлы ир-егетнең алдында – балалайка.

– Бу Василий Васильевич Андреев – илдәге беренче рус халык уен кораллары оркестрына нигез салучы, – дип сөйләп китә Анатолий Иванович. – Аңа кадәр халык уен коралларын зур сәхнәгә менгерү, аларны тулы канлы инструментка санау берәүнең дә башына килми. Андреев оркестрын исә Европаның һәм Американың иң шәп заллары алкышка күмә. Аның оркестрында ике уникаль баслы балалайка була. Шуларның берсен табып алдык, Мәскәүдәге оста аны реставрацияләде һәм ул хәзер – безнең оркестрда. Әлбәттә, мондый коралга зур акчалар китә, әмма филармония җитәкчелеге безнең үтенечләрне аңлый һәм канәгатьләндерә. Раритетлардан тагын берсен атамый үтә алмыйм, бу атаклы оста Зюзин ясаган йөзьеллык тарихы булган прима-балалайка. Татарстан Республикасының атказанган артисты Ольга Вайссбеккер уйный аңарда.

– Ә инструментларны ничә ел кулланып була, – дип сорыйм Анатолий Ивановичтан.

– Саклык белән кулланса, әллә ничә гасыр, – дип елмая ул. – Страдивари скрипкасы турында ишетә беләсез бит! Безнең уен кораллары да шулай, һәр музыкант үз коралы өчен җаваплы. Коралларның, раритет булмаса да, һәрберсе уникаль, күпчелеген Владимир осталары ясый.

– Ә үзебездә, Казанда ясамыйлармыни? – дип гаҗәпләнәм. – Шул ук баяннарны булса да?

– Элек Казанда бар иде гармун фабрикасы, гармуннарны, гармоникаларны Салих Батталович Шәйдуллин әзерли иде. Хәзер фабрика ябылды, уен коралларын читтән эшләтеп кайтартабыз. Сүз уңаеннан, Салих Батталовичның улы Рәшит Шәйдуллин аның традицияләрен дәвам итә, настройщик ул.

(Кызганычка каршы, мәкалә басмага әзерләнеп беткән көннәрдә Салих Батталовичның вафат булу хәбәре килде. – Л.Я.)

«КАЗАН – ПРОВИНЦИЯ ТҮГЕЛ!»

Көньяк Кореядагы Сеул шәһәрендәге концерт залы турында Анатолий Иванович үзе дә, оркестрдагы музыкантлар да сокланып, сагынып диярлек сөйлиләр. Беренчедән, уникаль яңгырашлы зал, диләр. Икенчедән, анда аларны бик җылы кабул итәләр. Хәер, Кореяда гына түгел, дөньяның кайсы гына почмагына барып чыксалар да – халык көйләреннән башлап, иң катлаулы классик әсәрләрне дә югары дәрәҗәдә башкара алучы мондый оркестрлар җир шарында бармак белән генә санарлык икән.

– Борынгы романс булсынмы, рус халык җырлары булсынмы, төрки аһәңнәрме, классика, джазмы – без барысын да билгеле күләмдә репертуарга кертергә тырышабыз, – ди Анатолий Иванович. – Халык уен кораллары оркестры дигәч тә, ул бары тик кашык шакып, думбра чиертеп утыра дигән сүз түгел. Оркестрның квалификациясе гаять дәрәҗәдә югары бүген. Мин моны курыкмыйча әйтә алам. Шуңа да безнең белән читтән килгән солистлар, корифейлар да бик теләп эшли.

– Ягъни Казанга килгәч, әллә кемләнеп, провинциягә килгәндәй тотмыйлар инде үзләрен, – дим.

– Юк, һич алай түгел, – ди Анатолий Иванович, – Казанның да, безнең филармониянең дә, оркестрның да дәрәҗәсе югары. Һәм шуны да әйтергә кирәк: безнең Казан публикасы шулай ук бик нәзакатьле, нәзберек дияр идем, бу мәркәзебезнең югары культурасын күрсәтә торган фактор.

Мин аларның уйнаганын берничә мәртәбә тыңлаганым бар – төрле жанрларны, төрле артистлар белән. Һәм, Анатолий Иванович белән сөйләшеп утырганда, кинәт бер нәрсәгә төшенәм – нигездә бит аларның

Фотолар: Татар дәүләт филармониясе архивыннан алынды

PRESSA.RU

нотолары да юк. Дөресрәге, халык уен кораллары өчен классик әсәрләрнең партитурасын махсус күчерергә кирәк. Ә бу үзе титаннарча хезмәт!

– Элек мин бу эш белән берүзем шөгыльләнә идем, – ди Анатолий Иванович, – хәзер шәкертләрем өлгереп җитте, контрабаста уйнаучы Михаил Шамаев белән баянчы Әнвәр Марин.

Оркестрдагы буыннар алмашы турында горурланып сөйли ул. Әгәр киләләр, ә бигрәк тә, еллар буена монда уйныйлар, калалар икән, димәк, гаиләбездә татулык бар дигән сүз...

– Алдагы сезонда безне нинди яңалыклар, сюрпризлар көтә соң? – дип сорыйм маэстродан.

Ул, әлбәттә, карталарның барысын да ачып салмый. Зур театр солисты

Фотолар: Татар дәүләт филармониясе архивыннан алынды

Михаил Казаков, Мәскәү оперетта театрының солистлары Максим Катырев белән Юлия Гончарова һәм тагын бик күпләр. Абонемент алып, сезон буена рәхәтләнеп тыңларга була аларны. Ә гастрольләргә чыгып киткән чакларында – сагынып көтеп алырга.

«ӨЙДӘ – ИКЕНЧЕ ДИРИЖЕР...»

– Оркестр ул – тере бер организм, – дип горурланып сөйли Анатолий Иванович. – Мин бик таләпчән тоеламдыр, бәлки, әмма коллективта һәркемнең үзен ничек хис итүе мөһим миңа. Профессиональлек, эшне җиренә җиткереп башкару, әлбәттә, беренче урында тора, әмма кешелеклелектән башка ул үзбәягә ия түгел. Һәркемнең ни белән яшәгәнен белеп торырга тырышам, туган көннәре белән котлыйм, без бергәләп табигатькә чыгабыз. Сезон тәмамлангач, Зөя ярына барып, бәйрәм итәбез, бу ел саен кабатлана торган бер традиция инде. Гастрольләргә гел бергә чыккач, минем тормышымның күп өлеше оркестр белән үтә. Ул – минем икенче гаиләм, дисәк тә буладыр.

– Ә беренче гаиләгез моңа ничек карый? Сезне оркестрга көнләмиләрме өйдә? – дип сорамый булдыра алмыйм.

Анатолий Иванович көлеп җибәрә.

– Юк, тормыш иптәшем педагог, кадетлар мәктәбендә эшли, ул мине бик яхшы аңлый. Оркестрның репертуарын үз акчама сатып алып, өйгә эш хакын алып кайтмаган чакларым да булды заманында, андый вакытта да гаиләдә хәлемә керделәр.

– Ә өйдә кайсыгыз дирижер? – дип сорыйм, җавапны инде алдан ук сизеп торып.

– Тормыш иптәшем! – ди Анатолий Иванович, һәм тәмләп, горурланып, гаиләсе, оныклары, бакчалары турында сөйләп китә.

Ә мин сокланып тыңлыйм: бары ярату булганда гына кешенең кулыннан барысы да килә, күрәсең – эштә дә, гаиләдә дә.

– Мин беркайчан да берсен икенчесенә каршы куймадым, йә аерып карамадым, – ди Анатолий Иванович. – Мин бик бәхетле кеше – эшемне дә, гаиләмне дә бертигез яратам.

ҮЗЛӘРЕ – МУЗЫКАНТ, ҮЗЛӘРЕ – МОРЖ

Корея дигәннән, оркестр музыкантлары Сеулдагы залны бер-берсен бүлдерә-бүлдерә мактадылар:

– Космик яңгыраш анда, андый залда эшләү – музыкант өчен зур бәхет...

Гастрольләр вакытында булган маҗаралары, күргән-белгәннәре белән дә бүлештеләр:

– Безнең үзебезнең моржларыбыз бар – алар ноябрь аенда океанда йөзделәр, – дип сөйләп китте контрабасчы Михаил Шамаев. Аңа башкалар да кушылды. – Көньяк Кореяда булды бу хәл, +10 градуслар тирәсе булгандыр. Янәшәдә генә Америка хәрбиләренең су асты көймәләре иде, алар курка калдылар, йөзеп киттеләр. Безнең ир-егетләр генә түгел, кызларыбыз да бик батыр. Без әле бу каһарманлыкны тагын Португалиядә кабатладык...

Ә балалайкалар төркеме концертмейстеры Ольга Вайссбеккерны кореялыларның имән чикләвеген ничек кулланулары таң калдырган:

– Бездә алар кабан дуңгызларыннан кала беркемгә дә кирәк түгел, ә анда шул чикләвекләрдән хәтта чәйгә тәм-томнар да әзерлиләр. Бөтен нәрсәне экономияле белә һәм файдалы итеп куллана торган ил, шуңа да алга киткән алар.

Маҗаралардан янә оркестр турында сөйләшүгә күчәбез. Бу юлы инде фикерләрне өземтә рәвешендә китерәм.

«МИН ИНДЕ БУ ОРКЕСТРНЫ САГЫНА БАШЛАДЫМ...»

Ольга Вайссбеккер, балалайкалар төркеме концертмейстеры:

– Әле Анатолий Иванович Шутиковны да белмим, оркестр үзе дә ул чакта «Чишмә» дип атала, эшчәнлеген башлап җибәргән генә еллары, анда, күп булса, 20 кеше булгандыр. Мин аларны беренче тапкыр телевизордан күреп гашыйк булдым. Дирижерга сокландым. Алларында ноталар да юк, ә музыкантлар белән дирижер арасында шундый табигый аңлашу, күз карашы аша ук бер-берләрен тоемлау бар, фантастика инде! Өч елдан соң үзем монда килеп эләктем. Һәм тышкы җиңеллек артында зур хезмәт торганлыгын аңладым. Әмма коллективтагы ихласлык һәм кешелекле мөнәсәбәтләр зәңгәр экран аша ничек сизелеп торса, чынлыкта да шулай. Тагын бер үзенчәлек – бездә тигезлек хөкем сөрә. Юкса барыбыз да аның студентлары, әмма ул һәрберебезне тулы канлы иҗатчы итеп күрә, ихтирам итә. Мин бу коллективта булуым өчен Аллаһка рәхмәтле!

Вениамин Булыгин, баяннар төркеме концертмейстеры:

– Күптән түгел генә Латин Америкасы музыкасын башкардык, килгән солистларның исләре китте, сез гомер буе шушы музыканы башкарган музыкантлар кебек уйныйсыз, диләр. Гәрчә безнең оркестр андый төр музыканы башкару өчен яраклашмаган булса да. Андагы ритмнар шактый катлаулы. Анатолий Иванович безнең алга шулай итеп катлаулы, әмма кызыклы, мавыктыргыч бурычлар куярга ярата, һәм ул шулай булырга тиеш тә, юкса музыкант үзе дә, коллектив та үсештә булудан туктый.

Михаил Шамаев, контрабасчылар төркеме концертмейстеры:

– Лариса Луста дигән актриса белән чыгыш ясаганыбыз хәтердә, ул күбрәк шансон жанрында эшли, эстрадага якын иҗаты. Концерт программасын башкарып чыкканнан соң, сәхнә артына чыккан да әйтә ди: «Мин инде бу оркестрны сагына башладым!» Безгә үзебезнең музыкантларның уллары, кызлары да килеп кушыла башлады хәзер. Ягъни, алмашка икенче буын музыкантлар – яшьләр килә. Оркестрда шундый гармонияле чор – инструментлар җитә, коллектив аңлашып эшли, рәхәтләнеп иҗат ит! Анатолий Иванович, кешенең мөмкинлекләренә карап, аңа үсәргә ярдәм итә – мин, мәсәлән, сценарийлар әзерлим...

Гүзәл Мөхәмәтдинова, Халык уен кораллары дәүләт оркестрының солисты һәм концертмейстеры:

– Ул һәрчак нәрсә уйнарга кирәклеген, нинди артистларны чакырырга кирәклеген белә, репертуарны төзегәндә, гел масштабны тоеп эш итә. Һәм, әлбәттә, яңгыраш бик мөһим аның өчен – оркестр һәрчак иң югары дәрәҗәдә чыгыш ясарга тиеш. Бу – кредо, бу – беренчел таләп.

P.S. Шулай булмаса, аны дөньяның иң шәп заллары аягүрә басып алкышламас иде. Татарстанның визит карточкалары арасында Анатолий Шутиков җитәкчелегендәге Халык уен кораллары дәүләт оркестры да бар, димәк. Ә без икеләтә бәхетле: гастрольгә яки кунакка килгәндә генә түгел, ә ел әйләнәсендә тыңлый алабыз бу гаҗәеп коллективны. Әлеге дә баягы филармониядә. Һәм анда гына да түгел.

PRESSA.RU

Кемгә ничектер, минем өчен җәйге ял яки отпуск дигән төшенчә, иң беренче чиратта, «китап» һәм «кино» сүзләренә тәңгәл. Ниһаять, иртән эшкә барасыңны уйламыйча, төннәрен йокламыйча, рәхәтләнеп бернечә кино карап чыгарга мөмкин дә, тәүлектә ничә сәгать барлыгын онытып, ашау-эчүдән калып, кызыклы китап укырга була! Ә диңгез? Ә ком? Ә пляж, диярсез. Ә бакча? Ә колорадо кортлары? Ә печән?! Болар барысы да, китап һәм кино белән бергә, «бар да каралган» комплексына сыеп бетә. Еракмы-якынмы сәяхәтләрдән кайтып керми торган таныш-белешләремнән дә җәйнең кыл уртасында китаплар турында сораштырырга булдым.

«КИТАП ҮЗЕ БЕР СӘЯХӘТ»

Язып алды:
Луиза Янсуар

1	2	3	4	5
Җәй көне китап укыйсыңмы?	Үзең белән юлга (отпускка, яки башка берәр сәяхәткә) нинди китаплар аласың?	Электрон вариантмы, кәгазь китапмы, аудиомы?	Сәяхәтләр вакытында китап кибетләренә керәсеңме, үзең белән алып кайткан китаплар буламы? Булса, ниндиләр?	Иң җәйге китаплар дип нинди китапларны исәплисең?

«КИТАПЛЫ ӨЙ – ҖАНЛЫ ӨЙ»

Эльмир Низамов, композитор:

1. Җәй көне китапларны күбрәк укырга тырышам, чөнки отпускта гына китапны бирелеп, тәмләп укып була.

2. Сәяхәттә булганда китаплар укымыйм, чөнки китап уку – ул үзе бер сәяхәт. Шуңа да китапларны тыныч кына өйдә утырган вакытларда укырга яратам.

3. Кәгазь! Бары тик кәгазь генә!

4. Әлбәттә! Мин гел китап кибетләрендә йөрим, елның кайсы фасылы булуга карамастан! Өйдә дә – гел китап. Китаплы өй – ул җанлы өй минем өчен. Киштәдә нинди китаплар булуына карап, өйнең хуҗалары турында да күп нәрсә белеп була.



5. Балачактан ук иң җәйге китап – Марк Твенның «Приключения Тома Сойера» әсәре.

«ЯШЕНЛЕ ЯҢГЫР, ВЕРАНДА ҺӘМ ЛОЛИТА»

Гөлназ Фәйзрахманова, «Болгар радиосы» алып баручысы:

1. Җәй көне китаплар сирәгрәк укыла шул. Максат итеп куйганыңның яртысы гына...

2. Һәрвакыт юлга китап алам. Сәяхәтнең кайда узасына, укыр өчен вакытның кайчан калачагына (төнме, көнме) карап, газета-журнал да алам. Мәсәлән, көндез поездда бирелеп, тәмам эченә кереп китеп китап укып булмый, журнал – әйбәт.

3. Кәгазь китап, әлбәттә! Яңа китаплар яратам, исен иснәп ләззәт алам. Газеталарны да тотып, алга җәеп, кыштырдатып, сузылып ятып укырга яратам.

4. Вакыт булганда, юлыма очраганда керәм. Алып кайткан китаплар да булды. Сеңлем белән Мәскәүгә баргач, Януш Вишневскийның ул вакытта бик популяр булган «Одиночество в сети» китабын алып кайтканым истә. Укый башладым да ташладым, башладым да ташладым мин аны поездда. Өйгә кайткач кына тынычлап укырга кирәк булган икән.



5. Владимир Набоковның «Лолита»сы. Җәй һәм яшенле яңгыр, авылдагы веранда белән күз алдына килеп баса ул. Чөнки авылда нәкъ менә шундый халәттә укылды, миңа ул вакытта 17-18 яшь тирәсе иде.

«ВАКЫТ ӘРӘМГӘ КИТМӘСЕН»

Илгиз Зәйниев, драматург, режиссер:

1. Китап уку минем өчен ел фасылына бәйле түгел, ул ел буе дәвам итә торган иң рәхәт шөгыль. Хәзерге вакытта Шекспирның пьесаларын кабаттан укыйм. Казан шәһәре турында танылган шәхесләрнең истәлекләре тупланган китапны. Карл Фуксны.

2. Янымда һәрчак китап йөртергә тырышам. Кызык бер кабатлану: берәр җиргә озакка киткәндә, һәрчак диярлек бер китап алам, «Антропология театра» дип атала ул. Бу юлы, ниһаять, укып чыгам, дип алам. Әмма һәр алган саен укылмыйча шул килеш әйләнеп кайта. Китап алмаган очракта ноутбукны алам, анда минем дөнья драматургиясеннән берничә мең пьессалык җыентык бар. Шуларны укыйм.

3. Аудиода күбрәк бизнес буенча китаплар тыңлыйм, һәртөрле тренинглар. Алары – машинада барганда вакыт әрәмгә китмәсен өчен.

4. Мәскәүгә, Питерга барсам, букинистика кибетләренә керергә яратам. Анда сирәк китаплар очрый. Төркиядән төрекчә пьесалар төяп кайттым, берәр кайчан, бәлки, төрек телен өйрәнә алырмын, дип.

5. Җәйге китап дигәч, ни өчендер Брэдбери телгә килә.



«КИТАПЛАР ИЯРЕП КАЙТА»

Алсу Әшрәпова, КФУ укытучысы:

1. Укырга тырышам, кимендә 2–3 китап укыйм. Соңгы арада юлда тыңлый башладым (гәрчә бу вариантны бик үк өнәп бетермәсәм дә).

2. Юлга классик әсәрләр алырга тырышам. Соңгы арада янә татар һәм инглиз әдипләренең иҗатына мөкиббән киттем.

3. Беренче урында – кәгазь китап, икенче урында – электрон вариант, өченче урында – аудиоформат.

4. Керәм! һәр сәяхәттән шул ил/шәһәр белән ассоциация тудырган, яки нәкъ менә шул сәяхәт алдыннан укырга хыялланып йөргән китаплар ияреп кайта. Күбесенчә, инглиз телендә. Араларында балалар өчен китаплар, классик әдипләрнең әсәрләре һәм үз эшемдә ярдәм итә торган китаплар да бар. Соңгы сәяхәтем Швециягә иде. Стокгольм шәһәрендә мәшһүр Карлсон шәһәрчегендә булуым Астрид Линдгренның китабын эзләргә сәбәпче булды.

5. Аерып кына җәйге китапларга бүлә алмам, мөгаен. Кеше һәр чорында үзенең күңеленә хуш килгән китапны үз итәдер. Шулай да һәр җәйдә укыла торган китаплар арасында Ә. Еники, А. Гыйләҗев, Г. Кутуй, Г. Әпсәләмов, З. Кадыйрова әсәрләре бар. Һәм минем өчен җәй ул, иң беренче чиратта, шигырь китаплары! Рус язучыларыннан: И. Тургенев, А. Чехов, Л. Толстой, В. Астафьев һәм инде ничәнче җәй яратып укый торган авторым Наринэ Абгарянның «Манюня» әсәре. Ел дәвамында Эдуард Асадовны бик яратып укыйм. Инглизләрдән: О. Генри, О. Уайльд, Ф.С. Фицджеральд, Г. Бичер-Стоу, М. Твен, Ш. Бронте, С. Ахерн.





«ДИҢГЕЗГӘ БИШ ТАПКЫР БАРДЫ»

Данил Сәфәров, журналист, «Матбугат ру» сайты җитәкчесе:

1. Мин бик күп һәм еш китап укучы түгел. Бигрәк тә җәй көне.

2. Гадәттә, юлга 3–4 китап алам. Әмма берсен дә укымыйм диярлек. Әйтик, Робин Шарманың бер китабы минем белән диңгезгә, ким дигәндә, биш тапкыр баргандыр. Аның битләреннән тоз коела инде. Ул китапны һаман укып бетерә алганым юк әле.

3. Электрон китапларны өнәмим. Кәгазь китап уку – электрон дөньядан ял итү ысулы ул. Аудиокитапны музыкаль бизәлешләр белән эшләнгән булса яратам. Әмма аудиокитапны бары тик машинада гына тыңлый алам. Анда да – трассада, шәһәр режимында 10–15 минутлы кисәкләргә бүлеп тыңлау – нормаль күренеш түгел.

4. Сәяхәттән китап алып кайтканым юк.

5. Җәйгә фәлсәфирәк китаплар бата. Мәсәлән, Э. Хемингуэйның «Старик и море» әсәре.

«СУМКАДА – ТУЛЫ БЕР КИТАПХАНӘ»

Ләйсән Дусаева, актриса, ТВ алып баручысы:

1. Китап мине ел әйләнәсе илһамландыра, рухландыра, тормышта ярдәм итә. Минә дигән киңәшче дә ул, дус, остаз да. Ә кайчак «иптәш кыз» да – була шундый китаплар, алар белән рәхәтләнеп чөкердәшеп утырасың, җаның ял итә.

2. Юлга психологик китаплар алырга яратам яки тормышчан романнар. Аларны укыганнан соң, таулар күчерерлек кодрәт иңәрлек булсын.

3. Электрон китаплар кәгазь китапны алыштырачак, дип фаразларга яраталар. Эш уңайлылыкта, билгеле, кечкенә генә сумкаңа тулы бер китапханәне сыйдырып була бит! Әмма шулай да кәгазь кыштырдавын берни алыштыра алмый... Мин шулай укырга яратам, әле тагын ошаган фразаларның астына да сызып куям... Ә аудиокитапларны үз итә алмыйм. Чөнки текстны укучы үзенең интонациясе, уку рәвеше белән тыңлаучыга мөнәсәбәтен дә тагып куя шикелле. Ә минем бары тик үземнең генә ачасым килә китаплардагы дөньяны...

4. Хәзер безнең үзебездә дә теләгән китабыңны сатып алырга була. Сәяхәтләрдә китап кибетләрендә йөрмим, ә үзебездә – йөрим. Кайчак сатып алыр өчен дә түгел, ә нинди яңа басмалар чыкканын барлар өчен. Барысын да сатып алмыйсың бит инде.

5. Кем дә булса укып өлгермәгән икән, Джоджо Мойес әсәрен укырга тәкъдим итәм – «До встречи с тобой» дип атала ул. Хәзер кинотеатрларда экранизациясе бара. Әмма, киносын караганчы, башта укыгыз! Аньес Мартен-Люганның «Счастливые люди читают книжки и пьют кофе» әсәре ошады тагын, бер сулышта укып чыктым. Шушы көннәрдә генә «Серебряный век. Женская лирика» китабын сатып алдым, җәемнең тагын бер бизәге ул булачак...

МАХСУС ПРОЕКТ

— 13нче чыгарылыш —

Татарстан юбилярлары

PRESSA.RU

ҖИҢҮЧЕ ПСИХОЛОГИЯСЕ

А. Н. Туполев исемендәге Казан милли-тикшеренү техник университеты – КАИ ректоры Альберт Гыйльметдинов – танылган галим дә, оста идарәче дә. Бу сыйфатлары аның һәр җитәкчелек эшендә чагылыш тапкан: физик лабораториядә дә, ТР Мәгариф һәм фән министрлыгында да, ул ректорлык иткән өч ел вакыт эчендә абруйлы эш һәм уку урынына әйләнгән КМТТУ-КАИда да.

Беренче югары белемен (алар аның өчәү) Альберт Харисович Казан университетының физика факультетында алган. Аны һәм аспирантураны яхшы билгеләренә генә тәмамлагач, хезмәт эшчәнлеген КДУның гомуми физика кафедрасында кече фәнни хезмәткәр булып башлаган. Туган вузына Альберт Гыйльметдинов барысы чирек гасыр гомерен багышлаган. Университетта докторлык диссертациясе яклаган, профессор һәм үзе төзегән аналитик спектроскопия лабораториясе мөдире булган. Ул чын галим: тикшеренү сәләтенә ия булган хәлдә, белемнәрнең үз тармагы үсешенә реаль өлеш керткән кеше. 1990нчы еллар башында, чит илләргә юл ябылгач та, Альберт Харисовичның АКШ, Канада, Германия, Бөекбритания, Словения, Норвегия, Швеция, Кытай һәм Тайвань университетларына спектроскопия һәм плазма физикасы буенча лекцияләр укырга һәм халыкара конференцияләрдә катнашырга даими чакырылып торуы очраклы хәл түгел. Аның ике монографиясе (автордашлыкта) АКШта һәм Бөекбританиядә басылып чыккан, ул – 22дән артык фәнни хезмәт авторы, уйлап табуга 16 патенты (шул исәптән халыкара) бар. Аның бу фәнни эшчәнлеге үз илендә дә (Фән һәм техника өлкәсендә ТР Дәүләт премиясе), чит илдә дә (атом спектроскопиясе буенча Atomic Spectroscopy Award* һәм Йоханус Маркус Марси исемендәге халыкара премияләр) законлы танылу алды.

Талантлы галим яхшы оештыручы да булып чыкты. Альберт Харисович өчен идарәче юнәлешенә күчү авыр булмады. 2007 елда ул ТР мәгариф һәм фән министры урынбасары итеп билгеләнде, ә 2009 елда министрлыкны җитәкләргә алынды. Шуннан соңгы өч ел мәгариф системасы өчен шактый гына зур проектларны эшләү һәм тормышка ашыру чоры булды. Ул 2010 елда «Киләчәк» 2010–2015 елларга Татарстан мәгарифе үсеше стратегиясеннән башланды. Бүгенге көндә әлеге стратегиянең мәгариф белән идарә итү системасының нәтиҗәгә ориентлаша башлауга китерүен әйтергә була. Шулай ук республика мәктәпләрендәге кадрлар потенциалының көчәюе, инфраструктураны киң колачлы модернизацияләүгә һәм мәгарифне матди-техник яктан тәэмин итүгә старт бирелүе һәм яңа белем бирү технологияләре кертелүе әлеге стратегиянең мөһим нәтиҗәләре булып тора. Татарстан, Россиядә беренчеләрдән булып, өч яшьтән өлкәнрәк сабыйларны балалар бакчалары белән тулысынча тәэмин итте («Бәләкәч» программасы). «Электрон балалар бакчасы», «Электрон мәктәп» автоматлаштырылган системалары да шул вакытта эшләнде һәм гамәлгә кертелде. Нәтиҗәдә ике ел эчендә республика халыкның укыту сыйфатыннан канәгать калуы күрсәткече буенча федераль рейтингта 37нче урыннан 5нче урынга күтәрелде. Мон-

Реклама

1\. Д. Медведев һәм Д. Ливанов «КАИ-Лазер» белән таныша.

КМТТУ-КАИның яңа партнёрлары арта бара.

* Atomic Spectroscopy Award – атом спектроскопиясе буенча халыкара премияләр.

нан тыш, министр Татарстанның сәләтле студентларын һәм аспирантларын дөньяның иң яхшы университетларына җибәрүче «Алгарыш » республика программасын модернизацияләүдә дә турыдан-туры катнашты.

2013 елда Альберт Харисовичның карьерасында һәм тормышында яңа чор башланды – ул КМТТУ-КАИ ректоры итеп билгеләнде. Шунда ук университетның белем бирү һәм фәнни потенциалын үстерүне, Татарстан һәм Россиянең сәнәгать һәм фәнни үзәкләре белән бәйләнешләрне ныгытуны эшчәнлегенең өстенлекле юнәлешләре итеп билгеләде. Ачышлар сериясе башланды: корабль төзелеше үзәге, республика предприятиеләрендә база кафедралары челтәрләре, корпоратив институт. Замананың соңгы сүзе белән җиһазландырылган «КАИ-Лазер», «КАИ-Композит», «КАИ-Квант» кебек инженерлык үзәкләрен үз эченә алган «КАИ-парк» технологик кластеры, сәнәгать робот техникасы үзәге, шулай ук лазерлы аддитив технология лабораториясе төзелде. Тагын ике үзәк – «КАИ-электроника» һәм «КАИ-двигатель» – төзү планлаштырыла, аларда заманча нано-һәм микроэлектроника буенча һәм двигатель төзү өлкәсендә тикшеренүләр үткәрү күздә тотыла. Инновацион технологияләр үзләштерү һәм аларны икътисадның реаль секторына кертүгә исәпләнгән фәнни һәм белем бирүнең тоташ бер челтәре булдырылды. Профессор-мөгаллимнәр составының квалификациясен күтәрүнең яңа программалары кертелде. 2013 елда КМТТУ-КАИ РФ Мәгариф һәм фән министрлыгының дүрт мегагрантын откан бердәнбер вуз булды. Очу аппаратларының ныклыгын һәм ышанычлылыгын тикшерү лабораториясе һәм нанотехнологик үзәк тагын да көчлерәк үсеш алды. Вуз үсеше саннарда да чагылыш тапты: 10 яңа белем бирү программасы эшләнде һәм тормышка ашырыла, 7 яңа белгечлек һәм 27 өстәмә һөнәри белем бирү программасы ачылды.

Ә 2014 ел КМТТУ-КАИда халыкара хезмәттәшлек үсеше чоры буларак танылды. Уку йорты базасында, илдә беренче буып, яңа технологияләрнең Германия – Россия институты (ГРИНТ) ачылды, аны тәмамлаучылар берьюлы ике дипломга (Россиянеке һәм Германиянеке) ия булачак. Бу зур проект РФ Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Хөкүмәте һәм Германиянең DAAD** академик алмашу хезмәте ярдәме белән тормышка ашырыла. Хәзер ГРИНТ, Германиянең Ильменау һәм Магдебург партнерлык университетлары белән бергәләп, алты магистр программасын тормышка ашыра. Быел аларга Кайзерслаутерн Техник университеты да кушыла.

Әмма КМТТУ-КАИдагы Германия – Россия фәнни хезмәттәшлеге моның белән генә чикләнми. Ректор инициативасы белән 1915 елда биредә әйдәп баручы немец компанияләренең инжиниринг үзәкләре ачылды, «Татарстан – Тюрингия» машина төзелеше үзәге ачылышы көтелә.

Мәктәп укучылары һәм яшьләр арасында техник фәннәрнең һәм инженерлыкның дәрәҗәсен күтәрү һәм популярлаштыру кирәклеген аңлаган хәлдә, КМТТУ-КАИ 2015 елда А. Н. Туполев исемендәге Халыкара премия һәм яшь галимнәр өчен В. Е. Алемасов исемендәге премия булдырды. Ә узган уку елы барышында вуз базасында I Бөтенроссия инженерлар фестивале уздырылды, анда 17 меңнән артык укучы һәм студент, шулай ук 42 сәнәгать предприятиесе катнашты. Узган елның сентябрендә сәләтле балалар өчен КМТТУ-КАИның инженерлык лицее ачылды.

Альберт Гыйльметдинов җитәкчелек иткән чорда КМТТУ-КАИ эшчәнлегендәге барлык мөһим күрсәткечләрнең шактый нык үсеше күзәтелә. Бу абитуриентларны кабул итү сыйфатына да (гомуммилли рейтингта университет өч ел эчендә әлеге күрсәткеч буенча 170 пунктка күтәрелде), кандидатлык һәм докторлык диссертацияләрен яклау санына да, вуз хезмәткәрләре эшләренең Scopus и Web of Science*** мәгълүматлар базасында саклана торган халыкара нәшриятларда басылу санына да, чит ил студентлары санына да (ул ике тапкырдан да күбрәккә артты), университетта уртача хезмәт хакының күләменә дә (өч елда 51%ка үсте) кагыла.

Бу күләмле исемлек КМТТУ-КАИның дәрәҗәле эш һәм уку урынына әйләнгәнлеге турында сөйли. Бүген ул – Идел буеның әйдәп баручы профильле вузы, Россиянең иң яхшы белем бирү учреждениеләре исәбенә керә һәм мәгариф рейтингларында алдынгы урыннарны били. РФ Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан КМТТУ-КАИ нәтиҗәле университет булып танылды. Бу, һичшиксез, җитәкче хезмәтен дә югары бәяләү – аның тырышлыгы белән университет заманча укыту һәм фәнни тикшеренү комплексына әйләнә бара.

Хөрмәтле Альберт Харисович!

Чын күңелдән юбилеегыз белән тәбрик итәбез! Сезнең җитәкчелектә КМТТУ-КАИ киләчәккә ышаныч белән карый һәм төрле катлаулы мәсьәләләрне хәл итәргә әзер тора. Сәламәтлек, гаилә иминлеге һәм, әлбәттә, университетыбыз файдасына яңа нәтиҗәле идеяләрегезнең һәм ниятләрегезнең тормышка ашуын телибез!

КМТТУ-КАИ коллективы

МАКС-2015.

Альберт Гыйльметдинов КМТТУ-КАИның сәләтле балалар укый торган инженерлык лицеенда.

** DAAD (Deutscher Akademischer Austauschdienst, Германия академик алмашулар хезмәте) – төп эше студентларга Германиядә укырга булышу булган халыкара оешма.

*** Scopus и Web of Science – халыкара мәгълүматлар базасы.

PRESSA.RU

Александр Гомзин,
«М.П. Симонов исемендәге тәҗрибә-конструкторлык бюросы» Фәнни-җитештерү берләшмәсе АҖ генераль директоры – баш конструкторы

Лаеклы биеклектә!

Хөрмәтле Альберт Харисович!

Симонов исемендәге ТКБ хезмәткәрләре исеменнән Сезне 60 яшьлек юбилеегыз белән чын күңелдән тәбрикләргә рөхсәт итегез!

Бүген Сез республиканың милли-тикшеренү университеты статусына ия әйдәп баручы вузларның берсен җитәклисез. КМТТУ-КАИ ректоры булып эшли башлаганнан бирле бөек максатка ирешү – бөтен Россия авиация һәм оборона сәнәгате өчен уникаль инженер кадрлар әзерләү урыны буларак, вузга аның элеккеге данын кире кайтару өлкәсендә эшлисез. Бүген күп проектларыгыз уңышлы тормышка ашырылды. Алда тагын да зуррак казанышларга ирешәчәгегезгә ышанам.

Безнең кайчандыр «ОКБ «Сокол» дип аталган, Казан авиация институты студентларының тәҗрибә-конструкторлык бюросы һәм Казан авиация заводы базасында нигез салынган предприятиебез язмышы да КАИ белән тыгыз бәйләнгән, шуңа күрә аның Сезнең җитәкчелек астында ирешкән уңышларын күзәтү безгә аеруча сөенечле.

Партнёрлыгыбыз уңышлы дәвам итә. КАИның алдынгы студентлары безнең предприятиедә практика үтәләр, ТКБ өчен, мәсәлән, пилотсыз очу аппаратлары төзү һәм камилләштерү кебек проектлар эшләүдә катнашалар. Вузның һәм аның укытучыларының дәрәҗәсе турында бу күп нәрсә сөйли. Сез КАИның дәрәҗәсен тиешле югарылыкта тотуны дәвам итәсез.

Хөрмәтле Альберт Харисович! Энергиягез, талантыгыз, максатка омтылучанлыгыгыз вуз тарихына әле тагын бик күп данлы сәхифәләр өстәячәгенә ышанам. Янәшәгездә һәрчак фикердәшләр булуын, инициативаларыгызның хуплау табуын, ә проектларыгызның тормышка ашуын телим. Сәламәтлек, уңышлар һәм иминлек юлдаш булсын Сезгә!

Реклама

ЯНӘШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА

ТАТАРСТАН

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

Реклама бүлеге:
тел: (843) 222-09-76

Махсус проектлар бүлеге:
тел: (843) 222-06-05

ФӘН ҺӘМ ТОРМЫШ

Илшат Гафуров, Казан (Идел буе) федераль университеты ректоры, ТР Дәүләт Советы депутаты, августта үзенең 55 яшьлек юбилеен билгеләп үтә.

Илшат Рәфкатовичның хезмәт биографиясендә иң озын чор Алабуга районы белән бәйле, ул аны 1998–2010 елларда җитәкләде. Соңгы алты елда юбиляр Казан университеты – Россиянең иң эре унлыгына керүче вуз (45 меңнән артык студент) белән җитәкчелек итә. Илшат Рәфкатович эшләгән чорда КФУ төрле юнәлештәге алты мөстәкыйль вузны үзенә берләштерде – илебездәге югары мәктәпләр тарихы уку йортларының бу кадәр зур тупланышы аналогларын белми.

Илшат Гафуров эшчәнлеге казанышлары «ТРның атказанган икътисадчысы», «Россия ТКХның мактаулы хезмәткәре» исемнәре, РФ Хөкүмәте премиясе, ЮНЕСКОның «Алтын пальма ботагы» дипломы, «Казанның 1000 еллыгы хөрмәтенә», «Фидакарь хезмәт өчен» медальләре белән билгеләп үтелгән.

Нэлла Прусс,
«ТИСБИ» Идарә университеты ректоры, профессор

Ярдәмегезне югары бәялибез һәм киләчәктә дә нәтиҗәле хезмәттәшлеккә ышанабыз!

Хөрмәтле Илшат Рәфкатович!

Матур бәйрәмегез – юбилеегыз белән чын күңелдән тәбрик итәм! «ТИСБИ» Идарә университетының барлык коллективы – укытучылар, хезмәткәрләр һәм студентлар изге теләкләргә һәм ихлас котлауларга кушыла.

Россиянең гаять зур федераль университетына уңышлы җитәкчелек итеп, Сез аны яңа дәрәҗәгә күтәрдегез – аның дөньяның иң яхшы университетлары рейтингында югары позицияләр яулавы шуны раслый. Җитәкчелек талантыгыз, принципиальлелегегез һәм алдан күрүчәнлегегез аркасында вузда уникаль инновацион проектлар тормышка ашырыла. Сезнең җитәкчелек астында биомедицина һәм фармацевтика кебек өстенлекле фәнни юнәлешләр, перспективалы материаллар һәм нанотехнологияләр, инфокоммуникацион һәм космик технологияләр уңышлы үсә. Топ-менеджерлык сәләтегез, инициативалылыгыгыз аркасында билгеләнгән стратегияне тиешле дәрәҗәдә тормышка ашыруны дәвам итәчәгегезгә ышанабыз.

Татарстан вузлары ректорлары Советын җитәкләгән хәлдә, Сез мөмкинлекләре чикләнгән кешеләрне укытуга да нык игътибар бирәсез. Нәкъ менә «ТИСБИ» Идарә университетына алар белән эшләү буенча Республика вузара үзәге эшен ышанып тапшыруыгыз өчен рәхмәтлебез. Ярдәмегезне югары бәялибез һәм киләчәктә дә нәтиҗәле хезмәттәшлеккә ышанабыз!

Чын күңелдән ныклы сәламәтлек, иминлек, саекмас энергия һәм оптимизм телибез! Тугрылыклы фикердәшләрегезнең ярдәмен тоеп яшәгез, Россия мәгарифе һәм фәне хакына билгеләнгән планнарыгызны уңышлы тормышка ашырыгыз!

PRESSA.RU

Асия Тимирясова,
В. Г. Тимирясов исемендәге Казан инновацион университет (ИЭУП) ректоры

Олы хезмәтегез өчен рәхмәт Сезгә!

Хөрмәтле Илшат Рәфкатович!

В. Г. Тимирясов исемендәге Казан инновацион университеты (ИЭУП) коллективы һәм шәхсән үз исемемнән 55 яшьлек юбилеегыз белән котларга рөхсәт итегез!

Сезнең зур абруегыз һәм олы хезмәтегез бөтен дөньяга билгеле булган фән һәм мәгариф үзәге – Казан университеты тархында яңа битләр ачарга мөмкинлек бирде.

Казан университеты, халыкара дәрәҗәдәге идеяләр һәм югары класслы белгечләр хәзерләүче буларак, яңа, вузның Россия һәм бөтендөнья фән-мәгариф киңлекләрендәге билгеләнеше белән бәйле булган тагын да югарырак үсеш траекториясенә чыкты.

Без барыбыз да Казан (Идел буе) федераль университетының соңгы еллардагы комплекслы үсеше белән горурланабыз: инфраструктураның яңа объектлары ачыла, яңа фән-мәгариф бүлекчәләре төзелә, йөзләрчә уку һәм фәнни лаборатория сафка баса – аларның җиһазлары дөньяның иң эре университетлары көнләшерлек. Оештыру сәләтегез һәм үзегезнең турыдан-туры катнашуыгыз аркасында университет күз алдында бөтендөнья брендларыннан калышмый торган куәтле тикшеренү структурасына әйләнеп бара, шул ук вакытта үзенең тарихи атмосферасын һәм Татарстан бердәйлеген саклап калуын дәвам итә.

Илшат Рәфкатович, Казан университеты, Татарстан, бөтен илебез файдасына булган барлык иҗади ниятләрегезнең алга таба да тормышка ашуын телибез! Хезмәтегез Сезгә канәгатьлек һәм сөенеч китерсен! Нык сәламәтлек, күтәренке күңел, иминлек һәм бетмәс-төкәнмәс энергия телим!

Реклама

Борис Тихомиров,
«Казан Гипронииавиапром» АҖ генераль директоры

КФУның киләчәге – Татарстан фәненең киләчәге!

Хөрмәтле Илшат Рәфкатович!

Казан федераль университетының данлы исеме бөтендөнья җәмәгатьчелегенә яхшы таныш. Ректор буларак, Сез бу исемнең нигезендә вузның мәгариф, фән, сәнәгатьнең иң алдынгы өлкәләрендәге казанышлары ятсын өчен күп көч куясыз.

Университет эшендәге барлык юнәлешләрнең комплекслы үсешенә гаять зур игътибарыгызны юнәлтеп, аның матди-техник базасын камилләштерү проектларын системалы тормышка ашыруны дәвам итәсез.

Сезнең ышанычыгыз аркасында «Казан Гипронииавиапромы» хезмәткәрләре илнең әйдәп баручы вузларының берсен модернизацияләүгә үз өлешләрен кертә алдылар. Казан университетының күп кенә белгечләребезнең alma materы булуы аеруча куанычлы.

Беренче проектларыбызның берсе – балалар дәваханәсе һәм хәзер «Алабуга-Сити» дип йөртелүче кунакханә. Шәһәрнең тарихи үзәгендәге төзелеш эше һәрвакыт проблема булып тора. Әмма бу объектларны проектлау һәм төзү вакытында ул проблемаларны хәл итү Сезнең ярдәм белән шактый җиңел хәл ителде.

Безгә Казан университеты проектларын тормышка ашырганда Сезнең белән бергә эшләү бәхете тиде. Аеруча зур горурлыгыбыз – В. П. Энгельгардт исемендәге Астрономик обсерватория базасындагы планетарий проекты, анда катлаулы архитектура һәм инженерлык мәсьәләләрен хәл итәргә кирәк булды. Проектны тормышка ашыру төрле яшьтәге һәм белем дәрәҗәләре төрле булган кешеләрнең астрономия дөньясын танып белүендә интерактив ысулны актив файдалануны күздә тота. Әлеге проект Казанның йөзен бизәп торучы символик билге һәм дөнья планетарийлары арасында урын алган объект булып исәпләнә.

Университетның химия факультетының яңа бинасы проектын да Сезнең белән бергә эшләдек, ул бинада бөтендөнья дәрәҗәсендәге 30дан артык фәнни лаборатория урнашкан, анда дөнья һәм Россия фән һәм мәгариф үзәкләренең әйдәп баручы галимнәре белән хезмәттәшлек алып барыла.

Казан университеты белән безне аның 200 еллыгы һәм Казанның 1000 еллыгы алдыннан тарихи объектларны реставрацияләү һәм яңартып корудан башланган тыгыз иҗади хезмәттәшлек бәйли.

Казан университетының югары интеллектуаль атмосферасы белән өретелгән подрядчылар эшләгәнгә, төзелеш мәйданчыкларында иҗат рухы хөкем сөрде.

Хөрмәтле Илшат Рәфкатович! Сез – сәләтле җитәкче, менә дигән оештыручы һәм стратег. 55 яшьлек юбилеегыз алдыннан «Казан Гипронииавиапром» коллективы исеменнән университет файдасына булган барлык планнарыгызның тормышка ашуын телибез – Татарстан һәм Россия фәненең һәм сәнәгатенең киләчәге университет эшчәнлегеннән дә тора бит. Сәламәтлек, иминлек, уңышлар телибез Сезгә!

Реклама

Рәшит Заһидуллин,
Апас муниципаль районы башлыгы, Апас муниципаль районы Советы рәисе, Апас штп башлыгы

Максатыгызга таба ышанычлы атлагыз!

Хөрмәтле Илшат Рәфкатович, 55 яшьлек юбилеегыз уңаеннан ихлас котлауларымны кабул итегез!

Сезне Апас муниципаль районы халкы исеменнән тәбрикләү минем өчен аеруча куанычлы. Нәкъ менә апаслылар ТР Дәүләт Советының V чакырылышына сайлауларда Апас бер мандатлы сайлау округында депутат итеп күпчелек тавыш белән Сезне сайладылар. Илшат Рәфкатович, районыбыз мәнфәгатьләрен республика дәрәҗәсендә намус белән кайгыртуыгыз өчен, Сезгә нык рәхмәтлебез. Җирле проблемаларыбызны бик яхшы беләсез һәм аларны хәл итүдә актив катнашасыз. Апас районы территориясендә гражданнарны кабул иткәндә дә депутат эшенең бу гаять мөһим өлешенә һәрвакыт җаваплы карыйсыз. Сез җитәкли торган Казан университеты да районның җирле үзидарәсе органнарына төрле яклап методик ярдәм күрсәтә, вуз шулай ук 2030 елга кадәрге район үсеше стратегиясен эшләүдә катнаша. Сез – ел саен Апаста Балаларны яклау көнендә уздырыла торган Балалар сабантуе иганәчеләренең берсе. Районда үткәрелә торган барлык әһәмиятле чараларда да катнашасыз. Депутат эшчәнлегегездә иң әүвәл кешеләр белән эшлисез һәм, димәк, Апас җире мәнфәгатьләрен ихлас кайгыртасыз. Моның өчен рәхмәт Сезгә!

Илшат Рәфкатович, без шулай ук Казан университеты белән горурлану хисе кичерәбез һәм аның соңгы еллардагы үсешендәге уңышлары өчен сөенәбез. Сез һәрвакыт дөрес максат сайлый һәм шуңа таба тыныч һәм ышанычлы төстә бара белдегез. Вузның бөтендөнья дәрәҗәсендәге тикшеренү университетына әверелүенә юнәлтелүен беләбез, һәм Сезнең җитәкчелектә аның бу максатка һичшиксез ирешәчәгенә ышанабыз. Инде бүген КФУ глобаль һәм региональ базарлар үсеше тенденцияләрен игътибар белән күзәтә һәм Татарстанның иң эре предприятиеләре, Европа һәм Азиянең җитештерү һәм инжиниринг компанияләре, фәнни-белем бирү үзәкләре белән берләштерелә. Инде бүген ул уникаль лабораторияләргә ия, чит ил һәм Россиянең әйдәп баручы галимнәре, яшь талантлы тикшеренүчеләр аларда эшләүне зур дәрәҗә дип исәпли. Инде хәзер университетта төрле предметлар белән тоташкан куәтле фәнни юнәлешләр формалаша. Аның структурасының уңышлы рәвештә үзгәртелүен, эшлекле попечительләр советы төзелүне, биналарының йөзе яхшы якка үзгәрүне дә беләбез. Университет акча табу һәм шулай ук конкурс һәм грант нигезендә финансларны арттыру өлкәсендә дә уңышлы эшли. Классик университетта һичшиксез практик фәннәр дә булырга тиешлеген Сез хаклы рәвештә әйтә килдегез, чөнки хәзерге заман вузы зур икътисадый һәм социаль мәсьәләләрне хәл итүдән аерым яши алмый. Һәм шуңа күрә дә бүген КФУда әйдәп баручы университетларга хас булганча фәнни белем бирү һәм тикшеренүләрдән алып интеллектуаль хезмәт продуктларын коммерцияләштерүгә кадәр эш алып барыла.

Илшат Рәфкатович, тагын бер кат юбилеегыз белән тәбрикләргә рөхсәт итегез! Апас районы, Татарстан Республикасы, бөтен илебез һәм, әлбәттә, Казан университеты (без аның югары уку йортларының бөтендөнья элитасына керәчәгенә ышанабыз) өчен алга таба да нәтиҗәле эшегезне дәвам итүегезне телим! Сәламәтлек, рухи көч һәм уңышлар юлдаш булсын Сезгә!

Реклама

PRESSA.RU

Геннадий Емельянов,
Алабуга муниципаль районы башлыгы,
Алабуга шәһәре мэры

Кешеләр алдындагы җаваплылык – җитәкченең төп сыйфаты ул

Хөрмәтле Илшат Рәфкатович!

Барлык алабугалылар һәм шәхсән үз исемемнән юбилеегыз белән котларга рөхсәт итегез!

Менә алты ел дәвамында Сез илебезнең гаять абруйлы уку йортын – Казан федераль университетын җитәклисез. Без барыбыз да КФУның күз алдыбызда зур тизлек белән үсеп баруын зур горурлык белән күзәтәбез. Вузның Россия һәм халыкара фәнни һәм белем бирү киңлекләрендә позицияләре ныгый, анда укып чыккан белгечләргә ихтыяҗ арта, интеллектуаль хезмәт продукциясенең сыйфаты яхшыра, икътисадның реаль секторы белән үзара бәйләнеше көчәя. Ректорлык эшчәнлегегезнең нәтиҗәләре соклангыч. Хезмәтегез өчен рәхмәт Сезгә!

Шул ук вакытта безгә, алабугалыларга, хезмәт биографиягезнең мөһим өлеше Алабуга җире белән бәйләнгән булуы аеруча күңелле. Биредә үскәнсез, шушында укытучылык эшчәнлегегезне башлагансыз, 12 ел буе районыбызны җитәкләгәнсез, аның уңышларына нигез салгансыз – алар белән ул бүген хаклы рәвештә горурлана.

1998 елда махсус икътисадый зоналар турындагы федераль закон өчен үрнәк булып торган «Алабуга» МИЗ турындагы республика законы проектын эшләү нәкъ менә Сезнең исем белән бәйләнгән. 2005 елда Россия хөкүмәте карары буенча ул Сез җитәкчелек иткән чорда тормышка ашырылды һәм куәтле көченә эшли башлады. Бүген «Алабуга», билгеле булганча, Россиядә сәнәгать-җитештерү тибындагы гаять эре МИЗ, Татарстанга чит ил инвестицияләрен җәлеп итүдә әһәмиятле нокта.

Нәкъ менә Сез Алабуганың социаль һәм мәдәни инфраструктурасын җитди рәвештә үзгәртү, аны ачык һавадагы музей-шәһәргә, XVIII–XIX гасырлардагы уезд үзәге фрагментларын музей объектларына әйләндерү инициативасы белән чыктыгыз. Бүген болар барысы да Алабугабызның үзенчәлекле йөзен билгеләп. Территориянең комплекслы үсеше идеясен дә Сез тәкъдим иттегез. Нәтиҗәдә 2002–2006 елларга Алабуга районы һәм Алабуга шәһәренең социаль-икътисадый үсеше программасы кабул ителде, һәм шуның кысасында Марина Цветаеваның мемориаль комплексы, Иван Шишкин, Надежда Дурова мемориалларын үз эченә алган крайны өйрәнү комплексы ачылды. Бүген алар шәһәргә туристларны җәлеп итүдә әһәмиятле роль уйный, кунаклар килүе арта – узган ел аларның саны 277 меңгә җитте. Һәм, ниһаять, без 2007 елда Алабуга үзенең 1000 еллыгын билгеләп үтүен дә хәтерлибез. Бу гаять зур бәйрәм булды, кайбер чаралар хәтта халыкара статус алды.

12 ел буе Сез район җитәкчелегендә намуслы эш башкардыгыз, халыкның тормыш дәрәҗәсен даими рәвештә күтәрә барып, алабугалыларның һәртөрле ихтыяҗларын канәгатьләндердегез, Сезгә ышанып тапшырылган территория иминлеге өчен тиешенчә уйланган карарлар кабул иттегез.

Илшат Рәфкатович, Сезгә һәрвакыт җаваплылык, инициативалылык, хезмәт сөючәнлек сыйфатлары хас булды. Туган төбәгездә җитәкче өчен алыштыргысыз булган әлеге сыйфатларны саклап калуыгызны телим. Кызыклы һәм нәтиҗәле идеяләр, сәламәтлек, күңел күтәренкелеге һәм уңышлар юлдаш булсын!

Реклама

БАРЫСЫ ДА ЯШЬЛӘР ӨЧЕН, СПОРТ ӨЧЕН

Марат Бариев, РФ Дәүләт Думасының алтынчы чакырылыш депутаты, РФ Дәүләт Думасының физик культура, спорт һәм яшьләр эшләре буенча комитет рәисенең беренче урынбасары, июльдә үзенең 55 яшьлек юбилеен билгеләп үтә.

Марат Мансуровичның 20 елдан артыкка сузылган һөнәри эшчәнлеге ике төп юнәлеш белән бәйләнгән: спорт үсеше һәм яшьләрне төбәк һәм илнең социаль-икътисади үсешенә тарту. Ун ел ТР Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм министрлыгында җитәкче булып тору дәверендә ул республикада спорт белән кызыксынуны сизелерлек арттырды, шулай ук Казанны 2013 елгы җәйге Универсиадага хәзерләү эшенә гаять зур өлеш кертте.

Марат Бариевның күптән түгел булган парламент инициативалары арасында – допинг кабул иткән өчен җинаять җаваплылыгына тарту турындагы закон проекты (РФ ҖКндагы төзәтмәләр), шулай ук «Россия Федерациясендә дәүләт яшьләр сәясәте турында»гы федераль закон проекты. Ул РФ субъектлары өчен яшьләр сәясәте өлкәсендә бердәм база нормативы документы булырга мөмкин.

Күренекле «КАИчылар» плеядасыннан

Альберт Гыйльметдинов, КМТТУ-КАИ ректоры

Хөрмәтле Марат Мансурович!

КМТТУ-КАИ коллективы һәм шәхсән үз исемемнән юбилеегыз белән кайнар һәм ихлас котлауларыбызны кабул итегез!

Университетны тәмамлаучылар аның горурлыгы булып тора. Сез – күренекле «КАИчылар» плеядасына керүчеләрнең һәм көн саен альма-матерларын үзләренең эшләре белән данлап торучыларның берсе. Без КМТТУ-КАИ үсешенә керткән өлешегезне югары бәялибез.

Дәүләт югарылыгындагы мәсьәләләрне хәл иткәндә Сез һәрвакыт югары профессиональлек һәм принципиальлек күрсәтәсез. Россия гражданлык җәмгыяте проблемаларын һәм мәнфәгатьләрен тирәнтен белү, гаять бай тормыш тәҗрибәсе, катлаулы мәсьәләләрне хәл итү сәләте, инициативалылык – иҗтимагый-сәяси эшлекләр карьерасындагы уңышны әлеге Сезгә хас сыйфатлар билгеләде.

Тормышыгыз һәрвакыт хезмәттәшләрегезнең ихтирамы һәм ярдәме, туганнарыгызның һәм якыннарыгызның мәхәббәте белән тулып торсын! Сезгә яңа профессиональ казанышлар, гаилә учагы җылысы телим! Уңышлар һәм күңел күтәренкелеге барлык башлангычларыгызда юлдаш булсын, ә ныклы сәламәтлек һәм яхшы кәеф көндәлек тормышыгызда һәрчак озата барсын. Үзегезгә һәм якыннарыгызга бәхет һәм иминлек телим!

PRESSA.RU

ҖИТӘКЧЕ БАР НӘРСӘГӘ БАШ

Альберт Мөхәммәтшин

Татарстанның пассажирларга хезмәт күрсәтүче иң эре автотранспорт предприятиеләренең берсе – Казан 2нче ПАТП 40 ел дәвамында эшли. Бу чор эчендә ул төрлесен күрергә өлгергән: бик авыр еллар да, тынычрак вакытлар да булган. Хәер, моның белән бүген берәүне дә гаҗәпләндереп булмый. Гаҗәбе шул: аның директоры Альберт Әхәтович Мөхәммәтшин бу предприятиегә үзенең 30 ел гомерен багышлаган.

Билгеле, бу озын юл аның өчен җитәкче урыннардан башланмаган. ПАТП-2гә Альберт 1987 елда яңа гына армиядә хезмәт итеп кайткан һәм Казан автотранспорт техникумын тәмамлаган 20 яшьлек егет булып килгән. Һәм шунда ук бер зур механизм – автобус паркы эшенә тартылган. Башта ПТО инженеры, аннары автобус йөртүче булып эшләгән. Соңрак колонна бригадиры, башлыгы, баш инженер, автотранспорттан файдалану буенча директор урынбасары булган. 2002 елда яңа директор билгеләү мәсьәләсе килеп тугач, озак баш ватарга туры килмәгән. Предприятиедә карьера баскычының барлык басмаларын үткән һәм аны биш бармагы кебек белгән Мөхәммәтшинның бу эшне булдыра алачагында инде беркем дә шикләнмәгән.

1980нче еллар азагындагы һәм бүгенге ПАТП-2 – күпмедер дәрәҗәдә икесе ике предприятие. Автобуслар паркының үзендәге тәртипләр дә, пассажирларга хезмәт күрсәтүдәге таләпләр дә үзгәрде. Бу үзгәрешләрнең инициаторы нәкъ менә Альберт Әхәтович булды. Әмма шул ук вакытта ул ПАТП-2нең төп традициясе – кеше хезмәтен хөрмәт итү – үзгәрешсез калырга тиеш икәнлеген һәрвакыт ассызыклады. Директор үзе 14 яшеннән эшли башлаган, ул чын мәгънәсендә эшче кеше. Аның дөньяга ныклы карашы, остазларга һәм, гомумән, өлкәннәргә ихтирамлы мөнәсәбәте шуннан килә. «Әле дә бездә малай чагымда мине эшкә өйрәткән ветераннар хезмәт куя, – диде Альберт Әхәтович үзенең бер интервьюсында. – Алар – предприятиебезнең горурлыгы, һәрберебезгә үрнәк кешеләр». Һәм бу гади генә сүзләр түгел. Предприятиенең бар эшчәнлеге иң беренче чиратта коллективны саклауга юнәлтелгән. Мәсәлән, автопаркның 20 һәм аннан да күбрәк ел эшләгән хезмәткәрләре хезмәт хакларына 30 процент өстәмә ала. Мөгаен, бу ПАТП-2нең ачы тәҗрибәсенә нигезләнгәндер. 1990нчы елларда, төшемлерәк эш эзләп, күпләр предприятиене ташлап киткән. Аларны аңларга та була – һәркемнең тотрыклы хезмәт хакы аласы һәм заманча уңайлы машина йөртәсе килә (ул чакта икенче автопаркта иске ЛиАЗлар һәм «пазик»лар гына калган булган). Билгеле, Альберт Әхәтовичның үзенең дә бөтенесен ташлап китү теләге туган чаклар булган. Әлеге адымнан аны, үзенең әйтүе буенча, бу коллективка хас дуслык, иптәшлек, үзара ярдәмләшү хисе саклап калган.

ПАТП-2дәге машина йөртүче шәхесенә мөнәсәбәттә дә кеше хезмәтенә хөрмәт белән карау чагыла. Җитәкче аның предприятиедә төп көч икәнен яхшы аңлый. Альберт Әхәтовичның яратып куллана торган сүзе дә – «ашаган белми, тураган белә». Шуңа күрә биредә машина йөртүчеләргә уңайлы шартлар тудырырга тырышалар. Рейстан соң вакытларын гаражда мөмкин хәтле азрак үткәрсеннәр өчен бөтенесен дә эшлиләр. Бүген читтән килеп эшләүче шоферлар өчен директор карары буенча төзелә торган тулай торак бассейны һәм физиопроцедуралар өчен көндезге стационары булган сәламәтләндерү комплексы белән җиһазланачак. Шул ук вакытта ПАТП-2нең үз территориясендә инде ике фитнес-залы бар. Хезмәткәрләрнең шифаханәләрдә, балаларының лагерьларда ял итү чыгымнарының яртысын предприятие түли. Бу аена алтышар миллион пассажир йөртүче компаниянең эш темпын киметмәве, киресенчә, киләчәккә ныклы нигез салуы турында сөйли.

Һәрхәлдә, аның җитәкчесе ирешелгәннәрдә һич тә туктап калмаска җыена. «Ни өчен мин үземә дә, башка хезмәткәрләргә дә зур таләпләр куям? – ди Альберт Мөхәммәтшин. – Чөнки омтылырлык максат бар. Без Россия генә түгел, хәтта Европа буенча алдынгы автотранспорт предприятиесе булырга тиешбез. Бүген бу адымны атларга әзербез. Планнарыбыз зур».

Хөрмәтле Альберт Әхәтович!

Сез Татарстан башкаласы халкы һәм килгән кунаклар шәһәребезнең теләсә кайсы ноктасына уңайлы шартларда вакытында барып җитсен өчен бөтен тырышлыгыгызны куясыз. Без, ПАТП-2нең барлык хезмәткәрләре, Сезне җаваплы, намуслы, ышанычлы, һәрберебезгә хуплау һәм яклау сүзләре таба ала торган җитәкче буларак беләбез. Безнең эшнең үз үзенчәлекләре бар, ул һәрвакытта да җиңел генә түгел, әмма предприятиене Сезнең кебек шәхес җитәкләгәндә эшкә яхшы кәеф һәм күтәренке күңел белән киләбез. Моның өчен рәхмәт Сезгә! Ихлас күңелдән сәламәтлек, бәхет һәм озын гомер телибез!

Реклама

«ТАТАРСТАН» ЖУРНАЛЫ КАЙЛАРДА САТЫЛА

КАЗАН

МЕЛЬНИКОВ ШЭ

«ЭДЕЛЬВЕЙС»
Павлов ур., 23
Ибраһимов пр., 1
Чуйков ур., 38
Ямашев пр., 54
Голубятников ур., 21 а
Әмирхан пр., 41
Адоратский ур., 12
Мусин ур., 61 б
Гаврилов ур., 33
Адоратский ур., 11 а
Әмирхан пр., 97
Н. Назарбаев ур., 9/2
Восстание ур., 56
Фучик ур., 30 а
Сәфиуллин ур., 40
Зайцев ур., 10
Максимов ур., 4 а
Кошевой ур., 6
Октябрьнең 40 еллыгы ур., 4
Магистраль ур., 77
Мамадыш тракты, 36 а
Фучик ур., 72
Павлюхин ур., 101
Оренбург тракты, 138 а
Ломжа ур., 2 а
Н. Назарбаев ур., 54
Сәлимҗанов ур., 16
Универсиада пр., 16

«ПЯТЁРОЧКА»
Декабристлар ур., 8
Копылов ур., 5/1
Дежнев ур., 2
Һади Такташ ур., 123
К. Цеткин ур., 13
Җиңүнең 40 еллыгы ур., 6 а
(Осиново)
Губкин ур., 44
Кызыл Позиция ур., 9

«ПЕСТРЕЧИНКА»
Авангард ур., 54
Декабристлар ур., 184
Энергетиклар ур., 3
Краматорская / Лушников ур., 6
Латыш Укчылары ур., 25
Меридиан ур., 11
Юдино, Красиков ур., 11
Социалистик ур., 7

«БӘХЕТЛЕ»
Мәүлетов ур., 45
Павлюхин ур.
Әмирхан пр.
Оренбург тракты

«БОСФОР»
Миславский ур., 9

«МАГНИТ»
Әмирхан пр., 97
Фучик ур., 49
Татарстан ур., 18
Зорге ур., 33
Ибраһимов пр., 61

«АЗИНО» СК
Фучик ур., 155

7НЧЕ ШӘҺӘР ХАСТАХАНӘСЕ
Ямашев пр.

КИОСКЛАР
Совет ур., 22
Ямашев пр., 54
Гадел Кутуй ур., 24/31
Татарстан ур., 18
Б. Шаһиди ур., 1
Себер тракты, 8
Мәүлетов ур., 9
Чехов ур., 8
«Петрушкин двор» тукталышы
Ломжа ур., 24
Солидарность ур., 4
Шаляпин ур., 9
Әмирхан пр. / Чуйков ур., 71
Юдино, Бирюзовая ур.
Ленинград ур., 32
Парин ур., 6
Фучик / Зорге ур., 34
Курчатов ур., 2
Максимов ур., 1
Адоратский ур., 12
Губкин ур., 48
Сәфиуллин ур., 40
Тула / Авангард ур.
Кол Гали ур., 11/52 а

«МИР ПРЕССЫ – РЕГИОН» ҖЧҖ

«ДЕЙЛИ» КИБЕТЛӘРЕ
К. Маркс ур., 59
Н. Ершов ур., 78
Зорге ур., 93
«Тукай мәйданы» метро станциясе
Н. Ершов ур., 1 а («Корстон»)
«Горки» метро станциясе
Белинский ур., 4
«Җиңү проспекты» метро станциясе
Чуйков ур., 69
Парк ур., 6
Короленко ур., 81
Фрунзе ур., 5
Мусин ур., 68 б
Лаврентьев ур., 9
Даурия ур., 40

«ТАТАР КИТАП НӘШРИЯТЫ» ТР ДУП
Декабристлар ур., 2
Бауман ур., 19
Бауман ур., 29/11

«ГОРПЕЧАТЬ» ЯАҖ
Фрунзе ур., 7
Пушкин ур., 2
Сахаров ур., 13
Межлаук ур., 15
Ямашев пр., 49
Вишневский ур., 2
Н. Назарбаев ур., 47
Н. Назарбаев ур., 63
Восстание ур., 83
Кави Нәҗми ур., 7
К. Цеткин ур., 17/20
Восстание, 23 / Декабристлар ур.
Копылов ур., 5/1
Адоратский ур., 29
Максимов ур., 34/24
Липатов ур., 5
Достоевский ур., 74 а
Себер тракты, 7
Декабристлар ур., 189
Татарстан ур., 72
Даурия ур., 36
Даурия ур., 23
Автовокзал
«Казан Оргсинтез»
Горький шоссесы / Можайский ур.
Н. Ершов ур., 53
Кошевой ур., 16
Декабристлар ур.,178 а
Восстание ур., 56
Айдаров ур., 8 а
Окольная ур., 23
Себер тракты, 34
Декабристлар ур., 102
Челюскин ур., 31
Краснококшайская ур., 164
Максимов ур., 4
Ш. Усманов ур., 12
Гвардейская ур., 42
Батыршин, 16 / Коләхмәтов ур.
Революция ур.
Ильич ур., 30
Попов ур., 7
Беломорская ур., 73
Газовая ур., 9
Декабристлар ур., 115
Н. Назарбаев ур., 35
Черноморская ур., 3
Восстание ур., 6
Калинин ур., 73
Мәүлетов ур., 17
Гагарин ур., 22
Гагарин ур., 12
Халитов ур., 34 ж
Белинский ур., 9
Фучик ур., 72
Тынычлык ур., 33
Карбышев ур., 13
«Океан»
Чуйков ур., 38
Н. Ершов ур., 32
Гвардейская ур., 38
Чехов ур., 6
Халезов ур., 21
(Дәрвишләр бистәсе)
Короленко ур., 89
Декабристлар ур., 150

«ТАТАРСТАН ПОЧТАСЫ» ФПЭИ ПОЧТА БҮЛЕКЧӘЛӘРЕ
Сахаров ур., 27
Мәүлетов ур., 9
Забайкальская ур., 3
Маршал ур., 25
Һ. Такташ ур., 75
Мехчылар ур., 3
Бауман ур., 37
Меридиан ур., 14
Әмирхан пр., 10 а
Максимов ур., 2
Салмач, Тынычлык ур., 6 а
Адоратский ур., 29 а
Адоратский ур., 12
Мусин ур., 68
Гаврилов ур., 40
Җиңү пр., 17
Ю. Фучик ур., 34
Кремль
Нокса авышлыгы, 1
К. Маркс ур., 44
Яңа аэропорт
Татарстан ур., 11
К. Цеткин ур., 33
Фрунзе ур., 1
Айдаров ур., 22
Декабристлар ур., 191
Юбилей ур., 1/43
Вишневский ур., 14
Волгоград ур., 22
Шатура ур., 155
Качалов ур., 95
«Оргсинтез» заводы
Беломорская ур., 1
Карьер, Нокса ур., 29
Мирный, Яңа Дәүләкәй ур., 16 а
Нагорный, Круговая ур., 12
Павлюхин ур., 116
Рәхимов ур., 33
Ирек мәйданы, 1
Черноморская ур., 3
Петровск, Үзәк ур., 1
Тынычлык ур., 45
Гвардейская ур., 42
Яңа Юдино ур.,140
Красиков ур., 8
Завокзальная ур., 57
Альберт Камалиев ур., 12
Беломорская ур., 73
Зур Урам, 11
Я. Гашек ур., 1
Дәрвишләр бистәсе,
Краевая ур., 8 а
Товарищеская ур., 28/70
Б. Заречная ур., 22
Кадыш, Калинин ур., 1
Кремль
Оренбург тракты

PRESSA.RU

**Татарстан – яхшы кешеләргә генә түгел, гаҗәеп кызыклы риваятьләргә дә бай төбәк. Кайсы гына районга барып төшмә, үз якларына хас төгәллекләр белән тулы борынгы хикәятләрне сөйләп бирүче, барысыннан да хәбәрдар кеше һәрвакыт табыла.
«Татарстан» журналы республикабыз риваятьләрен туплады һәм алар белән сезне дә таныштыра бара.**

ТАТАРСТАН РИВАЯТЬЛӘРЕ: ШУРАН ӨРӘКЛӘРЕ

Лаеш районында урнашкан Шуран авылында, Каманың текә яры буенда, XVIII гасыр башларында салынган өй тора. Бүген ул гап-гади мәктәп, монда туристлар да тукталып тормый. Ләкин юкка гына! Әлеге йортта ике йөз елдан артык вакыт элек булган вакыйгалар турында риваятьләр йөри, ул гына да түгел, готик һәм романтик мотивлардагы китаплар да язылган. Мәхәббәт тә, кан да, өрәкләр дә чагылыш тапкан аларда.

Әлеге вакыйгаларның төп герое – отставкадагы капитан Андрей Нармацкий. Ул Шуранны әби-бабаларыннан мирас итеп ала. Ә тегеләренә Кама буендагы җирләрне Петр I үзе бүләк иткән була. Авылга күчеп килгәннән соң, Нармацкий урта гасырлар замогын хәтерләткән йорт салып куя. «Аның иң баштан ук манаралар, яшерен урыннар һәм җир аслары белән төзелгән өендә чылбырлар, бөҗралар, кысалар, рогаткалар һәм алпавытларча «үгет-нәсыйхәт» бирүнең башка кораллары булган төрмәләр булган», – дип яза үзенең китабында Казан тарихчысы Дмитрий Корсаков.

Андрей Петрович кансызлыгы белән аерылып торган, күрше-тирә авылларда яшәүче халык та, авыл янынннан узып баручы сәүдәгәрләр дә аннан курыккан. Башта ул үтеп баручы олаулардан һәм Кама буенча йөзүче кораблардан үз казнасына ясак җыюны оештырган. Ә аннары үз утарын гомумән пиратлар артеленә әйләндергән, ди.

Ошаган бар нәрсәне үзенә алу гадәте Нармацкийда хатын-кызларга карата да булган. Явыз алпавыт һәм аның тарафыннан урланган матур кызлар турында Георгий Дадиани «Софья и Алексей, или Красный замок на диком берегу Камы» (1825 ел) дип аталган повесть язган. Тирә-якка үзенең җенси дәрте, башбаштаклыгы һәм рәхимсезлеге белән танылган Кызыл замок хуҗасы Барбур (прототибы, күрәсең, Нармацкий булгандыр) крестьян кызы Софьяны яратып йөргән егете Алексей белән иртәгә туй булачак көнне урлап китә. Софьяны коткарырга маташкан Алексейны тоталар һәм кызның күз алдында Камага ташлыйлар. Әмма Барбурдан үч алу бөтенләй көтелмәгән яктан килеп чыга: Софьяга ярдәмгә аны сабый чакта тәрбияләгән Мартаза рухы килә. Өрәк Барбурның үз-үзенә хәнҗәр кадарга мәҗбүр итә. Үз тормышын Алексейдан башка күз алдына китермәгән Софья исә Камага сикерә. Яшьләрнең өрәкләре әлеге урында ел саен күренә имеш.

Нармацкий тарафыннан газаплап үтерелгән тоткын кызлар турындагы риваятьләрне аның нәселендәге яшь буын да сөйли. Шуларның берсе – язучы Петр Суворов (1839 елда туган) әбисеннән ишеткәннәрне җиткерә: «...Кәнәфигә (өйдә гаепле дип саналган кызларны утырта торган чуен «тәхет» булган дип сөйлиләр – авт.) бик матур, толымнарын тараткан яшь хатын-кыз чүкеп беркетелгән. Җир астын ачкач, саф һава агымы матур өрәккә барып бәрелгәч, ул шунда ук юкка чыкты. Бары тик сөякләр һәм чәчләр генә калды. Риваять буенча, Нармацкий үзенең матур күршесе Доможировага гашыйк була. Кыз аны кире каккач, ул хәйлә уйлап таба. Көзге караңгы төндә аның хезмәтчесе Доможированы урлый. Нармацкий тоткынын көч белән үзенеке итмәкче була. Ә кыз, җавап итеп, хурлаучысын яңаклый һәм моның өчен бик кыйммәт бәя түли...» Нармацкийның күршеләре арасында чыннан да Доможировлар гаиләсе дә булуы билгеле.

Үзенең күпсанлы явызлыклары өчен Нармацкий барыбер җәзасын ала: 1773 елда аны Тобольскига сөрәләр. Ул анда да җирле губернатор исеменә донос язмакчы була һәм шуның өчен соңгысы тарафыннан Иртыш елгасына батырыла.

Ә җирле халык хәзер дә Нармацкий утары турында легендалар сөйли. Кайберләре хәтта тоткыннарны тоткан һәм җәзаланган шул зинданнарны һәм елгада урланган әйберләрне өйгә кертү өчен төзелгән җир асты юлларын да күргәннәр, ди...

Олеся Бондаревская әзерләде

БУ АЙ КӘЕФЕ:
ЧӘЧӘКЛӘР ҺӘМ ПЕСИЛӘР

Җәй уртасында бөтен нәрсә чәчкә атып, хуш ис бөркегәндә, кәеф тә шундыйрак – чәчәкле. Кемгә бакчасында яки урамдагы хуш исләр җитми – Кремльгә, «Хәзинә» милли сәнгать галереясенә «яшь» рәссамнарның «Глубокий обморок сирени» күргәзмәсенә ашыга.

– Сиреньнән тыш, без биредә җәйге чәчәкләрне җыйдык, – дип сөйли күргәзмәнең оештыручысы һәм илһамчысы, рәссам Рәмзия Илһамова (нәкъ менә аның остаханәләрендә җитди һөнәр ияләре һәм саллы вазыйфаларны биләүче кешеләр буяуга катып беткән «бөек» рәссамнарга әверелә). – Һәм, бәлки, күргәзмәне тамаша кылучылар өчен көтмәгәндә, ләкин нәкъ без көткәнчә, әлеге чәчәк композицияләренә… төрле чәчәкләр арасында йокымсырап ятучы Казан мәчеләре кушылып китте. Алар кайчагында чәчәк өстендә дә изриләр. Алар үзләренең гамьсез кыяфәтләре белән бик тә табигый итеп экспозициягә баеталар. Чәчәкләр һәм песиләр – нәкъ менә Казан җәе. Шулай ук кышы да, көзе дә, язы да.

– Бу күргәзмә икеләтә үзенчәлекле, – дип шәрехли «Хәзинә» милли галереясе мөдире Анна Романова. – Беренчедән, ул залларда түгел, ә галереянең тарихи баскычларында бара. 1834 елда төзелгән борынгы баскычларда һөнәр осталары да, атказанган рәссам да, академик та түгел, ә менә өйрәнчек рәссамнарның картиналары бик тә үзенчәлекле күренә. Һәм алар туристларны үзенә җәлеп итә – кайтавазлар кенәгәсенә генә күз салу да җитә. Гадәти булмаган нәрсәләр һәрвакыт шулай бит.

PRESSA.RU



«Татарстан» журналына барлык элемтә бүлекләрендә язылырга мөмкин

Индекс **П2381** – татар телендә
Индекс **П2378** – рус телендә

ТАТАРСТАНДА ЯШИСЕҢ –

«ТАТАРСТАН»НЫ УКЫ!